ЯҢАШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

№04 (399)
АПРЕЛЬ 2025

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

«ГАЛӘМ ГҮЗӘЛЕ»

МИРАС, ЛИДЕРЛЫК ҺӘМ БАЛАНС ТУРЫНДА

№04 (399)
АПРЕЛЬ 2025

16+

Редакция:
Адрес: 420066, Россия,
Татарстан Республикасы,
Казан, Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасары: Фәридә Әхмәтҗанова
Әдәби мөхәррир: Луиза Янсуар
Бүлек мөхәррирләре: Руфия Фазылова, Николай Коновалов, Евгения Чеснокова, Дмитрий Сивков
Авторлар: Олеся Бондаревская, Хәмидә Гарипова, Сафа Гәрәев, Гомәр Даутов, Илсөяр Закирова, Әхмәт Шакиров
Фотограф: Александр Ефремов
Дизайн-макет: Олег Бурилов
Вёрстка: Анастасия Хатыйпова
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Тышлыкта: Раджана Солтанова. Алеся Сәлахова фотосы

Журнал 1920 елдан нәшер ителә
1977 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

ММЧ исеме: ТАТАРСТАН TATARSTAN

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 400 данә
Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4750 данә.
Реклама 16+

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә басылды. Адрес: 420066, Россия, Татарстан Республикасы, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: М-0552
Басарга кул куелды: 11.04.2025
Чыгу көне: 17.04.2025

Коммерция директоры:
Рәшит Хәйретдинов,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9600-487-900
Коммерция директоры урынбасары:
Алина Майорова,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9033-132-741
Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Ирина Захарова, irinamoroz10@mail.ru
Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел.: (843) 222-09-80

РЕДАКЦИЯДӘН

1 НЧЕ НОМЕРЛЫ ӘЗЕРЛЕК

Һәр елны Казан, җиң сызганып, май кунакларын каршыларга әзерләнә. Чөнки нәкъ менә майда, инде уналтынчы мәртәбә, безнең башкала «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum 2025» халыкара икътисадый форумын уздырачак.

«Бу еллар эчендә форум ислам дөньясы илләре өчен уңышлы бәйләнешләр булдыру мәйданына әверелде», – ди Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов. Ә Россия Президенты Владимир Путин, 2023 елда KazanForumга федераль статус биреп һәм ел саен бу чарада кунакларны сәламләп, Татарстан Республикасы турында бик җылы сүзләр әйтә. «Республика бик күп илләрдән килгән кунакларны һәрчак колач җәеп каршылый, шуның белән үзенең масштаблы һәм мәртәбәле эшлекле очрашуларны уздырырга әзер абруйлы да, дәрәҗәле дә мәйдан булуын елдан-ел раслый килә», – диде ул.

Безне күпсанлы чаралар көтә – эшлекле дә, күңел ачуга корылганнары да. Алар Ислам хезмәттәшлеге илләре арасында халыкара элемтәләрне тагын да ныгытыр, дип ышанып калабыз. Шулай ук форум көннәре матур да, ямьле дә, күңел җылысы белән өретелгән дә булыр, дип өметләнәбез.

Сезнең киң колачлы һәм дәрәҗәле эшлекле чараларны яктыртырга һәрчак әзер редакциягез

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛАХОВ Мәгъзүм Хәлимуллович
ФАЗЛЫЕВА Ләйлә Ринатовна
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы: «ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче: «ТАТМЕДИА» АҖ
Адрес: 420097, Россия,
Татарстан Республикасы, Казан,
Академическая ур., 2

«Татарстан» журналына ТРның барлык элемтә бүлекләрендә язылырга мөмкин:
Индекс **П2381** – татар телендә ярты елга
Индекс **ПА468** – татар телендә бер елга

Индекс **П2378** – рус телендә ярты елга
Индекс **ПА471** – рус телендә бер елга

2025 елның ярты еллыгына ТР буенча язылу бәясе:
1305 сум 00 тиен китереп биреше,
1274 сум 28 тиен соратып алганда.
2025 елга ТР буенча язылу бәясе:
2610 сум 04 тиен китереп биреше,
2548 сум 46 тиен соратып алганда.

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНА 104 ЯШЬ

ТАТАРСТАННЫҢ 100 җәүһәре

бары ТИК ТАТАРСТАНДА



БЕР ШАРФ БЕЛӘН БӘЙЛӘНГӘН

541 метр 40 сантиметр – гаять зур озынлыктагы шарфны март башында «Рубин» футбол җанатарлары «Ак Барс Арена» трибуналарында суза. 700дән артык кеше катнашкан акция җанатарларның яраткан клубы тирәсендә берләшү һәм бердәмлек символына әверелә. Символга лаеклы бәя бирелә – ул Россия рекордлар китабына кертелә. Рәсми телдә әйткәндә, бу «Россиядә состав өлешләрдән торган иң озын җанатарлар шарфы». Гәрчә, әйтик, 4646,46 метр озынлыктагы могҗиза – дөньяда бер кеше тарафыннан бәйләнгән иң озын шарф буларак Гиннесс рекордлар китабына кереп калган норвегияле Хельга Йохансен эшләнмәсенә сизелерлек оттырса да, бу чыннан да зур казаныш. Аның каравы Казанныкының – билгеләнеше үзенчәлекле. Аннан кечерәк шарфлар ясап сатарга, ә алынган акчаларга интернат-мәктәп өчен спорт инвентарьлары сатып алырга уйлыйлар.

© «Татарстан» журналы

WWW.PROTATARSTAN.RU

Фото: knigarekordovrossii.ru

ЭЧТӘЛЕК

акыллы гамәлләр

6. Онлайн режимдагы хәләл
Партнёрлык финансларына цифр ни рәвешле үтеп керә

10. Мәккәгә юл
Хаҗга ничек акча тупларга

14. Белем бирә торган курорт
Ул кайда урнашкан

20. Экспорт. Юнәлешләрне билгелик
Хәләл дөнья базарында ничек югалып калмаска

24. Кунакчыллык индустриясе
Хәләл туризмны үстерү юллары нинди

игелекле эшләр

38. Гамьле әңгәмә
Бәрәңгене кайчан утыртырга

42. Республика гербындагы җанвар
Ак барсны ничек саклыйлар

52. Туган як тарихы
Алабуга шәһәрлеген кемнәр күтәргән

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта:
protatarstan.ru

мәңгелек кыйммәтләр

56. Имам һәм галәм
Юрий Гагаринның билгесез фотосын кем ясаган

60. Җиңүнең 80 еллыгына
Батыр егетләр «тел»не кайдан алып кайткан

68. 41нче ел балалары
Сугыш чоры балалары авырлыкларны ничек җиңгән

76. Татарстан авыллары
Олы Мишә авылы бүген кемнәргә таяна

87. Казанның агач архитектура һәйкәлләре
Крестовниковлар йорты ни хәлдә

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

27.03

Резеда Хәйретдинова, КФУ Психология институтының башлангыч белем бирү кафедрасы доценты, – Россиядә мигрант балаларын адаптацияләү проблемалары буенча КФУда фикер алышу вакытында:

– Ата-аналарны Россиядә белем бирүнең сыйфаты җәлеп итә, бу урта белемгә дә, югарысына да кагыла. Еш кына мигрантлар балаларына төпле белем бирү, аларның якты киләчәген кайгырту өчен Россиядә яшәп калырга омтыла. Илебез дустанә дәүләтләрдән килүче кешеләргә мохтаҗ, әмма бу процесс идарә ителергә тиеш. Димәк, без, галимнәр буларак, мондый гаиләләрдәге балаларны укытуның нәтиҗәле методикаларын эшләргә тиеш.

ИГЕЛЕКЛЕ ӘШЛӘР

27.03

Владимир Вавилов, Анжела Вавилова исемендәге Балаларга ярдәм итү төбәк иҗтимагый фонды Идарәсе рәисе, – Мәскәүдә, күренекле дирижер Фуат Мансуров истәлегенә үткәрелгән хәйрия концертыннан соң:

– Шушы еллар эчендә хәйриячеләр ярдәмендә ике хоспис төзедек – башта балалар хосписы, аннары – өлкәннәр өчен. Хәзер аларда йөз пациент бар. Шуны ышандырып әйтә алам: акчаларның тиененә кадәр изге эшкә – балаларга ярдәмгә, хоспислар эшенә китәчәк. Бу игелекле эшкә керткән өлешегез өчен бик зур рәхмәт.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

12.03

Равил Гайнетдин, РФ мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, – Мәскәүдә ислам дөньясы илчеләре катнашындагы ифтарда:

– Без Татарстан Республикасы Рәисе, «Россия – Ислам дөньясы» стратегик караш төркеме рәисе Рөстәм Миңнехановны тарихта беренче тапкыр Россия шәһәре – Татарстан башкаласы Казанның ислам дөньясының мәдәни башкаласы дип игълан ителүе белән котлыйбыз. Стратегик караш төркеме әгъзасы, Казан кешесе буларак, мин барыгызны да борынгы мәдәни һәм сәүдә юллары очрашкан борынгы шәһәргә чакырам. 2024 елның октябрендә БРИКС Саммиты вакытында татарларның, Татарстанда яшәүче башка дин һәм милләт вәкилләренең кунакчыллыгын үзегез дә күрдегез. Казанга дистәләгән дәүләт башлыгы килгән иде, шул исәптән КХР Рәисе Си Цзиньпин, Һиндстан Премьер-министры Нарендру Моди, БГӘ Президенты Мөхәммәд бин Зәйд Әл-Нахайян, Иран Ислам Республикасы Президенты Масуд Пезешкиан һәм башка бик күпләр.

Фото: tatar-inform.ru, kpfu.ru,

игелекле эшләр

акыллы гамәләр /

мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Быелгы KazanForum **кемнәрне** көтә

Хаҗга акчаны **ничек** җыярга

Татарстан хәләл продукция экспортында **күпме** акча эшли

Хәләл туризмны **ничек** үстерергә

РОССИЯ – ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ: ИМИНЛЕК ХАКЫНА ХЕЗМӘТТӘШЛЕК

Татарстан башкаласында гадәттә май аенда уза торган «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» халыкара икътисадый форумы таныштыруга мохтаҗ түгел. Экспертлар аны Россия Федерациясе белән Ислам дөньясы илләре өчен төп икътисадый хезмәттәшлек мәйданчыгы дип атый. Бу чыннан да шулай: узган ел бирегә дөньяның 87 иленнән 20 000 нән артык катнашучы килде. Дистәләгән утырыш, очрашу, күргәзмә һәм сөйләшүләр нәтиҗәсендә 120 килешү төзелде. KazanForum-2025 тә шулай ук вәкиллекле булырга вәгъдә итә. Төп темалар арасында – Россия Федерациясенең икътисадый үсешендә ислам финанслары потенциалын куллану һәм «Төньяк – Көньяк» халыкара транспорт коридорын, глобаль хәләл индустрияне үстерү өчен яңа офыклар, ислам банкингының алдынгы технологияләре һ.б. Әлеге темаларның кайберләре турында «Татарстан» журналы үзенең махсус чыгарылышында сөйли. Редакция аны форум ачылышына әзерләде.

Фото: Александр Ефремов, tatarstan.top, islam.ru

ПАРТНЁРЛЫК ФИНАНСЛАРЫ: БАСЫМ – ЦИФРГА

Әхмәт Шакиров

Иджара, мурабаха, мудараба, сукук... Бу төшенчәләр акрынлап безнең өчен экзотика булудан туктый. Ә ислам ипотекасы, ислам арендасы яки ислам факторингы, хәләл дебет картасы турында әйтеп тә торасы юк – хәзер күпләр өчен аңлаешлы һәм көндәлек кулланыштагы инструментлар бу. Алга таба нәрсә? Мөгаен, иң мөһиме – алдынгы технологияләр нигезендә партнёрлык (ислам) капиталының заманча базарын формалаштырудыр. Бу юнәлештә дә эшләр башланган.

Арслан С. – эшләре уңай гына бара торган эшмәкәр. Танышым шәригать принципләры белән көйләнгән ислам банкингы гадел икътисад һәм сәламәт җәмгыятьнең нигезе дип ышанучы кешеләрдән. Килешүләрнең үтә күренмәлелеге, финанс килешүләрендә гарарны (билгесезлекне), процент алуны, уен бизнесына, алкоголь җитештерүгә һ. б. «пычрак» өлкәләргә кертелә торган хәрәм инвестицияләрне тыю – бу бит файдага! Партнёрлык финанслары буенча эксперимент кысаларында тәүге продуктлар барлыкка килә башлауга, Арслан беренчеләрдән булып әлеге процесска кушылып китә. Аның фирмасы инде берничә ел ислам исәп-хисап-касса хезмәтен-

нән файдалана, акчаларын ислам счетында тота. Бу аңа банк акчаларны хәләл булмаган максатлар белән «бутамас» дип ышанырга мөмкинлек бирә.

РӨХСӘТ ИТЕЛГӘН КЕШБӘК БӘРӘКӘТЕ

Сез аңлагансыздыр инде, танышым дини кеше. Пөхтә генә сакал, бераз кыскартылган мөселман чалбары – имиджының мәҗбүри өлеше. Үз вакытында аңлы рәвештә башкаладан Казанга күченә, чөнки монда тормыш рәвешен исламча алып бару мөмкинлекләре күбрәк дип саный. Сүз уңаеннан, бизнесы да шундый яшәү рәвеше нәтиҗәсендә туган: Арслан, мәсәлән, безнең илгә әнис (тмин) мае һәм ул кулланылган продуктлар, башка хәләл товарлар импорты белән шөгыльләнә.

Хәләл дебет карталары пәйда булгач, беренче булып шундый картаны ала. Ә хәләл кешбәклы партнёрлык дебет карталары барлыкка килүне гомумән бик шатланып кабул итә. Беренче эш итеп картаны үз балалары өчен ала. Аның дүрт баласы бар, икесе инде зурлар. Кешбәклы гадәти дебет карталары аларга кызык. Ләкин мөселманнарга андый карта туры килми: сатып алган өчен кешбәк түләү – асылда шул ук хәрәм банк проценты... Хәләл картада исә кешбәк банк тарафыннан түгел, ә товар сатучы тарафыннан түләнә: аерманы сизәсезме?

Бүген Арслан өчен дистәләгән партнёрлык продукты эшли. Бу продуктлардан ул гына түгел, башка мөселманнар да, шулай ук мөселман булмаган кешеләр дә файдалана ала. Иҗарадан (ислам лизингыннан, процент, пеня һәм штрафларсыз, аның бөтен срогы дәвамында килешүдә теркәлгән сумма күләмендә файдалану) алып ислам кануннарына таянып эшли торган инвестиция фондына кадәр. Ала гына түгел, инде файдалана да.

Ләкин Арслан максималист, төпле дөньяви белем алган кеше. Цифрлы технологияләр, бизнес бурычларын онлайн хәл итү – бу аның өчен биш вакыт намаз кебек үк табигый хәл. Һәм бу яктан караганда партнёрлык финансларына үсәсе дә, үсәсе әле.

– Шундый хәлне күз алдына китерегез: сез бер яхшы хәләл проект уйлап таптыгыз, финанс югалтулары куркынычларын исәпләп чыгарылган, бизнес-планыгыз төзелгән, инде инвестор табарга кирәк. Финанс йортына яисә ислам банкына партнёрлык инвестицияләре сорап мөрәҗәгать итү варианты бар. Әмма әлегә алар күп түгел, димәк, йөз процент уңышка ирешәм, дип ышанып булмый, – дип фикер йөртә Арслан. – Төбәкләр һәм дәүләтләр белән чикләнмәгән, ислам финанслары принциплары заманча технологияләр казанышлары белән берләштерелгән ислам (партнёрлык) капиталы базары кирәк. Ул чынлыкта ничек эшли? Маркетплейска тартым, тик финанслар буенча. Әйтик, бизнес вәкиленең һәм потенциаль инвесторның онлайн очрашуы, бер-берсенең мөмкинлекләрен (шул исәптән ислам нормаларына туры килү-килмәвен дә) онлайн бәяләве һәм партнёрлык килешүен дә онлайн төзү мөмкинлеге булган ниндидер инвестиция платформасын оештыру. Ә аннары килешүне гамәлгә ашыру процессының да чыннан да ислам нормаларына туры килүен шулай ук онлайн күзәтеп бару мөмкинлеге.

Фантазияме? Аннан бигрәк, вакыт таләбедер, минемчә. Алай гына да түгел, күптән түгел булган вакыйгалар күрсәткәнчә, бу теләк чынбарлыкка әйләнә башлады кебек.

ОНЛАЙН РЕЖИМДА – ХӘЛӘЛ

Беренче шундый вакыйга ярты ел элек булды, ләкин күпләр өчен сизелмичә диярлек үтте. Россиядә ислам нормалары буенча беренче төбәкара килешү имзаланды, дип тыйнак кына хәбәр итте масскүләм мәгълүмат чаралары. «СТАТУС-ИНВЕСТ» инвестиция платформасында «Амаль» финанс йорты Чечен Республикасындагы Шәех Зәйед* фондыннан 40 миллион сум акча җәлеп итте.

Барысы да яки барысы да диярлек танышым Арслан фаразлаганча булгандыр, дип уйлыйбыз. Килешүнең нечкәлекләре һәм анда катнашучыларның исемнәре, әлбәттә, аталмый, әмма безгә билгеле мәгълүмат та картинаны күз алдына китерергә мөмкинлек бирә. Партнёрлык финанслары ниндидер юридик затка кирәк булган, потенциаль инвестор табылган, шартлар килешенгән һәм килешү имзаланган. Барысы да онлайн режимда барган. Шул ук вакытта ике як та килешүнең һәм алга таба аны гамәлгә ашыруның ислам нормаларына туры киләчәгенә ышана. Финанс операциясенең чисталыгын Россиядә AAOIFI** сертификациясенә ия беренче белгеч – «Амаль» Финанс йортының тышкы шәригать эксперты Булат Мөлеков карап-күзәтеп торачак.

Әлбәттә, беренче килешү үк берәр зур инвестиция проектын озак вакытка финанслау үрнәге булыр, дип көтү беркатлылык булыр иде. Моны килешүдә каралган сумма да, Чечен Республикасында хатын-кыз таксие яки он җитештерү заводы кебек тыйнак стартапларга акча салучы инвесторның казанышлары исемлеге дә ачык күрсәтә. Килешүне оештыручы «ӘС СӘЛАМ»дә (ислам финанслары өлкәсендәге инвестицияләр платформасы) яшермиләр: кулланылган схема – инвестицияләр җәлеп итүчеләр өчен – касса өзеклекләрен каплау коралы, инвесторлар өчен – кыска вакытлы ликвидлык урнаштыру ысулы, ягъни депозитлар аналогы.

Ләкин болар барысы да детальләр генә. Иң мөһиме башкада. «ӘС СӘЛАМ» кулланучылар җәмгыяте идарәсе рәисе Ренат

** Эшмәкәрлеккә һәм инновацияләргә ярдәм итү буенча Шәех Зәйед исемендәге фонд 2017 елда оештырылган. Чечен Республикасында Фондны Эшмәкәрлекне үстерү халифе фонды (Khalifa Fund for fterprise Development) гамәлгә куйган.*

*** AAOIFI (Accounting and Auditing fganization for Islamic financial institutions) – ислам финанс учреждениеләренең бухгалтерлык хисабын һәм аудитын алып бара торган коммерциячел булмаган оешма, штаб-фатиры – Бәһрәйндә.*

Едиханов билгеләп үткәнчә, «әлеге вакыйга цифрлы инструментлар кулланыла торган заманча партнёрлык (ислам) капиталы базарын формалаштыру өчен Россиядә беренче килешү. Ул алга таба әлеге юнәлештә эшләр өчен нигез була ала». Нәкъ менә шундый операцияләр булачак партнёрлык капиталы базарының нигезен тәшкил итәчәк. Ислам финанслары принципларына таянган озак вакытлы инвестицияләр җәлеп итүгә килгәндә исә, бәлки, андый беренче тәҗрибәне без шул ук инвестиция мәйданчыгында терки алырбыз.

– Инвесторлар өчен төрле продуктларны диверсификацияләү максатыннан, акчаларны җәлеп итүнең төрле ысулларын эшләргә ниятлибез. Эш «ӘС СӘЛАМ» белән бергә алып барылачак. Бу исә Россиядә партнёрлык капиталы һәм тулаем ислам финанслары базарын үстерүгә яхшы этәргеч бирәчәк, – дип фикер йөртә «Амаль» Финанс йорты генераль директоры Рөстәм Сәгъдиев.

Алга таба нәрсә? Алда – иң мөһиме. Беренче килешүне оештыручылар фикеренчә, мөмкин кадәр күбрәк катнашучыны һәм потенциаль инвесторны платформада эшләргә җәлеп итәргә кирәк булачак. Ислам финанслары буенча экспериментта катнашучылар дәрәҗәсендә тотрыклы эшли торган капитал базары (партнёрский «межбанк») барлыкка килер, дип көтелә. Бу Россиягә чит ил инвестицияләрен җәлеп итү инфраструктурасын үстерү өчен җитди нигез булачак.

ИНВЕСТИЦИЯ МӘЙДАНЧЫГЫНДА ОЧРАШЫРБЫЗ

Инвесторлар һәм потенциаль партнёрларның хезмәттәшлеге өчен үзара файдалы шартларда оештырылган интернет-мәйданчыкка ислам финанслары базарында катнашучыларда ихтыяҗ булырмы соң? Күптән түгел партнёр белән инвесторның шул ук башкала интернет-платформасында узган яңа уңышлы очрашуы күпмедер дәрәҗәдә әлеге сорауга җавап бирә, дип уйлыйм. Бу юлы Шәех Зәйед исемендәге фонд белән «ӘС СӘЛАМ» компанияләр төркеме арасындагы төбәкара килешү продукты «цифрлы мудараба» булды. Акчалар сөт продукциясен күпләп сату белән шөгыльләнә торган компанияне финанслау өчен җәлеп ителә. Оештыручылар белдергәнчә, һәр продукт аерым структурлана торган серия буенча беренче килешү бу. Цифрлы продуктларның барлык вариантларын сынаганнан соң, базар төрле финанслау мөмкинлекләре булган азык-төлек исемлегенә ия булачак.

Арслан һәм Россиядә ислам кануннары буенча бизнес алып баручы башка эшмәкәрләрнең ихтыяҗ туганда цифрлы инвестиция мәйданчыгыннан файдаланырга әзер булуларында шик юк. Югарыда аталган инвестмәйданчыктан файдаланыргамы, әллә башка шуңа охшаш булганыннанмы – бусы алай ук мөһим түгел. Ихтимал булган чит ил партнёрлары һәм потенциаль инвесторлар – анысы инде башка мәсьәлә.

Сорауның технологик ягына килгәндә, без аларны гаҗәпләндерә алмабыздыр. Күп кенә Көнчыгыш илләрендә мөселман кулланучыларының уникаль ихтыяҗларын канәгатьләндерергә сәләтле инновацияле цифрлы финанс технологияләре уңышлы файдаланыла. Кулланучылар мәгълүматларын анализлау һәм индивидуаль киңәшләр бирү, чишелешләр тәкъдим итү өчен ясалма фәһем (интеллект) кулланыла. Тулысынча ислам принциплары нигезендә эшли торган цифрлы банклар да бар, алар шәригать кануннарына туры килә торган финанс хезмәтләренең тулы бер исемлеген тәкъдим итә, шул исәптән инвестицияләр һәм финанслау вариантлары буенча да. Алар арасында, аерым алганда, Bank Islam Malaysia, Insha, Alinma Bank бар.

Санкцион киртәләр тоткарлык булырга мөмкин. Әмма, мөгаен, аларны традицион финанс системасына альтернатива рәвешендә, блокчейн технологиясе кулланылган цифрлы чишелешләр ярдәмендә әйләнеп узу вариантлары табылыр. Проблема, мөгаен, финанс яссылыгында гына түгелдер.

ЧИКЛӘРСЕЗ БАЗАР ҺӘМ КИЛЕШҮГӘ ЮЛ БУЛАРАК СТАНДАРТЛАР

– Чит ил инвесторлары базарның үсүен, анда эшләргә мөмкин булуын аңлауга, инвес-

тицияләр килә башланачак, – диде ТР ИУА җитәкчесе Талия Миңнуллина ислам финанслары буенча түгәрәк өстәлләрнең берсендә. – Һәм хәзер дөнья партнёрлык финанслары базарында Россияне дөрес таныту мөһим. Тулаем алганда, дөньяда ислам финанс активларының гомуми күләме 4,5 трлн доллар, дип бәяләнә. Бу шактый зур акчалар, тик әлегә Россия Федерациясе аларны кулдан ычкындыра. Өстәвенә, бу активларның күп өлеше дустанә илләрдә урнашкан. Һәм бүген без ачыграк булсак, бу акчаларның илебез икътисадына эшләү мөмкинлеге туар иде. Халыкара инвестицияләр җәлеп итү максатында, мәгълүматны экспериментта катнаша торган төбәкләрдә яшәүчеләргә генә җиткереп калмыйча, ил чикләреннән чыгарга кирәк.

Ислам банкингы базарының эчке потенциалын да истән чыгарырга ярамый. Ул РФ Финанс министрлыгы тарафыннан 1 трлн сум дип бәяләнә, шул ук вакытта мөселманнар ил халкының якынча 20% ын гына тәшкил итә.

Әмма эчке һәм халыкара ислам финанслары базары куәтеннән максималь файдалану өчен, тәкъдим ителә торган продуктлар кырыс шәригать стандартларына туры килергә тиеш. Татарстанда базарга чыга торган продуктларны стандартлаштыру буенча ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең шәригать экспертлары җитди эш алып бара. Аларның уңай карары – тәкъдим ителә торган дебет картасының чыннан да хәләл булуына гарантия, ә иджара, ислам лизингы – чыннан да исламныкы, бернинди яшерен комиссияләрсез. Әмма шунысы да очрый: әлегә диния нәзарәтләренең критерийлары аерылырга мөмкин, әйтик, бер төбәктә финанс продукты хәләл дип танылган, ә башкасында – юк.

Моның чишелеше бармы соң? Мондый очракларда ислам илләре тәҗрибәсе һәм ислам дөньясында кабул ителгән гомуми стандартлар ярдәм итәргә тиеш. Бу уңайдан күптән түгел Бәһрәйндә ислам банкингы буенча AAOIFI белән хезмәттәшлек турындагы меморандум имзалауны һәм Россия Банкының AAOIFI составына кабул ителүен җитди алга адым, дип санарга мөмкин. Аңлатып китик: AAOIFI – Бәһрәйндә урнашкан халыкара оешма. Ул бөтен дөнья буйлап ислам финанс учреждениеләре өчен шәригать һәм аудиторлык стандартлары эшли.

«Татарстан, партнёрлык финансларын үстерү буенча Россиянең сынау төбәге буларак, киләчәктә сезнең оешма белән хезмәттәшлек итәргә, шул исәптән белгечләр әзерләргә, ислам финанслары өлкәсендә стандартлар кертергә тели», – дип билгеләп үтте Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов килешүне имзалаганнан соң. Аның сүзләренчә, AAOIFI тарафыннан эшләнгән стандартлар, финанслау һәм инвестицияләү мәсьәләләрен генә җайга салып калмыйча, эшчәнлекнең төрле өлкәләренә караган килешүләр төзү һәм үтәү өчен гомуми кысаларны да билгели.

Үтә күренмәлелек, ышаныч һәм бердәм стандартлар. Мөгаен, оешып кына килә торган ислам финанслары базарын чын-чынлап баетырга тиешле әчтәлек әнә шулардыр. Сорау белән тәкъдим, бер-берсенә этәргеч биреп, тиз һәм пропорциональ рәвештә үсә башлагач.

Һәм Арслан кебек эшмәкәрләр хәләл өлкәгә караган чыннан да файдалы бизнес-проект тәкъдим итә икән, кирәкле инвесторны цифрлы платформада табу үзен озак көттермәячәк.

СҮЗ УҢАЕННАН

Партнёрлык финанслары буенча экспериментның беренче нәтиҗәләре буенча, акчаларны урнаштыру буенча килешүләр портфеле **2,8 млрд сум** тәшкил иткән. 2024 елның 9 аена караган әлеге мәгълүматларны Россия Банкы китерә. **Бу операцияләрнең иң зур өлеше (43%) кичектереп түләү шарты каралган сату-алу килешүләренә туры килә**.

Акча җәлеп итү буенча операцияләр портфеле **3,8 млрд сумга** җитте, шуларның **45% – банкларда исәп-хисап һәм карта счётлары буенча операцияләр**. Мондый акчаларның яртысыннан артыгы юридик затларга карый.

Ислам финансларына караган килешүләр күләме буенча Татарстан Республикасы лидер булып тора. Килешүләр шулай ук Мәскәүдә һәм Мәскәү өлкәсендә, Чечен Республикасында, Башкортстан Республикасында, Түбән Новгород өлкәсендә һәм башка төбәкләрдә башкарыла.

Партнёрлык финансларын үстерү буенча эксперимент 2023 елның 1 сентябреннән башланды. Анда финанс оешмалары да, башка юридик затлар да катнаша ала. Экспериментта катнашучылар реестрын Россия Банкы алып бара.

ХАҖ СӘФӘРЕНӘ АКЧА ТУПЛАУНЫҢ ҖИҢЕЛ ҺӘМ ХӘЛӘЛ ЫСУЛЫ

«Амаль»* Финанс йорты ислам финанслары программасында катнашу аша Мәккәгә хаҗ кылырга хыялланучыларга ярдәм итә.

Хаҗ – изге урыннарга зиярәт кылу, исламның бишенче баганасы булып тора. Ул мөмкинлеге булган мөселманнар өчен мәҗбүри, хаждан соң кешенең барлык гөнаһлары кичерелә. Татарстанда яшәүче һәр мөэмин-мөселман үзенең хыялын тормышка ашыра ала. ТР мөселманнары Диния нәзарәтендә аңлатуларынча, соңгы ике елда республиканың 3800 кешесе Мәккәгә хаҗ кылган. Гомумән, Россиягә елына 25 000 квота бирелә. Ул, дин тотучылар санына карап, төбәкләр арасында бүленә. Татарстан өчен инде күп еллар бу сан үзгәрешсез кала (пандемия чорын санамаганда) – 1 800 кеше.

Рәсми хаҗ операторы «ТР мөселманнары Диния нәзарәте» мәгълүматларына караганда, Татарстан мөселманнары өчен хаҗ кылуның берничә программасы эшләнгән. Бәяләр, урнашу шартларына карап, 4 400 доллардан 12 600 долларга кадәр. Шул ук вакытта барлык юлламаларга, бәясенә карамастан, юл йөрү һәм трансфер, яшәү һәм туклану, медицина хезмәте күрсәтү, имамны озата бару, документлар рәсмиләштерү һәм укыту чыгымнары, зәмзәм суы һәм хаҗи комплекты бәясе керә. Хаҗи комплектында кирәкле әдәбият һәм рюкзак бар.

Шактый кызыклы, әмма дүрт программаның иң арзаны да 4 400 доллар тора. Әлеге материалны язу вакытындагы доллар курсы буенча бу 370 мең сум дигән сүз. Хәтта бик каты теләгән очракта да һәр кеше әлеге чыгымнарны күтәрә алмый. Хәер, мондый сәфәрнең беркайчан да арзан булганы юк. Бер генә юл кала – акча җыярга. Борын-борыннан кешеләр хаҗга дип акча туплаганнар, булганны бәрәкәтләрәк тотып, артыгын алып куя барганнар.

Ләкин менә инде берничә ел күпкә нәтиҗәлерәк туплау ысулы эшли башлады. «Амаль» Финанс йорты «Кәгъбәгә юнәлеш» дип аталган тариф программасына кушылырга тәкъдим итә. Ул Мәккәгә юлны җиңеләйтә. Шактый мөселман, «Амаль» Финанс йорты белән хезмәттәшлек итеп, әлеге ысулдан файдаланган да.

Программаның принциплары түбәндәгеләр:

1. Акча туплауны үзегез өчен кулай теләсә кайсы суммадан башларга мөмкин, мәсәлән, 10 000 сумнан.
2. Акчаны үзегез өчен уңайлы режимда даими салып бару каралган: ай саен, квартал саен яки бер тапкыр.
3. Керем хәләл: акча ислам финанслары принциплары нигезендә эшли.
4. Ышанычлылык: 2010 елдан оешма тотрыклы табыш күрсәтә һәм ике дәрәҗәдәге шәригать контроле астында эшли.
5. Максат гарантиясе: акча туплана барган саен, кирәкле суммага күпме җитеп бетмәгәне күренеп тора, һәм сез ышанычлы рәвештә хыялыгызга таба атлыйсыз.

Шул ук вакытта инвесторлар счетындагы сумма өйдә акча җыюга караганда тизрәк үсә, һәм тагын хәләл гарантиясе дә мөһим. Ислам банкингында төп тыю процент керемнәренә кагыла, шулай ук финанс структураларына хәмер, тәмәке җитештерү, дуңгызчылык, комарлы уеннар бизнесы һ.б. кебек хәрәм өлкәләргә инвестицияләр кертү тыела. Табыш инвестицияләрдән килә, шуңа күрә ислам банкингының киң таралган операцияләре – кичектереп түләү, лизинг, өлешләп финанслау.

«Хаҗ – күңел халәте, йөрәк кушкан юл. Без аны финанс ягыннан борчуларсыз үтәр өчен ярдәм кулы сузарга әзер. Бүген туплый башлагыз, хыялыгыз тизрәк чынга ашар!» – дип ышандырдылар «Амаль» Финанс йортында.

Фото: amal.ru. РЕКЛАМА. «Амаль» Кулланучылар җәмгыяте

* Юридик исеме – «Амаль» КҖ.

ТӨБӘК ЛИЗИНГЫНЫҢ 5 УҢАЙ ЯГЫ

Дмитрий Сивков

«Татарстан Республикасы Төбәкара лизинг компаниясе» генераль директоры Станислав Королёв – җитештерү белән сатып алучы кооперациясенең өстенлекләре турында.

– Станислав Валерьевич, сезнең компаниягез базарда үзен ышанычлы партнёр буларак танытты. Сез моңа беренче чиратта нәрсәгә таянып ирешә алдыгыз?

– Без 2017 елда ТР Икътисад министрлыгына карый торган ведомство оешмасы буларак беренче адымнарыбызны ясадык – әнә шуннан башлыйк әле. Компаниянең төп миссиясе – төбәкара икътисадның реаль секторын үстерү. Бу максатка ирешер өчен, станоклар белән җиһазлар, күчемсез милек объектлары, шулай ук махсус техниканы урта һәм кече бизнес предприятиеләренә лизингка бирү буенча ташламалы ставка рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтәбез.

– Сез тәкъдим иткән хезмәтләрнең төп плюсларын, ягъни уңай якларын билгеләп үтик әле?

– Безнең клиентлар шактый зур өстенлекләргә ия була. Шуларның кайберләренә генә тукталам.

1. Республика бюджетыннан лизинг буенча елга 8% тан башлап ташламалы ставка белән дәүләт ярдәме алу мөмкинлеге.

2. Икътисадның реаль секторына ярдәм итү – Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан җитештерү предприятиеләре үзләренә стимул ала. Бигрәк тә бу сәнәгать өлкәсендә әһәмиятле: үзебездә җитештерелә торган станоклар, җиһазлар, сәнәгать роботлары белән махсус техника турында сүз бара. Татарстан Республикасы индустриаль парклары резидентларына ярдәм итү максатында күчемсез милек объектларын алуга юнәтелгән лизинг продукты булдырылды.

3. Предприятиегә әйләнештә булган акчаларны лизинг предметының тулы бәясе күләмендә чыгарырга кирәк булмаячак.

4. Предприятиегә коммерцияле банкта йә булмаса лизинг компаниясендә югары процентлы кредит түләргә кирәк булмаячак.

5. Килешү максатчан характерда башкарыла. Предприятие акча түгел, ә кирәкле лизинг предметына ия була. Бу дәүләт ярдәменең максатчан кулланылуын контрольдә тотарга булыша.

– Татарстан партнёрлык финансларын үстерүдә катнашучыларның берсе. «Татарстан Республикасы ТЛК (Төбәкара лизинг компаниясе) АҖ продуктлары исемлегендә «Ислам лизингы (иджара)» дигән хезмәт тә тәкъдим ителгән. Бу хакта тулырак сөйли алмассызмы икән?

– Монда мин игътибарыгызны өч нәрсәгә юнәлтер идем. Беренчедән, иджара – ул аренданың билгеле бер төре, ягъни, башка тел белән әйткәндә, ислам лизингы. Аның шартлары буенча нинди дә булса предмет арендаторга, алга таба ул бу предметны сатып алу шарты белән, аренда түләүләренә алмашка бирелә. Икенчедән, «иджара» килешүләрендә милекне куллану буенча процент ставкасы булмый, ә менә гадәти лизингларда ул күздә тотыла. Өченчедән, иджара очрагында лизингка махсус техника, коммерцияле автотранспорт бирелә, лизинг срогы - 5 ел.

Әлеге финанс коралы Татарстан Республикасы Диния нәзарәтендә 2023 елның 4 августындагы 417-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә җавап бирә, дигән хуплау алды.

Бүген, заманча технологияләр күз иярмәс тизлек белән үсеш алган, ә җитештерү белән бизнесның эшләү шартлары зур таләпләргә җавап бирергә тиеш дип исәпләнгән дөньяда, лизинг финанслауның бик үтемле коралларының берсенә әверелеп бара. Бу бигрәк тә җиһазларга, роботлашкан һәм махсуслашкан техникага ихтыяҗ югары булган тармакларда эшли торган компанияләр өчен актуаль. Ташламалы шартлар тәкъдим итү буенча дәүләт акчаларын куллана торган лизинг компанияләре әлеге процесста гаять әһәмиятле, хәтта ки хәлиткеч роль уйный, дип әйтә алам.

«Татарстан Республикасы Төбәкара лизинг компаниясе» АҖ
Татарстан Республикасы, Казан ш., Петербург ур., 28 йорт
sales@rlcrt.ru
8 (843) 524-72-32, 8-917-279-95-49

Фото «ТР Төбәкара лизинг компаниясе» АҖнән алынды. РЕКЛАМА



«ТИМЕР БАНК» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕННӘН ИСЛАМ КАРТАСЫ СЕЗНЕҢ ПРИНЦИПЛАРГА ҖАВАП БИРӘ

Дмитрий Сивков

Татарстан Республикасын да кертеп, дүрт төбәктә тормышка ашырыла торган партнёрлык финанслары (икенче төрле әйткәндә, ислам банкингы) программасы буенча эксперимент Россиядә ел ярым элек башланып киткән иде. Бүген ул торган саен колачлырак була бара. Ислам банкингы инструментларын кулланып башкарылган килешүләрнең күләме дә, экспериментта катнашучылар саны да арта. Хәзерге вакытта Россия Банкының әлеге тәҗрибәсендә катнашучылар реестрына 30 финанс оешмасы теркәлгән, шуларның яртысыннан күбрәге Татарстанда да эшли. Алар арасында реестрга 2024 елның 9 сентябрендә кертелгән «Тимер Банк» акционерлык җәмгыяте дә бар.

– Антон Андреевич, сезнең банк ни өчен партнёрлык финанслары белән кызыксына башлады? – «Тимер Банк» акционерлык җәмгыяте Идарәсе рәисе Фомин Антон Андреевич белән әңгәмәбез шушы сораудан башланып китте.

– «Тимер Банк» һәрвакытта да Татарстанда яшәүчеләрнең ихтыяҗларына җавап бирергә омтыла. Республикада партнёрлык финанслары кысаларында тәкъдим ителә торган продуктлар белән кызыксынучылар бар. Әлегә ихтыяҗ зур булмаса да, мондый продуктларның кирәклеген, практика да, финанс аналитикларының фаразлары да күрсәтә.

Әйтергә кирәк, безнең банкның тамырлары Татарстаннан. Без Татарстан Республикасында 30 елдан артыграк эшлибез. Банк 1991 елда «Идел-Чулман акционерлык банкы» исеме белән «Финист-банк» Яшьләр коммерция банкының Татар филиалы нигезендә теркәлгән, шуңа да без Татарстанда шактый киң масштабта эшлибез. Казандагы дүрт офистан тыш, Әлмәттә, Түбән Камада, Алабугада, Бөгелмәдә һәм Яшел Үзәндә өстәмә офисларыбыз бар.

Партнёрлык финанслары юнәлеше безнең илдә яңарак кына кулланыла башласа да, без аның перспективалы булуына ышанабыз.

– Партнёрлык финанслары буенча клиентларыгызга нинди продуктлар тәкъдим итәргә әзер?

– Безнең беренче продуктыбыз – ислам картасы чыкты.

– Ислам картасының гадәти банк картасыннан аермасы нәрсәдә?

– Асылда, ислам картасы барыбызга да таныш дебет картасы кебек үк, шулай да кайбер аермалар бар. Беренчедән, мондый карта белән шәригать нормаларына каршы килми торган товар һәм хезмәтләр өчен түләргә була, ягъни бу карта белән күңел ача, уйный торган урыннарда исәп-хисап ясап булмый: барларда, төнге клубларда, букмекер контораларында, шулай ук хәмер һәм тәмәке кибетләрендә, ломбардларда, микрофинанслар бирә торган пунктларда һәм иминият оешмаларында.

Икенчедән, акчалар аерым санала, бу исә аны банк үз карамагында файдалана ала торганнары белән бутап булмый дигән сүз.

Өченчедән, ислам картасында калган акчага процентлар килми. Ягъни бу карта – хәләл. Ул партнёрлык финанслары кысаларында эшләнгән теләсә кайсы продукт кебек үк банк тарафыннан Россия ислам институты (Казан ш.) каршындагы Россия ислам икътисады һәм финанслары үзәге хезмәткәрләре катнашында эшләнгән һәм мөселманнарның Диния нәзарәтендә килештерелгән.

– Банкоматларда тере акча алу яки сатып ала торган товарга онлайн түләү буенча ничек?

– Онлайн да, офлайн да сатып алырга, тере акча алырга яки күчерергә була. Сүз уңаеннан, тере акчаны комиссиясез генә Россия территориясендәге теләсә кайсы банкның банкоматларыннан алып була. Мондый картаны эшләп чыгарган һәм тәэмин иткән өчен аерым түләргә кирәк түгел.

Әлбәттә, банк ислам банкингы продуктлары исемлеген киңәйтергә, картадан тыш, партнёрлык финанслары кысаларында башка продуктларны да әйләнешкә кертергә планлаштыра. Бу җәһәттән без әле юл башында гына. Һәм бу юлны без Татарстанда яшәүче кешеләр белән бергәләп үтәрбез, дип ышанабыз.

Фото: «Тимер банк» АҖнән алынды. РЕКЛАМА

GARANT

FINANCIAL SERVICE

ТЫШКЫ ИКЪТИСАДЫЙ ЭШЧӘНЛЕК ӨЧЕН ОПТИМАЛЬ КАРАРЛАР - БӨТЕН ДӨНЬЯ БУЕНЧА РӨХСӘТ ИТЕЛГӘН ВЭД-ОПЕРАЦИЯЛӘР

RSI GARANT - тышкы икътисадый эшчәнлеккә халыкара хезмәт күрсәтү

Төрле юрисдикциядәге компанияләргә легаль түләү операцияләрен үткәрергә булышабыз

Бизнеска халыкара стандартлар исәпкә алынган карарлар тәкъдим итәбез

Консультацияләр бирәбез һәм килешүләр вакытында шәхси ярдәм күрсәтәбез

Уңайлы һәм ышанычлы булсын өчен, халыкара исәп-хисап процессларын оптимальләштерәбез

Безнең экспертан консультация алыгыз – QR-кодны сканлаштырыгыз һәм күбрәк белегез!

@rsi_garant

Реклама. “Эр-Эс-Ай Капитал” ҖЧҖ

БЕЛЕМ БИРҮ ЮНӘЛЕШЛЕ «БАЙТИК»

КУРОРТЫ ЮБИЛЕЕН КАРШЫЛЫЙ

Евгения Чеснокова

Казанның Крутушка бистәсендәге белем бирү юнәлешендә эшли торган «Байтик» лагере безне язгы кояш нурларына күмелеп каршы алды. Сукмаклар инде кардан арынган. Элекке вакытлардан калган мирас – гипстан ясалган пионер кыз безгә чәчәк бәйләме суза. Хәер, ул «Байтик»ка килүчеләрнең барысын да шулай каршылый. Бу көнне бирегә дөнья мәдәнияте буенча бөтенроссия укучылар олимпиадасында катнашучылар килә башлады. Корпуслар инде балалар тавышыннан гөр килә. Башка күп кенә лагерьлардан аермалы буларак, «Байтик» ел әйләнәсе эшли. Бу «Байтик» савыктыру-белем бирү комплексы ачылган 2000 елдан бирле шулай дәвам итә.

КАЗАНСУДА, ЗӘҢГӘР КҮЛЛӘР БУЕНДА

Ләкин барысы да 25 ел элек кенә түгел, тагын да иртәрәк башлана. 1994 елдан Биектау районының компьютер үзәге укучылар һәм укытучылар өчен мәгълүмат технологияләре дәресләре үткәрә башлый. Ә җәй көне үзәктә эшләүче педагоглар район мәктәпләре балалары өчен IT профильле сменалар оештыра. Берничә елдан аларга элеккеге «Вымпел» пионер лагере территориясендә төпләнергә тәкъдим итәләр.

– Без монда килгәндә, әлбәттә, бөтен җир җимерек иде, – дип искә ала «Байтик» директоры Лариса Бикмуллина. – Корпуслар тузган, тәрәзәләре ватылган, коймалар бөтенләй калмаган... Бүген кунаклар фотога төшәргә яраткан пионер сыннарыннан да арматурага беркетелгән ватык бетон кисәкләре тырпаеп тора. Балалар белән бергә, без аларны рәткә китердек, буядык…

Әмма «Байтик»ны оештыручыларның нәкъ менә шушында, Зәңгәр күлләрдән ерак түгел, Казансу буенда каласы килә. Аларга бу урыннарның табигате дә ошый, курорт диярсең! Юкка гына янәшәдә шифаханә салынмаган, Казаннан да ярты сәгатьлек юл. Территориягә төзекләндерә башлыйлар, балалар шөгыльләнә алсын өчен, төп бинага ут, җылылык, интернет үткәрәләр. Һәм 2000 елның җәендә «Байтик» тәүге укучыларын кабул итә. Беренче сменага йөз бала килә. Чагыштыру өчен: хәзер бер сменада кирпеч биналарда 500 дән артык бала ял итә. Ә «Байтик» территориясендә чагыштырмача күптән түгел генә барлыкка килгән җәйге палаткалы лагерьны исәпкә алсак, тагын да күбрәк.

ДУСЛАШЫРГА, УКЫРГА, ҮЗЕҢНЕ ТАБАРГА

«Байтик»ны еш кына компьютер лагере дип атасалар да, оештыручылар, ди Лариса Бикмуллина, балаларның биредә программалаштыруга гына йөз тотмаячагын баштан ук аңлап эш итә. Бүген, мәгълүмат технологияләре һәм робот техникасыннан тыш, укучылар космик технологияләрне өйрәнә, архитектура, театр, мультипликация, кулинария, чит телләрне өйрәнү белән

Фотолар: Александр Ефремов, «Байтик» савыктыру-белем бирү комплексыннан алынды. РЕКЛАМА

шөгыльләнә ала... Әлбәттә, спорт та ят түгел. Өстәвенә, «Байтик» территориясе спорт уеннары ягыннан бик күп мөмкинлекләргә ия – футбол, волейбол, бадминтон уйнау, хәтта атта йөрүләр өчен дә шартлар бар.

Шуңа да карамастан, мәгълүмат технологияләрен алга этәрүне «Байтик»ны оештыручылар төп бурычлары дип санаган һәм саный.

– Безнең педагоглар, вожатыйлар, оештыручылар бергәлеге елдан-ел тыгызрак туплана бара, – дип сөйли Лариса Бикмуллина.

Хәзер «Байтик»та йөзгә якын кеше – администраторлар, инженерлар, методистлар, программистлар, пешекчеләр, табиблар, горничныйлар даими эшли. Күп кенә белем бирү программалары педагоглары һәм вожатыйлар «Байтик» белән инде озак еллар хезмәттәшлек итә. Сүз уңаеннан, алар арасында кайчандыр бирегә мәктәп укучысы буларак килүчеләр дә шактый һәм бу гадәти хәл, ди Лариса Владимировна. Әгәр кешегә бу урында яхшы һәм кызык икән, ул бирегә һичшиксез кире кайтачак. Ә лагерьда моның өчен бөтен шартлар тудырылган.

Әлбәттә, 25 ел эчендә яшь буын сизелерлек үзгәргән, әмма «Байтик»та балалар белән эшләү принциплары шул ук: балаларның фикерен тыңлыйлар һәм хөрмәт итәләр, аларның мөстәкыйльлеген һәм инициативалылыгын хуплыйлар, ә дәресләрне мавыктыргыч итәргә тырышалар.

«Байтик»та тәрбияләнүчеләрнең күбесе соңрак чыннан да үзләрен IT-өлкәдә таба һәм һөнәрләрендә зур уңышларга ирешә. «Байтик» педагогларын тагын бер нәрсә сөендерә: лагерьда дуслашкан балалар соңыннан олы тормышта да дуслыкларын дәвам итә. Димәк, лагерь үз бурычын үти: аның тирәсендә профессионаллар гына түгел, ә чын фикердәшләр берләшмәсе барлыкка килә.

КРУТУШКАДА – ШӘП!

...Без яңа ике катлы бинага керәбез – быел «Байтик»та иске, бер катлы биналар урынында барлыкка килгән өч бинаның берсе ул. Корпусларның берсендә – чүлмәк ясау остаханәсе, икенчесендә – уңайлы кухня-студия, анда балалар «ВкусноБайтик» программасы дәресләрендә пешерергә өйрәнәләр (сүз уңаеннан, лагерьда биш тапкыр туклану каралган, ә тагын чын рус миче бар – кулинария дәресләрендә аннан да файдаланалар!).

Олимпиадага укучылар алып килгән Мәскәү педагоглары өстәл артында кофе эчәләр иде. Үзләрен нәкъ менә «Байтик»ка урнаштыруларына шат алар. Кунакларны вак-төякләрдә үк сизелеп торган кайгыртучанлык һәм матурлык аеруча сокландыра. Һәрнәрсәдә уңайлылык – заманча техника һәм аудиторияләрне җиһазлау гына түгел, ә зәвыклы дизайн да һәм менә шулай, хезмәттәшләр белән кофе эчеп, алда торган бурычлар турында фикер алышу мөмкинлеге дә.

«Байтик»ны бүген еш кына зур конкурслар, олимпиадалар, семинарлар уздыру өчен сайлыйлар. Әлеге курортта эшләве – уңайлы, ял итүе – рәхәт.

Күп кенә бөтенроссия чаралары «Байтик» белән хезмәттәшлектә уза. Аларны оештыручылар лагерьның белем бирү һәм агарту программаларыннан илһам ала. Мәсәлән, ел саен унбиш ел дәвамында августта бирегә «Крутушка» халыкара этнофестивале үткәрелә – анда дөньякүләм этник музыка йолдызларының зур концерты, ярминкә, музыка, һөнәрчелек, кулинария мастер-класслары каралган... Бу проекттан «Крутушка. Балалар» – фольклор юнәлешендәге балалар иҗат коллективлары өчен бөтенроссия белем бирү этномәдәни сменалары пәйда була. «Байтик»та мондый сменаның чираттагысын апрель ахырында көтәләр – бу юлы Россия балалар фольклор ассамблеясе узачак. Смена остазлары һәм жюри әгъзалары – «Крутушка» фестиваленең мактаулы кунаклары һәм экспертлары. Үзенең атмосферасы һәм нәтиҗәлелеге буенча бу проект уникаль. Балалар, диңгездә ял итүгә караганда «Байтик»ка өстенлек биреп, бирегә килергә тырыша.

– Бездә көньяктагыдан бер дә ким түгел, – дип елмая Лариса Бикмуллина. – Балалар өчен шифаханәдәге кебек шартлар тудырылган, табигать диңгез буеныкы кебек үк булмаса да, бик матур...

Һәм, гомумән, Россия балаларының тулы канлы ял һәм белем алулары өчен мөмкинлекләр никадәр күбрәк тудырылса, барыбызга да шулкадәр яхшырак булачак, дип саный «Байтик» директоры.

Ә без, лагерь буйлап йөреп, сер итеп кенә шуны әйтик: «Байтик»та чыннан да бик шәп!

Казан ш., Бондаренко ур., 26, 315 нче оф.
+7 (843) 240-54-45
t.me/lagerbaytik
bronp@mail.ru
baytik-kazan.ru
vk.com/baytik_kazan

ИТ-ГРАМОТАЛЫЛЫК – ЯҢА MUST-HAVE: КАЗАНДА «ЦИФР ДӘРЕСЛӘРЕ» ҮТТЕ

Олеся Бондаревская

Инженер, юрист һәм логистны нәрсә берләштерә? Җавабы һич тә көтелмәгәнчә яңгырый – мәгълүмат технологияләре. Цифрлы һөнәрләр иртәгәге көннең йөзен билгеләячәк. Бу турыда мәктәп укучыларына IBR компаниясенең үсеш буенча директоры Юлия Лунина сөйләде.

ИТ-программаларның нинди принципларга таянып корылуын аңлау бүген аны эшләүченең күнекмәсе генә түгел, ул – һәркемгә теләсә кайсы эшне нәтиҗәле итеп башкарып чыгу мөмкинлеге бирә торган универсаль код. Бу турыда «Цифр дәресе» Бөтенроссия уку-укыту проекты спикерлары Казанның 98 нче мәктәбе һәм Лицей – инженерлык үзәгендә мартта үтә торган чаралар кысаларында сөйләде. Очрашулар ТР Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү министрлыгы белән ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы ярдәмендә үткәрелде, анда **IBR (Мәгълүмати бизнес-карарлар)** һәм «1С» компанияләренең вәкилләре төп катнашучылар булды.

– Бүген программалаштыру аны эшләүчеләргә генә мөһим дип әйтеп булмый. Ул юрист, табиб, фермер, дизайнер – һәркем белергә тиешле тел кебек, – диде «Цифр дәресе»ндә ТР дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү министры урынбасары Булат Габдрахманов. Технологик яктан белемле булу тел һәм табигый-фәнни яктан грамоталы булу белән бер рәттә тора, дип басып ясады ул. ТР Цифрлы үсеш министрлыгы вәкиле укучыларны үсеш өчен бөтен мөмкинлекләрдән файдаланырга чакырды:

– Уңышка ирешкән стартаперлар белән сезнең арада упкын ята дип уйламагыз. Бүген 150 миллион кеше уйный торган Standoff уенын Сарман белән Кукмара егетләре уйлап чыгарды. Мөмкинлекләр бар, тик утырмаска гына кирәк!

БЕЗНЕ ҮЗГӘРТӘЧӘК КИЛӘЧӘК

«1С» вәкиле Никита Кареев алгоритмнар ярдәмендә теләсә кайсы процессны оптимальләштерергә мөмкин икәнне күрсәтте – мәктәп ашханәсендәге чиратлардан алып, складтагы логистикага кадәр. Спикер low-code* технологиясенең мөмкинлекләре турында сөйләде. Аның ярдәмендә программалаштыру өлкәсендә әллә ни тирән белемнәргә ия булмасаң да, ИТ-продуктлар эшләп булуын күрсәтте. Шул ук вакытта Никита Кареев:

– Яшь программалаштыручылар еш кына башкалар эшләгәнне кабатлый, мәсьәлә катлауланса, төртелеп кала. Нигезне, ягъни «тимер»не, төп һәм башка популяр телләрне өйрәнергә кирәк, – дип басым ясады.

Юлия Лунина программалаштыручыларның масштаблы һәм ин-

* Түбән код.

Фотолар ТР Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү министрлыгыннан алынды. РЕКЛАМА

новацияле проектлар эшләгәндә үз күнекмәләреннән файдалануы турында сөйләде. Эксперт цифрлы технологияләрнең тормышның барлык өлкәләренә – медицинадан башлап, төзелешкә кадәр үтеп керүен аңлатты, киләчәккә бүгеннән үк әзерләнә башларга кирәк, диде:

– Якындагы 10-15 елда бик күп һөнәрләр үзгәреш кичерәчәк. Технологияләр хәтта югары квалификацияле белгечләрне дә кысрыклап чыгарырга мөмкин. Аның каравы, яңа юнәлешләр барлыкка киләчәк. Моңа әзер булырга һәм яңа һөнәрләр үзләштерергә кирәк, системалы фикерләү, проектлар белән идарә итү күнекмәләре, билгесезлек шартларында эшли белү, күптеллелек, ясалма фәһем һәм робот техникасы өлкәләрендә белемнәр алырга вакыт.

ЯШЬ ВАКЫТТА УКЫП КАЛ

IBR компаниясе – Татарстанның ИТ-базарында лидерларның берсе. Ул 1С юнәлешендә эшли. Юлия Лунина аудиторияне IBRның зур проектлары белән таныштырды. Бу – зур сәүдә челтәрләре, машина төзелеше предприятиеләре, АЗС челтәрләре һ.б. белән идарә итүне автоматлаштыру. Спикер сүзләренә караганда, IBR бөтен бурычларын проектлар рәвешендә команда белән эшләү аша башкара. Сүз уңаеннан, «Цифр дәресе»н тыңлаучылар үзләре теләсә һәм компетенцияләре рөхсәт итсә, тиздән командага кушыла ала.

– Без вузлар белән эшлибез, студентларны укытабыз, хезмәткәрләребезнең soft һәм hard skills дәрәҗәсен үстерәбез. IBRда техник белемнәр генә түгел, клиент белән эшли, конфликтларны уңай хәл итә белү, элемтәләр урнаштыра алу да югары бәяләнә. Хәтта цифрлы этикет һәм эмоциональ интеллект та – безнең эштә мөһим компетенция, – дип сөйләде Юлия Лунина.

Бүген IBR – ИТ-компания генә түгел, ә яшь белгечләрне үзенә тарту үзәге дә. Биредә һөнәри ориентация башлангычларына һәрвакыт хәерхаһлык күрсәтәләр, стажировкалар үткәрәләр, укытуда тармакның чынбарлыктагы бурычларына якын итеп оештырылган яңа модельләрен эшлиләр. Компания кадрларның системалы рәвештә үсүенә булышлык итә: хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрүдән әре тармак форумнарында катнашуга кадәр.

ҺӘРКЕМГӘ АҢЛАЕШЛЫ «ЦИФР»

«Поларис» челтәрендә хисапны автоматлаштыру, КАМАЗларны ремонтлауны диспетчерлаштыру, фураларның маршрутларын Яндекс-сервислар ярдәмендә оптимальләштерү – бу кейсларның барысын да IBR компаниясе мәктәп укучыларына программалаштыруның һәм системалы рәвештә фикерләүнең практикада – тормыштагы бизнеста ничек эшләве үрнәге итеп күрсәтте.

– Мондый очрашулар укучыларның офыкларын киңәйтә һәм яшьтән үк кирәкле һөнәр сайлавына ярдәм итә, – дип билгеләде Лицей – инженерлык үзәгенең өстәмә белем бирү буенча директор урынбасары Руфина Дәүләтбаева. – «Цифр дәресе» безнең лицейның тармак белгечләре белән очрашу буенча программасының ачык бер дәвамы булды.

– Дәрес чыннан да миңа яңа офыклар ачты, – ди 98 нче мәктәпнең 8 сыйныф укучысы Кира Семенова. – Киләчәктә инженерлык юнәлешендә белем алырга телим, анда шулай ук компьютерлар һәм программалаштыру белән эшли белү таләп ителә. Хәзер инде бу теманы тирәнрәк өйрәнергә җыенам.

ТАТАРСТАН ПАРТНЁРЛЫК

2024 ЕЛДА

ҖӘЛЕП ИТЕЛГӘН
АКЧА КҮЛӘМЕ

2,5
ТАПКЫРГА АРТКАН



5,4 млрд сум

РЕСПУБЛИКАСЫНДА ФИНАНСЛАРЫ

ЭКСПЕРИМЕНТ КЫСАЛАРЫНДА:

ФИНАНСЛАНГАН КИЛЕШҮЛӘР КҮЛӘМЕ

4,3 млрд сумлык

13 меңнән артык кеше

УКЫГАН

30 дан артык продукт

ЭШЛӘНГӘН ҺӘМ ГАМӘЛГӘ АШЫРЫЛГАН

24 мең данәдән артык

ДЕБЕТ КАРТАСЫ БИРЕЛГӘН

БИЗНЕСНЫҢ ХӘБӘРДАРЛЫГЫ

20% ка АРТКАН

ХАЛЫКНЫҢ ХӘБӘРДАРЛЫГЫ

25%ка АРТКАН

МАССАКҮЛӘМ МӘГЪЛҮМАТ ЧАРАЛАРЫНДА

1600 дан артык

МАТЕРИАЛ БАСЫЛГАН

КЕЧЕ ҺӘМ УРТА ЭШКУАРЛЫККА

240 млн сумлык

ЯРДӘМ КҮРСӘТЕЛГӘН

РОССИЯ БАНКЫ РЕЕСТРЫНДАГЫ **30** ОЕШМАНЫҢ **22се** ТАТАРСТАНДА ЭШЛИ

ХӘЛӘЛ – СӘҮДӘ ҮСЕШЕНӘ КӨЧЛЕ ЭТӘРГЕЧ

Сафа Гәрәев

2024 ел йомгаклары буенча Татарстанда хәләл продукция экспорты 12 миллион долларга якынны тәшкил итә. Саллы сан – әле алты ел элек үк республика чит илләргә мөселман кануннарына туры килә торган 300 мең долларлык продукция сата иде. Әмма бүгенге казаныш – киләчәк юлының бер этабы гына: хәләл дөнья базарында инде 8 триллион долларлык продукция сатыла. Татарстан да бу базарда лаеклы урынын табарга җыена.

Татарстанда җитештерелгән хәләл продукцияне чит илләргә сату динамикасы берничә ел дәвамында тотрыклы үсеш күрсәтә. Беренче җитди алга китеш 2020 елда теркәлгән. Ул вакытта республика 2,5 миллион долларлык хәләл агросәнәгать продукциясен экспортлаган. Бу аннан алдагы ел белән чагыштырганда сигез тапкырга күбрәк дигән сүз. Мондый җитди саннарга ирешү очраклы

Фотолар: spas-rt.ru, ТР ИУА матбугат хезмәте, tatar-inform.ru, halalrt.ru

гына түгел. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов, «Россия – Ислам дөньясы: KazanSummit 2019» XI халыкара икътисадый саммитының пленар утырышында чыгыш ясап, хәләл экспортны үстерү һәм аны тышкы сәүдәнең мөһим өлешенә әйләндерү бурычын куйды. Республиканың ислам дөньясы белән эзлекле рәвештә икътисадый элемтәләрен ныгытуы аны хәл итү өчен нигез булып тора.

ҮСЕШ БАСКЫЧЛАРЫ: САНКЦИЯЛӘРГӘ КАРАМАСТАН

Ислам илләре базарында уен кагыйдәләрен, потенциаль ихтыяҗны, маркетинг кампанияләрен һәм предприятиеләребезнең хәләл стандартларына туры килә торган сыйфатлы продукция җитештерү сәләтен өйрәнү үзенең уңай нәтиҗәләрен бирә. ТРның чит илләргә хәләл продукция сату күләме тотрыклы үсә. 2023 ел нәтиҗәләре буенча алар инде 11 миллион ярым долларны тәшкил итә, бу аннан алдагы ел күрсәткеченнән 177 процентка артыграк дигән сүз.

Узган елда зуррак үсешкә исәп тотсалар да, экспорт күләме әллә ни артмаган. Хәләл продукцияне 16 миллион долларга сату планлаштырылган иде. Санкцияләр басымы, ни кызганыч, бушка узмый: логистика һәм үзара исәп-хисаплар белән проблемалар хәләл товарлар экспортын тоткарлый, гәрчә импортерларыбыз дустанә илләр булса да... Хәер, барлык проблемалар да хәл ителерлек.

ИТ ҺӘМ МАЙДАН АЛЫП, КОНДИТЕР РИЗЫКЛАРЫ ҺӘМ СОККА КАДӘР

– Бүген Татарстанда җитештерелгән хәләл продукцияне төп сатып алучылар арасында – Фарсы култыгы, Таможня берлеге һәм Төньяк Африка илләре. Бу, аерым алганда, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Согуд Гарәбстаны, Казахстан, Кыргызстан, Мисыр, Алжир, Бразилия, Гыйрак... – дип сөйләде ТР Премьер-министры урынбасары – авыл хуҗалыгы министры Марат Җәббаров. – Бездән нигездә сөт, ит һәм кондитер продукциясе сатып алалар. Хәләл кондитер әйберләре экспортерлары, мәсәлән, «Акульчев», «Арабик групп» һәм «Эссен-Продакшн» компанияләре. «Агросила» холдингы һәм «Кәүсәр» АХҖК ит продукциясе һәм деликатеслар сата, Казан май комбинаты – көнбагыш мае, «Вамин-Татарстан» чит илгә – атланмай, MLK-GROUP ҖЧҖ сыр чыгара. Гомумән, аграр тармак экспортының төп өлеше май продукциясенә туры килә.

Хәер, көндәшлек һәрвакыттагыча югары булган хәләл базарның, традицион азык-төлек төрләре сегментыннан тыш, таләпчән сатып алучыны гаҗәпләндерергә сәләтле товар җитештерә торган фирмалар яулап алырлык буш өлкәләре дә бар. Бу уңайдан тышкы базарга көтелмәгән продукт – алкогольсез виноград эчемлеге чыгарган «ЭМИЗ» компаниясе яхшы үрнәк булып тора. Сыйфаты һәм кырыс хәләл стандартларына туры килүе әлеге ризыкны Малайзия, Индонезия, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре һәм Согуд Гарәбстанында сата башларга мөмкинлек бирә. Моннан тыш, 2025 елга төзелгән килешүләр эчемлек сатуның берничә тапкырга артуын күздә тота.

Татарстан компанияләренең хәләл базарда уңышлы эш тәҗрибәсе, киләчәктә үсеш җитди булыр, дигән өмет уята. Әлегә хәләл экспорты ТР агросәнәгать комплексы продукциясе экспортының өч процентыннан да кимрәк өлешен тәшкил итә. Чагыштыру өчен – узган ел экспорт күләме 430 миллион доллардан артып киткән. Тышкы икътисадый эшчәнлектә катнашучы 258 компания дөньяның 56 иленә үз продукциясен саткан. Хәләл экспорт географиясе шактый тыйнак, шул ук вакытта хәләл базар хәтта ислам булмаган илләрдә дә үзенең масштабы һәм потенциалы белән шаккатыра. АКШта, мәсәлән, ул 70 миллиард долларлык дип бәяләнә. Шуңа бәйле рәвештә иң мөһим максатларның берсе – Татарстанда хәләл продукция җитештерүчеләр өчен яңа базарлар эзләү.

ЯҢА БАЗАР – ЯҢА БУРЫЧЛАР

Февраль аенда Дубайда Бөтендөнья сәүдә үзәге территориясендә ачылган «Gulfood 2025» Азык-төлек сәнәгате буенча 30 нчы халыкара махсуслаштырылган күргәзмәсендә Татарстан делегациясенең катнашуы әлеге юнәлештә ясалган адымнарның берсе булды. Дөньяда иң зур һәм абруйлы күргәзмәдә ел саен 125 илдән 5 меңнән артык компания катнаша, ә килүчеләр саны – 195 илдән 130 меңнән артык кеше.

Дубай мәйданчыгы – партнёрлык багланышларын җайга салу, шул исәптән Татарстанның хәләл продукциясен экспортлау өчен дә яхшы мөмкинлек. Республиканың 15 тән артык предприятиесе ихтимал булган импортерларны үзендә җитештерелгән сөт, ит продукцияләре һәм хәләл десертлар белән таныштыру өчен биредә үз стендларын

оештырды. Компанияләр арасында – «КЖК» ААЖ, «ФЗП» ҖЧҖ, «ЭМИЗ» Сәүдә йорты» ҖЧҖ, «АЛИФ» ҖЧҖ, «Продэкс» ҖЧҖ, «Кәүсәр» АХҖК, «Вамин Татарстан» ҖЧҖ, «Хәләл» МЦСИС, «АКУЛЬЧЕВ ВТК» ҖЧҖ, «Экзито» ҖЧҖ, «АгроРост Экспорт» ҖЧҖ, «MLK-Group» ҖЧҖ, «ВМК» ҖЧҖ, ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хәләл» стандарты комитеты, «Ихлас» ҖЧҖ, «Полимер» Сәүдә йорты» ҖЧҖ, «Данлеко» ҖЧҖ, «Казан деликатеслары» ҖЧҖ.

Күргәзмә барышында Марат Җәббаров, республика делегациясенең башка вәкилләре белән бергә, Татарстан продукциясен сатып алучылар белән очрашулар уздырды. Аерым алганда, Оман, Малайзия, Иордания, Бәһрәйн вәкилләре белән үзара файдалы хезмәттәшлек мәсьәләләре тикшерелде. Сәфәр барышында шулай ук «Индеаль» ДК генераль директоры Андрей Алчаков, Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә «Рус йорты» генераль директоры Сергей Мөслимов, Al Madani Group җитәкчесе Мөхәммәд әл-Мәдәни, «Хәләл» МЦСиС генераль директоры Айдар Газизов, Әхмәд Али Солтан һәм Яхъя Али Яхъя белән сөйләшүләр узды. Татарстан экспортын алга таба үстерү кысаларында, аерым алганда, сатып алучыларга безнең ашлыкны турыдан-туры, арадашчылар катнашыннан башка китерү мөмкинлеге турында фикер алыштылар. ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы һәм Tagmoa франчайзинг һәм товар билгеләре буенча хезмәт күрсәтүләр ассоциациясе, шулай ук Al Madani Group арасында үзара аңлашу турындагы меморандумнар имзаланды.

KAZANFORUM: МӨМКИНЛЕКЛӘР ЯРМИНКӘСЕ

Һичшиксез, «Россия - Ислам дөньясы: KazanForum» халыкара форумы илләр арасында үзара файдалы сәүдә үсешенә көчле этәргеч булып тора. Чараның программасы ихтимал булган партнёрлар үзара таяну нокталары табарлык, булган проблемаларны хәл итәрлек, нинди дер каршылыкларны юкка чыгарырлык һәм ахыр чиктә ике якка да файдалы яңа эшлекле элемтәләр урнаштырырлык итеп төзелгән. Узган елгы форумда, исегезгә төшерәбез, «Хәләл индустрия» тематикасы буенча гына да биш түгәрәк өстәл уздырылган иде. Төп темалар РФ һәм гарәп-мөселман дөньясы илләре арасында товар әйләнешен үстерү; Россия хәләл продукциясен экспортлау: уңыш стратегиясенә ирешү һ.б. булды.

Хәләл продуктларга өстенлек бирүчеләр өчен Kazan Halal Market традицион ярминкәсе чын бәйрәм булып тора. Узган ел анда җитмештән артык компания катнашты, шул исәптән 15 чит ил компаниясе. Россия Федерациясенең 10 төбәгеннән 36 компания үз товарларын «Татар базары» бердәм бренды астында чыгарган иде. Бу – Татарстан, Башкортостан, Мордовия республикалары, Киров, Омск, Пенза, Түбән Новгород, Оренбург өлкәләре, Чуваш Республикасы, Пермь крае.

Kazan Halal Market 2025 ярминкәсе дә вәкиллекле булырга вәгъдә итә. Гаҗәп түгел, чөнки ярминкә – дустанә илләр белән хезмәттәшлекне ныгыту, АСК продукциясен экспортлауны үстерүнең яңа юлларын табуда нәтиҗәле мәйданчык. Моның шулай булуына даими катнашучылар өчен үз тәҗрибәләрендә инана бара.

КИЛӘЧӘКНЕ КҮЗДӘ ТОТКАН ЭКСПОРТ ЮЛЛАРЫ

ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хәләл» комитеты сертификацияләгән продукцияне бүген Татарстанда 150 компания җитештерә. Аларның егермедән артыгы экспортка эшли. Потенциал шактый, әмма, хәләл дөнья базары сыйдырышлылыгын исәпкә алганда, агросәнәгать тармагы алдында торган бурычлар җиңел түгел. Ни өчен, мәсәлән, Көньяк-Көнчыгыш Азия базарларыннан дустанә булмаган илләрне кысрыклап чыгарып, анда зуррак урын биләмәскә, ди?

Аңлашыла ки, киң колачлы бурычлар җитди оештыру һәм техник карарлар табуны да таләп итә. Монда хәләл продукцияне, аны җитештерә торган компанияләр санын арттыру белән генә чикләнеп булмый. Бүген Татарстан экспортының төп товары – май продукциясе (70,1%), шактый өлеше үсемлекчелеккә туры килә. Шул ук вакытта республика сөт җитештерү күләме буенча Россия Федерациясендә беренче урында тора. Безгә дустанә илләрдә, сүз уңаеннан, сөт продуктларына ихтыяҗ зур.

Нәтиҗә үзеннән-үзе ясала. Бер яктан, безгә хәләл базарда уңышлы гамәлгә ашырыла торган продукция экспорты күләмен арттырырга кирәк, икенче яктан – әлегә бу базарда беренче адымнарын ясый торган көчле тармакларыбызның потенциалын максималь файдалану да яхшы булачак. Монда хәләл эшкәртү произ-

JAKIM Малайзия аудиторлары ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хәләл» комитеты стандарты эшенә югары бәя бирделәр.

водстволары һәм уңайлы логистика белән тәэмин итә алырлык элеватор комплекслары төзү буенча экспортка юнәлтелгән инвестиция проектларын гамәлгә ашыру ярдәм итә ала.

Сүз уңаеннан, хәләл базарда нәтиҗәле эш үрнәген «Эссен продакшн АГ» һәм «Акульчев» күрсәтә. Алар 35 тән артык илгә кондитер продукциясе чыгара. Өстәвенә, «Акульчев»-ның бөтен азык-төлек төре дә диярлек хәләл стандарты буенча җитештерелә. Узган ел предприятие 550 мең тонна хәләл продукция саткан.

СЕРТИФИТ АЛУ ҺӘМ «ЯШЕЛ КОРИДОР»ГА ХОКУК

Мөселман иленең хәләл базарына чыгу җиңел түгеллеге аңлашыла. ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хәләл» комитеты биргән сертификатның булуы продуктка һәм аны җитештерүчегә ышанычны арттыра. Бу үзенә күрә сыйфат билгесе. Әмма һәр илнең үз стандартлары һәм критерийлары бар. Алар продуктны чыннан да хәләл дип санарга мөмкинлек бирә. Үз товарын экспортлауга «яшел ут» алу, димәк, сатып алучы илнең стандартларына һәм критерийларына туры килү – алай ук җиңел эш түгел. Еш кына алдан ук үзара сөйләшүләр алып барырга, чит ил дәүләт структураларында экспортлаучы илләрне мәҗбүри аккредитацияләргә кирәк була.

Күптән түгел, мәсәлән, Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында Малайзиядә исламны үстерү департаментында (JAKIM) аккредитация алу мәсьәләләре буенча Малайзия делегациясе белән эшлекле очрашу узды. Яклар Татарстан һәм Малайзия арасында хезмәттәшлекне үстерү, шулай ук продукциянең «Хәләл» стандартына туры килүен бәяләү һәм аккредитацияләү сораулары турында фикер алыштылар. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: JAKIMда аккредитация алу – Малайзиягә Россия хәләл продукциясен экспортка җибәрү өчен шарт. Бу ил безнең өчен иң өметле базарларның берсе.

РФ мөселманнарының Диния нәзарәте каршындагы «Хәләл» халыкара стандартлау һәм сертификацияләү үзәге дә бу эшләрдә мөһим роль уйный. ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгы әлеге оешма белән ныклы хезмәттәшлек итә. Россия территориясендә һәм чит илләрдә сертификацияләү мәсьәләләре белән шөгыльләнә торган әлеге абруйлы орган гарәп-мөселман дөньясы илләренә экспортлау максатында, Россия «Хәләл» продуктларын һәм хезмәт күрсәтүләрен сертификацияләү буенча да актив эшчәнлек алып бара. Фарсы култыгы илләре белән ныклы хезмәттәшлек урнаштыру өчен әлеге юнәлештәге иң зур импортёр белән 2017 елда «Галфтик – «Хәләл» МЦСиС (GulfTIC – ICSC Halal) уртак Россия – БГӘ предприятиесе төзелә.

Хәләл продукция җитештерүчеләрнең чит ил базарларына чыгуын Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте дә җиңеләйтергә тиеш. Аның «Хәләл» комитеты дөньяның алдынгы үзәкләрендә халыкара хәләл стандартларына туры килү буенча аккредитация узган, шуңа күрә дөньяның күпчелек ислам илләренә продукция экспортлау өчен верификацияләнгән сертификатлар бирергә әзер.

Мөселман илләрендә Татарстан компанияләренә аерым мөнәсәбәт булуы да мөһим. Хәтта халыкара сертификаты булмыйча, хәләл нормаларына туры килүен раслый торган Россия сертификаты гына булса да, сатып алучы ТР компаниясенә лояль мөнәсәбәттә тора. Шунысын да искәртик: экспортёрларга ярдәм чараларының берсе – халыкара сертификацияне, шул исәптән хәләл сертификация алуны финанслашу.

Язмабыз ахырында – кызыклы факт. Кошчылар милли берлеге мәгълүматлары буенча, Россия продукциясен сатып алу күләме буенча өченче урында Согуд Гарәбстаны тора. Бу ил ел саен 50 мең тоннага якын хәләл кошчылык продукциясе сатып ала. Шул ук вакытта сатуп алуларның күп өлеше «яшел коридор» форматында башкарыла, чөнки РФ җитештерүчеләре үз продукцияләренең югары сыйфатлы булуын инде исбатлаган.

Татарстан предприятиеләренең хәләл продукциясе киләчәктә шулай ук «яшел коридор» хокукына лаек булыр дигән ышаныч зур. Ⓣ

Фото: ТР Диния назарәте сайты, pxhere.com, sertiki.ru

ХӘЛӘЛ ТУРИЗМ. ЧЫНГА АШАРЛЫК ХЫЯЛМЫ?

Руфия Фазылова

Безнең Казанның нинди генә исемнәре юк: гастрономик башкала, спорт башкаласы, мәдәни башкала... Киләчәктә, ихтимал, тагын бер исеме барлыкка килер: «Казан – ислам туристлык башкаласы». Бу чынга ашарлык хыялмы? Казан, гомумән, Татарстан ни дәрәҗәдә моңа дәгъва кыла ала? Әнә шулар хакында белештек.

Сүзне шуннан башлыйк: хәләл турлар тәкъдим итә торган туристлык агентлыклары бармак белән генә санарлык. Алары да күбрәк чит илгә турлар сату белән шөгыльләнә. Алай да без шундый бер оешманы таптык. «Рәхәт тур» җитәкчесе Рушан Мостафинның бу өлкәдә тәҗрибәсе шактый. Казан – Мәскәү – Санкт - Петербург маршрутлары буенча да хәләл экскурсияләр оештырган. Казан – Болгар маршруты да популяр икән.

– Беренче чиратта хәләл кафе, ресторан, кунакханә кирәк аларга, – дип сүзен башлады Рушан Мостафин. – Хәләл туклану буенча Казанда проблема юк. Ә менә кунакханәләрне табу шактый авыр. Шуның өчен хәләл булмаганнарына тукталалар инде. Иң мөһиме – тыныч, чиста булсын, диләр. Замана туристларының тагын бер таләбе – фотога төшү өчен матур урыннар сорыйлар. Анысын да табабыз: Казаныбыз истәлекле урыннарга, шул исәптән ислам мәдәниятенә кагылышлы һәйкәлләргә, мәчетләргә бай. Хәләл маршрутларга килгәндә исә, кунаклар Болгарга экскурсиягә барырга ярата. Тагын башкаланың «Ярдәм» мәчетенә битараф калмыйлар. Биредә бер бинада гыйбадәтханә, тернәкләндерү үзәге, кунакханә, ашханә – аларның моңа исләре китә. Россиядә генә түгел, чит илләрдә дә мондый

урыннар юк дип беләм. Җитмәсә, хәзер «Ярдәм» мәчетендә мөмкинлеге чикле кешеләр өчен тулы бер заманча спорт үзәге дә бар. Әлбәттә, Казанның борынгы мәчетләре – барысы да туристларга кызык.

– Ә ризык буенча ниндидер аерым таләпләр куялармы?

– Кайсы илдән килүенә карап. Нигездә, мөселман илләрендә тозлырак, борычлырак ризыклар пешерәләр. Татлы ризыкларны да аерым тәмләткечләр белән әзерлиләр. Аннары, күп мөселман илләрендә дөге яраталар, ә бездә исә нигездә итле, бәрәңгеле ризыклар. Шулай булуга карамастан, алар безнең милли ризыкларны бик яратып ашый. Әле күчтәнәчкә дә алалар. Хәер, хәзер Казанда да төрле халык ашларын әзерли торган рестораннар бар, бик теләсәләр, кунакларны анда да алып барабыз. Гомумән, мөселманнарның күңеленә хуш килә торган ризыклар бездә җитәрлек.

ИСЛАМ КАНУННАРЫ БУЕНЧА ЭШЛИ ТОРГАН КУНАКХАНӘ

Рушан Мостафин Казандагы дүрт йолдызлы «Гольфстрим» мөселман кунакханәсен телгә алды. Биредә кунаклар өчен өчен барысы да бар: бильярд залы, бассейн, спорт залы, шулай ук зур булмаган конферец-зал һәм ресторан. Шунысын әйтергә кирәк: бассейн бер көн – хатын-кызлар, бер көн ир-атлар өчен эшли. Кунакханәнең хуҗасы үзе дә ислам кануннары буенча яши икән.

– Якын ук көнгә бер буш урын да юк, – диде кунакханәнең админстраторы, минем шалтыратуыма җавап итеп. Бәяләргә килгәндә, ике кешелек бүлмә 6900 сум тора икән. Монда иртәнге аш һәм кунакханәнең барлык ял итү урыннарыннан бушка файдалану кергән.

– Ә кунаклар ифтарны сездә ашый аламы?

– Әлбәттә, ресторанныбыз иртәнге җидедән тугызга кадәр һәм көндезге унбердән кичке сигезгә кадәр эшли. Рамазан аенда һәр көнне ифтар уза. Янәшәдә генә кунакханәнең мәчете бар, шунда кереп, тәравих намазы укырга мөмкин. Кыскасы, шәригать кануннары буенча яшәүче кунакларга бездә барлык мөмкинлекләр дә тудырылган.

Кунакханәнең рәсми сайтына кереп кайтавазларны укыдым. Тискәре фикерләргә караганда, уңайлары күбрәк дип таптым. Күп туристлар кунакханәнең шәһәр читендәрәк булуын начар, дип язган. Ә болай чисталык, туклану ягыннан бар да тәртип, дигәннәр.

«МАКСАТ – МӨСЕЛМАН ТУРИСТЛЫК КАРТАСЫН БУЛДЫРУ»

ТР мөселманнарының Диния нәзарәтендә дә мөселман туристлар белән эшлиләр. Дөрес, алар күбрәк чакырылган, рәсми затлар өчен

программа төзи. Ул ике көнлек тә, биш көнлек тә булырга мөмкин.

– Монда шуны аңларга кирәк: мөселманнар Казанга кызык эзләп килми, – диде Диния нәзарәтенең социаль үсеш бүлеге җитәкчесе Айгөл Биктимерова. – Аларга шау-шулы кичәләр, әллә нинди затлы спа-салоннар кирәк түгел. Монда пляжда кызынып яту ниятләре дә юк. Аларны безнең тарихыбыз, мәчет-мәдрәсәләребез кызыксындыра, шундый җирләргә алып барабыз. Шөкер, алар бездә җитәрлек. Күбесе алдан ук үз планын төзеп куйган була, фәлән җирне күрәсе килә, дип әйтәләр.

Мәчет, мәдрәсәләрдән тыш, ислам кушканча яшәүче туристлар зиратларга да экскурсия ясый. Бу бигрәк тә яз, җәй айларында популяр икән.

– Кышын да берничә шундый экскурсия булды, – диде Исламны кабул итүнең 1000 еллыгы исемендәге Казан Югары мөселман мәдрәсәсенең музей мөдире Зөлфәт Салих улы Мингалиев. – Әлбәттә, безгә килгән туристларны башта мәдрәсә, музей белән таныштырабыз. Теләге булганнарны Казанның Яңа Татар бистәсе зиратына зиярәт кылырга чакырабыз. Җәен егермешәр кешедән торган төркем җыела. Шимбә, ялларда атна саен шулай алып барабыз.

Анда бик күп танылган шәхесләребез, дин белгечләре күмелгән. Мәсәлән, Габделхак Саматов, Мәрҗани мәчетенең атаклы имамы булган кеше. Габделхак Каюмов, совет хакимияте елларында да халыкны дин нигезләренә, гарәп язуына өйрәткән остаз. Әлбәттә, Шиһабетдин Мәрҗани каберенә дә тукталабыз. Читтән килгән туристларның күбесе Мәрҗанине белә, шуның өчен дә төрле сораулар бирәләр. Тагын Әхмәтзәки Сафиуллин, Әхмәтһади Максуди, Галимҗан һәм Салихҗан Бурудилар, Габделхәбир Ярууллин – һәркайсының каберенә сугылабыз. Аларның эшчәнлекләре турында туристларга сөйлибез, сорауларына җавап бирәбез, рухларына багышлап дога кылабыз.

– Яңа Татар бистәсе зиратында бик күп татар зыялылары, язучылары да җирләнгән. Алар турында туристларга сөйлисезме?

– Сөйлибез. Габдулла Тукай кабере янына туктамыйча китмибез, Туфан Миңнуллин, Шамил Зиннуров, Миркасыйм Госманов – һәркайсы татар тарихында, мәдәниятендә якты эз калдырган шәхес. Аларны да искә алабыз.

Исламны кабул итүнең 1000 еллыгы исемендәге Казан Югары мөселман мәдрәсәсе җитәкчесе Ильяс Җиһаншинның бер хыялы бар – мөселман туристлык урыннары картасын ясарга. Аның фикеренчә, Татарстанда борынгы, тарихи, серле урыннар бик күп. Мисал өчен, Тәтеш районының Зур Әтрәч авылында 1236 елдан алып 1326 елга караган егермедән артык борынгы кабер ташы бар. Алар тимер рәшәткә белән уратып алынган, матур итеп ясалган. Шунда ук төрле авырулардан шифасы булган чишмә ага. Әлеге җирлекнең тарихы да бик үзенчәлекле. Кыскасы, туристлар өчен кызык булачак, дип фикер йөртә Ильяс хәзрәт:

– Иң мөһиме, андый урыннар республикабызның һәр районда булмаса да, күп җирдә бар. Менә шуларны тәртипкә салып, маршрутын көйләсәк, ислам кануннары буенча яшәүче туристларга гына түгел, башкалар өчен дә файдалы булыр иде, дип уйлыйм.

«ХӘЛӘЛ» СЕРТИФИКАТЫ КЕМГӘ БИРЕЛӘ?

Соңгы елларда «Хәләл» стандарты турында күп сөйлиләр. Ә аны алу бик җайлы. Россиядә бүген «Хәләл» сертификаты бирә торган 84 оешма бар. Кайбер очракта, алар онлайн гына да эшмәкәрләргә «Хәләл» сертификаты язып бирә. Мисал өчен, кайсыдыр райондагы бер абзыйның хәләл кафе ачасы килә. Ул, документларны җыеп, электрон рәвештә Мәскәүгә, «Хәләл» сертификаты бирә торган оешмага җибәрә. Тегеләре исә, үз чиратында әлеге документларны карап (урынга барып тикшереп тору юк), рәсми документ тапшыра. Бетте, шуның белән хәләл кафе ачылды, дигән сүз. Ә кулланылган майда, кетчуп яисә майонезда желатин,

башка хәләл булмаган продуктлар бармы-юкмы – анысы инде кафе хуҗасының намусында кала.

– Ләкин Татарстанда алай эшләргә рөхсәт куймыйбыз, – диде ТР Диния нәзарәтенең «Хәләл» комитеты җитәкчесе Аббас хәзрәт Шляпошников-Кадыйров. – Без – ТР мөселманнары Диния нәзарәте каршында эшләүче рәсми оешма. «Хәләл» стандартларына җавап бирү турындагы сертификатны биргәнбез икән, димәк, башта моны кат-кат тикшергәнбез. Алай гына да түгел, сертификатның срогы чыкканчы (гадәттә ул биш елга бирелә), без ул оешманың эшен тикшереп торабыз.

– Урынга барып тикшерәсезме? Сезнең мондый хокукыгыз бармы?

– Әйе, бар. Сертификат биргәнче, эшмәкәрләрне бу турыда кисәтәбез. Ике арада килешү төзелә, бөтен нечкәлекләр кәгазьдә теркәлә. Мисал өчен, Питрәч районы, Яр Чаллы шәһәренең кош фермалары без биргән сертификатлар белән эшли. Анда үз кешеләребез бар, аларга хезмәт хакы түлибез. Алар кош-кортны хәләл стандартлар буенча чалынуын карап, күзәтеп тора. Хәләл кафелар белән дә шул ук: урынга барып, итнең кайдан алынганын, башка продукциянең составын өйрәнәбез. Әгәр ниндидер сораулар туса, партнёрларыбызга: «Без бу җитештерүчене шикле дип таптык, зинһар, продукцияне башка кешедән алыгыз», – дип киңәш бирәбез. Шөкер, бүген бу өлкәдә проблема юк: хәләл стандартларга туры килгән май, майонез, төрле тәм-томнарны да табарга була.

ДУСЛЫК ТӘКЪДИМ ИТҮ

ТР «Хәләл» комитетының рәсми битендә, алар кемнәр белән эшли, шул оешмаларның исемлеге бар. Хәләл кунакханәләр исемлеген шуннан эзли башлаган идем... Бары тик Казандагы TARIH бутик-кунакханәсе һәм Спас районындагы «Кол Гали» кунакханәсе генә күрсәтелгән. Шуның белән бетте.

Ә бит үзләрен хәләл стандартлар буенча эшлибез дип таныта торган кунакханәләр күбрәк. Алар барысы да чынбарлыкка ни дәрәҗәдә туры килә – монысы инде икенче мәсьәлә. Хәер, «Хәләл» сертификациясеннән тыш, илебездә бүген «Мөслим Френдли» ирекле сертификация системасы да эшли. «Мөслим Френдли» категориясенә карый торган кунакханәләр нинди критерийларга туры килергә тиешлеген «Роскачество» базасында эшли торган Туристлык өлкәсендә компетенцияләр үзәге формалаштыра. Гади генә итеп әйткәндә, кунакханәләрдә мөселманнар өчен уңайлы шартлар тудырылырга тиеш.

– «Мөслим Френдли» ирекле сертификация системасына сәүдә объектлары, кунакханә, туристлык һәм медицина хезмәте күрсәтә торган компанияләр керә ала, – диде Аббас хәзрәт Шляпошников-Кадыйров. – Мисал өчен, «Туган авылым» комплексы белән шулай эшлибез. Ислам кануннары буенча яшәүче туристларны биредә ничек каршы аласын, нәрсә ашатасын, кыскасы, барысы хакында да беләләр. Эшчеләре махсус курслар узды. Шуның өчен бирегә ислам кануннары буенча яшәүче туристлар килә икән (гадәттә, алдан кисәтеп куябыз), кунакларны мөселманча сәламлиләр. Аннан соң Казан вакытына туры килгән намаз вакыты язылган кәгазь бирелә. Кирәк дисәләр, Коръән китабы да тәкъдим итәләр. «Туган авылым» комплексында мәчет тә бар. Шулай булгач, тәһарәт алу, намаз уку буенча да кыенлыклар юк.

Питрәч районындагы глэмпинг та «Мөслим Френдли» ирекле сертификация систе-

масы буенча эшли башлаган. Арендага йорт алып, саф һавада ял итәргә теләүче мөселман гаиләләре күп икән.

– Димәк, «Мөслим Френдли» системасы буенча эшләү – хәләл стандартларга туры килү ул. Ә ул компанияләргә «Хәләл» сертификаты биреләме соң?

– Үзләре теләсәләр, бирелә. Монысы инде икенче баскыч санала. «Мөслим Френдли» – хәләл стандартлар буенча эшләүнең беренче адымы. Кунакханә яки кафе-ресторан эшчеләре өчен яңа тәҗрибә туплау да. Бу юнәлеш чит илдә күптән популяр.

– Хәләл туризмга сорау зурмы? Аның киләчәге өметлеме?

– Әлбәттә, өметле. Сер түгел: соңгы елларда Россия мөселман илләре белән элемтәләрне көчәйтте. Барлык мөселман илләре Казанга карап тора, бу арттырып әйтү түгел. Әле менә күптән түгел генә Малайзиядән кунаклар килде. Бездәге шартлардан бик канәгать калдылар. Алар белән үзара хезмәттәшлек турында килешү төзедек.

ТР «Хәләл» комитетында Россиядә хәләл стандартына туры килә торган компанияләрнең исемлеген булдырырга уйлыйлар. Дөрес, әлегә бу хыял гына. Әмма май аенда узачак «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum»да нәкъ менә шушы теманы күтәрергә җыеналар.

...Казан – Россиянең башка бик күп шәһәрләреннән аерылып тора. Күпмилләтле булуы белән генә түгел, аның мәдәнияте, тарихы, яшәү рәвеше дә башка. Бер карасаң, бездә диңгезләр, мәгърур таулар да юк. Ә туристлар саны елдан-ел күбәя. Нәкъ менә шул үзенчәлегебез җәлеп итмиме икән аларны? Әгәр инде мөселман илләреннән килгән кунакларны лаеклы рәвештә каршы алып, озатып та җибәрә алсак, туристлык өлкәсендә тагын бер баскычка күтәрелер идек.

Бүген без хәләл туризмны оештыру буенча беренче адымнарны гына ясыйбыз. Ләкин боз кузгалды. Иң мөһиме – бер урында таптанып калмаска.

«ХӘЛӘЛ» СЕРТИФИКАТЫНА ИЯ КУНАКХАНӘЛӘР КАЙ ЯГЫ БЕЛӘН АЕРЫЛА?

Кунакханәләр һәм туристлык комплекслары өчен мәҗбүри шартлар:

- Хәләл туклану: оешма тулысынча хәләл стандартларга туры килә яисә кунакларга сертификацияләнгән хәләл ризык тәкъдим итә.
- «Хәләл» сертификатына ия кухня яисә туклануны җирле хәләл-рестораннар аша оештыру.
- Клиент соравы буенча мини-барлардан хәмерле эчемлекләрне алу.
- Яшәү һәм намаз бүлмәләрендә Кыйбланы күрсәтү.
- Тәһарәт алу өчен уңайлы шартлар булдыру.
- Намазлыклар бирү, җирле намаз вакытын күрсәтү.
- «Хәләл» стандарты принципларын белүче, мөселман кунакларның таләпләренә җавап бирә алучы персонал.

Тәкъдим ителгән шартлар:

- Җирле хәләл рестораннарны һәм мәчетләрне күрсәткән исемлек.
- Намаз бүлмәсе.

RESEDAODOR: КАЗАНДА ТУГАН МАТУРЛЫК ФӘНЕ

ResedaOdor® компаниясе профессиональ косметика базарында ун елдан артык алдынгылар рәтендә. Компанияне оештыручы Резеда Нурисламова – 25 еллык тәҗрибәгә ия фармаколог. Бит тиресен тәрбияли, проблеманың симптомнарын түгел, сәбәпләрен юкка чыгарырга булыша торган косметика уйлап табуны бурыч итеп куя ул. Бүген Россиядән читтә дә танылу алган бренд шул рәвешле барлыкка килгән.

УҢЫШ НИГЕЗЕНДӘ – ФӘННИ КАРАШ

ResedaOdor® – косметика гына түгел, күпьеллык тикшеренүләр һәм клиник сынаулар нәтиҗәсе дә. Һәр продукт составына актив компонентлар терапевтик дозада кертелгән, агрессив матдәләр, хушландыргычлар һәм буяулар юк. Компаниянең беренче эшләнмәләре арасында – 4 мономолекула – актив ингредиентларның 100 концентраты бар. Алар абруйлы InCosmetics Global призына лаек булган. Мәсәлән, SCC5 инновацион формуласы чәч коелуга бәйле төп сәбәпләрне ачыклый һәм дәвалый, шул исәптән андроген алопецияне. Бу трихологка мөрәҗәгать итүләрнең 90%на туры килә. Шулай ук яшькә, стресска һәм ковидтан соңгы халәтләргә бәйле сәбәпләрне хәл итә.

Бүген ResedaOdor®– Казанда үз лабораториясе һәм җитештерүе булган халыкара бренд ул. Компания үз продукциясен Якын Көнчыгыш, БДБ һәм башка илләренә актив экспортлый, ә 2024 елда «Ел экспортёры» бүләгенә лаек була. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: ResedaOdor продукциясе «Хәләл» сертификатына ия. Бу аның этика һәм сыйфатның югары стандартларына туры килүен раслый.

ResedaOdor® продукциясе Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә аеруча популяр. Бу косметиканың югары сыйфатына гына түгел, эссе климат аркасында тиредә пәйда була торган үзенчәлекле проблемаларны хәл итәргә сәләтле булуына бәйле. Бренд Дубайдагы клиникалар һәм матурлык салоннары белән хезмәттәшлек мөнәсәбәтләрен актив үстерә. Бу аның халыкара статусын раслый. «Хәләл» сертификатының булуы шулай ук Якын Көнчыгыш илләрендә ышаныч казанырга ярдәм итә.

ПРОБЛЕМАЛАРНЫ ХӘЛ ИТӘ ТОРГАН АССОРТИМЕНТ

ResedaOdor® компаниясе продуктлары арасында – бит тиресен һәм чәчләрне карауда кулланыла торган 130дан артык матдә. Компания Россиянең «Петровка Бьюти», «Клиника Юцковской» һәм «Медси» кебек әйдәп бара торган клиникалар белән хезмәттәшлек итә. Һәр продукт пациентларның ихтыяҗларын һәм табиб-косметологларның тәкъдимнәрен исәпкә алып эшләнә. 2025 елда ResedaOdor® берничә яңа матдә чыгарырга ниятли. Бу аның даими үсешкә һәм яңалыкка омтылуын күрсәтә.

Компаниянең соңгы казанышларының берсе розацея – күптән түгел генә нәтиҗәле чишелеше булмаган хроник тире авыруына каршы сыворотка уйлап таба. Өч ай элек кенә чыгарылган әлеге продуктның клиник яктан исбатланган нәтиҗәлелеге аны профессиональ мохиттә дә танытты.

БРЕНД ПРОИЗВОДСТВОСЫ ҺӘМ ФӘЛСӘФӘСЕ

ResedaOdor® үзенең Казандагы җитештерүе белән горурлана, анда брендның барлык продуктлары ясала. Компания дөньяның иң яхшы җитештерүчеләреннән алынган, тикшерелгән ингредиентларны гына куллана, шул исәптән Швейцария һәм Франциядән китерелгән компонентларны да. Шул ук вакытта ResedaOdor® үзебезнең, җирле эшләнмәләргә актив ярдәм итә. Мәсәлән, соңгы сывороткаларның берсендә файдасы буенча чит илнекеләрне узып киткән Россия пептиды кулланылган. Бренд сыйфатка һәм куркынычсызлыкка басым ясый.

Брендның бәя сәясәте сыйфатка зыян китермичә файдалана алуга юнәлдерелгән. ResedaOdor® продуктларына уртача бәя – 2 000 сумнан 5 000 сумга кадәр, бу аларны люкс маркалар фонында көндәшлеккә сәләтле итә.

МАТУРЛЫК ҺӘМ ДИАГНОСТИКА ҮЗӘГЕ

Казанда ResedaOdor® үзенең Матурлык һәм диагностика үзәген ача. Теләгән һәркем анда тире һәм чәчләрен бушлай тикшертә ала. Профессиональ косметологлар индивидуаль матдәләр сайлый, ә клиентлар тәкъдим ителгән продуктларны шунда ук сатып алырга мөмкин. Үзәк сату урыны гына түгел, ә кулланучылар белән аралашу мәйданчыгына да әверелгән. Бу компаниягә аларның ихтыяҗларын яхшырак аңларга мөмкинлек бирә.

КИЛӘЧӘККӘ ПЛАННАР

ResedaOdor® ирешелгәннәрдә генә тукталып калмый. Якындагы планнарда – маркетплейсларда ваклап сату линейкасын эшләтеп җибәрү. Компания парфюмер композицияләре белән танылган Швейцария җитештерүчесеннән люкс брендлар өчен тән тиресен тәрбияләү матдәләренең яңа коллекциясен тәкъдим итәргә әзерләнә.

ResedaOdor® – косметика гына түгел, фәнне, табигатьне һәм инновацияләрне берләштерә фәлсәфә дә ул. Бренд дөнья базарларын яулый. Россия косметикасының нәтиҗәле генә түгел, бәлки халыкара аренада көндәшлеккә сәләтле була алуын да раслый. Һәр яңа продукты белән ResedaOdor® матурлыкның хыял гына булып калмыйча, һәркем куллана алырлык чынбарлык булуына таба атлый. Һәм әгәр косметика индустриясенең киләчәге – фән, этика һәм кеше турында кайгырту синтезы икән, ResedaOdor® инде бүген үк әлеге киләчәккә этәргеч бирә. Т

Фото Резеда Нурисламова архивыннан. РЕКЛАМА

КУКМАРА ТЕГҮ ФАБРИКАСЫ: СЫЙФАТЛЫ, ҖЫЛЫ КИЕМНӘР ҖИТЕШТЕРӘ БАШЛАУГА – 70 ЕЛ

Татарстан Республикасындагы Кукмара шәһәре борынгы заманнардан ук үзенең һөнәрчелек кәсәбәләре белән данлыклы. XIX гасырда бередә баш киемнәре һәм бияләй тегү, киез аяк киеме басу, кирпеч сугу, бакыр эшләнмәләр җитештерү артельләре актив эшли. Кукмара осталарының даны еракларга тарала, ә аларның сыйфатлы да, уңайлы да продукцияләре югары бәяләнә.

Бүген Кукмара, заманча җитештерүләрне үстерү белән бергә, үз традицияләрен саклауны да дәвам итә. Биредә киез итек басу-киез комбинаты, металл савыт-саба заводы һәм, әлбәттә инде, Россиядәге иң тәҗрибәле предприятиеләрнең берсе, 1956 елда нигез салынган Кукмара тегү фабрикасы уңышлы эшли.

Фабрика өлкәннәр һәм балалар өчен өске кием тегүгә махсуслаша. Дистәләрчә ел эшләү дәверендә ул үз традицияләрен саклап кына калмый, базарның заманча таләпләренә дә яраклаша. Биредә бүген куртка, плащ һәм комбинезоннар гына түгел, корпоратив кием, мәктәп формасы да тегәләр, шулай ук мендәр, юрган һәм матраслар да җитештерәләр.

Кышкы кием-салым аеруча популяр. Барлык продукциянең сыйфаты катгый контрольдә тотыла һәм ГОСТ таләпләренә җавап бирә.

«Без хәтта үз киемнәребезне Мәскәү лабораториясендә дә тикшерттек, – дип сөйли фабриканың генераль директоры Руслан Рафаэлевич Голов. – Безнең тау чаңгысы костюмнары һәм комбинезоннарыбыз 30 градус суыкта да җылыны саклый. Бу рәсми дәлилләнгән факт».

КОРПОРАТИВ КИЕМ: СТИЛЬ ҺӘМ ИНДИВИДУАЛЬЛЕК

Фабрика шулай ук корпоратив киемнәр дә җитештерә. Аның заказчылары арасында Татарстан Республикасы Чаңгы спорты федерациясе, РФ Чаңгы узышлары федерациясе, ТР Спорт министрлыгы, «Ханский дом», «Буревестник» транспорт компаниясе, «Татпотребсоюз», «Уникс», «Татэнерго» һәм башка компанияләр бар. Һәр заказ – уникаль проект ул. Фабрика модельләрне уйлап таба, тукыма сайлый, логотип төшерә һәм шул рәвешле һәр заказчының корпоратив стилен чагылдырган кием-салымны тегеп әзерли.

ЗАМАНЧА ТЕХНОЛОГИЯЛӘР ҺӘМ ҮЗ ҖЫЛЫТКЫЧЛАРЫ

Предприятиенең иң зур горурлыгы – үзләре уйлап тапкан җылыткыч тукыма, синтепон. Ул үзенә бертөрле йомшак та, деформациягә дә чыдам, шунлыктан кием җылы да була, озак тузмый да.

«Безнең киемнәрне кер юу машинасында да юарга ярый, – дип искәртә Руслан Рафаэлевич. – Бу кулланучылар өчен бик уңайлы. Замандашларыбызга әйбернең сыйфаты гына түгел, уңайлылыгы да кадерле булуын без яхшы аңлыйбыз».

Кием-салымнан тыш, фабрикада мендәр, юрган һәм матраслар да җитештерелә. Бу эшләнмәләр дә үз синтепоннарыннан сырыла, димәк, җылы да, уңайлы да дигән сүз.

МӘКТӘП ФОРМАСЫ: ЯҢА ЮНӘЛЕШ

Моннан ике ел элек фабрикада Кукмара районы мәктәпләрендә укучы

Фотолар Кукмара тегү фабрикасыннан алынды. РЕКЛАМА

балалар өчен махсус форма тегелә башлый. Предприятие үз алдына куелган әлеге бурычны да уңышлы хәл итә. Бүген район мәктәпләрендә укучыларның барысы да бөтен стандартларга җавап биргән җайлы һәм стильле форма кия.

«Без башка төбәкләр өчен дә мәктәп формасы тегәргә әзер, – ди директор. – Бездә моның өчен кирәкле сыйфатлы тукымалардан алып төрле яшьтәге балалар өчен модельләр уйлап табучы конструкторларга кадәр, ягъни бөтен нәрсә бар».

КУЛЛАНУЧЫЛАР НӘРСӘГӘ ӨСТЕНЛЕК БИРӘ

Фабрика һәрвакыт трендлар һәм модалы тенденцияләрдән калышмаска омтыла. Мәсәлән, соңгы вакытта тыныч төсләрдәге гади һәм уңайлы модельләр популяр икән. Әмма тау чаңгысы костюмнары өчен барыбер шуганда әллә кайдан үзенә җәлеп итеп торырлык җете төсләр тәкъдим ителә.

Фабриканың төп бүлекчәләреннән берсе – эксперименталь цех. Биредә профессиональ конструктор һәм технологлар яңа модельләр уйлап таба, төрле тукымалар, фурнитура, дизайнны сыный.

«Без үз продукциябезне яхшырту белән даими шөгыльләнәбез, – дип сөйли фабриканың генераль директоры Руслан Рафаэлевич Голов. – Эксперименталь цехта туган идеяләр аннары тормышка ашырыла. Кайсы модельләрне җитештерә башлау турында карарлар фабрикада бергәләшеп киңәшкәннән соң кабул ителә».

СӘҮДӘ ГЕОГРАФИЯСЕ: ТАТАРСТАННАН – ЕРАК КӨНЧЫГЫШКА КАДӘР

Кукмара тегү фабрикасы продукциясен Кукмарадагы фирма кибетендә, шулай ук Казанның «Порт» сәүдә үзәгендә сатып алып була. Моннан тыш, товарлар үзләренең интернет-кибете һәм Ozon* кебек маркетплейслар аша да сатыла.

Кукмара тегү фабрикасы продукциясенә ихтыяҗ Татарстанда гына түгел, аннан читтә дә бик зур. Эшләнмәләр Пермь крае, Чувашстан, Киров өлкәсе, Удмуртия, Башкортстанга, шулай ук Ерак Көнчыгышка җибәрелә. Моннан тыш, фабрика Казахстан өчен дә кайбер заказларны башкарган, бу аның продукциясе белән якын чит илләрдә дә кызыксыну артуны күрсәтә.

КЫЕНЛЫКЛАР ҺӘМ КИЛӘЧӘККӘ ПЛАННАР

Россиядәге күп кенә җитештерүчеләр кебек үк, фабрика да чит ил брендлары көндәшлегеннән зыян күрә, бигрәк тә маркетплейсларда.

«Хәзер халык күп нәрсәне интернет аша сатып ала, һәм бу безнең өчен кыенлыклар тудыра, – дип аңлата Руслан Рафаэлевич. – Мәсәлән, Ozon платформасында без Кытай җитештерүчеләре белән көндәш – алар продукцияләрен арзанрак бәягә тәкъдим итә. Әмма без югары сыйфатка басым ясыйбыз һәм шуның белән отарга ниятлибез».

Фабрика җитештерүне киңәйтү, ассортиментны арттыру һәм продукцияне онлайн-форматта активрак сатуны планлаштыра.

70 ЕЛЛЫК СЫЙФАТ ҺӘМ КАЙГЫРТУ

Кукмара тегү фабрикасы – җитештерү генә түгел, ә бәлки шәһәр һәм аның халкы тормышының бер өлеше дә ул. Биредә җылыта, сөендерә, илһамландыра торган кием тегәләр.

«Без эшләнмәләребезнең теләсә нинди һава шартларында да кешеләргә үзләрен уңайлы тоярга булышуы белән горурланабыз, – ди Руслан Рафаэлевич. – Һәм без сатып алучыларыбызны үзебезнең яңа коллекцияләребез һәм сыйфатлы продукциябез белән куандыру эшен дәвам итәчәкбез».



Кукмара ш., Эшче тыкрыгы, 1
+79061172836
+7 (84364) 2-67-49,
+7 (84364) 2-68-62
t.me/fabrika_kukmor_official
e-mail.kukmor.fabrika@mail.ru
fabrika_kukmor.ru
vk.com/club226001094

* «Интернет Карарлар» ЖЧЖ ОГРН 1027739244741. 123112, Мәскәү шәһәре, Пресненская яр буе, 10 йорт. 1 бина, 41 кат, 6 бүлмә

МОДАЛЫ, ҖЫЛЫ, УҢАЙЛЫ

«Кукмара киез итек басу-киез комбинаты» тарихы – үзе бер дәвер ул. XIX гасыр азагында бертуган Комаровлар нигез салган предприятие, гасырлар аша үтеп, үзе дә сакланып калган һәм үзенең киез итек басудагы тиңдәшсез технологияләрен дә саклый алган. Киез итек Алтын Урда чорында кулланышка кереп, тора-бара халыкның яраткан кышкы аяк киеменә әйләнгән. Уникаль комбинатның бүгенгесе һәм киләчәге, киез итекләрнең Россиянең иң салкын төбәкләрендәге кешеләрне җылытуы һәм бу җитештерүнең беркайчан да юкка чыкмаячагы турында «Кукмара киез итек басу-киез комбинаты» АҖ генераль директоры Ләлә Шәрипова сөйли.

ТЕРЕ ТАРИХ

– Кукмара комбинаты – гади фабрика гына түгел, тере тарих ул. Предприятиегә нигез салучы бертуган Комаровлар бик аздан башлаган: җирле халыктан сарык йонын сатып алып, үз машиналарында теттергән һәм өйләрендә кулдан киез итек басучыларга тараткан. «Братья Комаровы» Сәүдә йорты эшләнмәләре Казан губернасыннан бик еракта да мәгълүм булган һәм хәтта Париж белән Лейпциг халыкара ярминкәләрендә дә бүләкләр алган.

Бүген комбинат, традицияләрне саклап, әмма замана таләпләренә яраклашып, эшен дәвам итә. Без елына 266 мең пар чамасы киез итек басабыз, әмма ихтыяҗ, билгеле ки, һава торышына бәйле рәвештә үзгәрергә мөмкин.

ИТЕКЛӘР ДИЗАЙНЫ: КЛАССИКАДАН – ЗАМАНЧАЛЫККА

Кайчандыр киез итек уңайлы җылы аяк киеме генә булса, хәзер – модалы аксессуар да. Комбинат дизайнны гел үзгәртеп тора һәм хәтта иң таләпчән сатып алучыларның зәвыгын да канәгатьләндерергә тырыша. Без итекләргә аппликация ябыштырабыз, чигәбез, төрле төскә манабыз. Элек киез итекләр кара яки соры гына булса, хәзер без башка вариантлар да тәкъдим итәбез. Дөрес, манылган киез итекләргә ихтыяҗ әлегә әллә ни зур түгел – алар кыйбатрак, һәм сатып алучылар ешрак классиканы сайлый.

Киез итекләрнең дизайны заманча трендларны исәпкә алып яңартыла. Без модадан калышмаска тырышабыз, балалар һәм өлкәннәр өчен нәрсә популяр булуын ачыклыйбыз. Мәсәлән, бүген балалар итекләренә мультфильм мотивлары чигү-ябыштыру трендта. Тиңдәшсез рәсем һәм аппликацияләр булдыру

Фото Кукмара киез итек басу-киез комбинатыннан алынды. РЕКЛАМА

өчен, без махсус программалардан файдаланабыз. Аю баласы төшкән яки кар бөртекләре «кунган» киез итек киясегез килә икән – рәхим итегез!

##ҺӨНӘРГӘ ӨЙРӘТҮ

Киез итек җитештерү – чын сәнгать ул, күнекмәләр генә түгел, сабырлык та таләп итә. Яңа останы өйрәтүгә якынча ярты ел вакыт китә. Башта кеше тәҗрибәле хезмәткәрләр җитәкчелегендә эшли, һәр операцияне үзләштерә. Ярты елдан ул инде нормаларны мөстәкыйль үти һәм яхшы хезмәт хакы ала башлый.

Киез итек басу – авыр хезмәт, ул осталык кына түгел, физик чыдамлык та, бригаданың көйле эшләве дә әһәмиятле бу эштә. Комбинат эшчеләренең 60 проценты – хатын-кызлар. Киез итекне башыннан азагына кадәр бер генә кеше баса алмый – барлык операцияләрне башкару өчен, кимендә дүрт кеше кирәк. Бу – бригада эше, анда һәркем үз этабы өчен җавап бирә. Бирелә үзара ярдәмнән һәм көйгә салынган эштән башка уңышка ирешеп булмый.

КҮПЛӘП САТЫП АЛУЧЫЛАР ӨЧЕН

Бүгенге көн сатып алучылары һаман таләпчәнрәк була бара, һәм комбинат аларның бөтен ихтыяҗларын канәгатьләндерергә тырыша. Күпләп сатып алучыларга ел саен берәр яңалык кирәк. Мәсәлән, соңгы елларда аппликацияле һәм чигешле киез итекләр популяр. Балалар өчен без мультфильм геройлары белән модельләр, өлкәннәр өчен исә кырысрак, әмма барыбер стильле вариантлар әзерлибез.

Трендлар елга һәм төбәккә бәйле рәвештә дә үзгәрә. Себер кебек салкын төбәкләрдә уңайлылык һәм җылылык мөһим булса, үзәк Россиядә сатып алучылар дизайнга һәм дым үткәрми торган табанлы киез ботинкаларга күбрәк игътибар бирә. Яңа модельләрне эшләгәндә,

бу үзенчәлекләрне дә исәпкә алырга тырышабыз.

Элек без армиягә миллионышар пар киез итек җитештерә идек. Бу аерым линейка булып, аеруча чыдам һәм тиз тузмый торган итекләр бастык. Хәзер армиядән заказлар юк, тик без шул ук стандартлар буенча киез итекләр чыгаруны дәвам итәбез. Алар классик модельләрдән күпкә юкарак һәм җиңелрәк, әмма шундый ук ышанычлы.

Киез итектән тыш, комбинат киездән эшләнгән башка продукция дә чыгара. Без мунча өчен җыелмалар, киез башмаклар, сарык йоныннан сырылган юрганнар, кечкенә келәмнәр һәм декоратив эшләнмәләр җитештерәбез. Мәсәлән, безнең киез башмаклар бик уңайлы. Табигый материалдан эшләнгәнгә, алар җиңел, җылы, гомумән, өйдә кию өчен идеаль вариант. Өстәвенә, без аларны әле матур итеп тә ясарга тырышабыз.

Киездән мунча өчен җыелмалар – тагын бер хит. Киез башлык һәм бияләй – мунчада чабынырга яратучылар өчен must-have. Гәрчә безнең җитештерүдә алар беренче урында булмасалар да, үзләренә ихтыяҗ һәрвакыт бар.

САРЫК ЙОНЫ: ҮЗЕ ҖЫЛЫ, ҮЗЕ ФАЙДАЛЫ

Сарык йоныннан басылган киез итекләр һәрвакыт сәламәтлек чыганагы саналган. Сарык йоны тиңдәшсез сыйфатларга ия – ул җылыны яхшы саклый, тирене сулата һәм аллергия китереп чыгармый. Чын йоннан басылган киез итекләр бик йомшак һәм уңайлы булганга, бигрәк тә буыннары авырткан кешеләргә файдалы.

Җитештерү өчен йон Россиянең көньяк төбәкләрендә сатып алына. Әзер продукция югары сыйфатлы булсын өчен, без чималны бик җентекләп сайлыйбыз, бөтен стандартларга туры килерлек итеп чистартабыз.

КИЕЗ ИТЕКСЕЗ БУЛМЫЙ

Себердә һәм Россиянең башка салкын төбәкләрендә, бигрәк тә авылларда, киез итек һәр гаиләдә дә бар. Быел кыш җылы булып, сату бераз кимесә дә, Себердә киез итексез барыбер яшәп булмый. Без продукциябезне Новосибирск, Магнитогорск, Чиләбегә һәм башка шәһәрләргә җибәрәбез. Халык безнең киез итекләрне көтеп ала, чөнки аларның иң каты суыкларда да җылытачагын яхшы белә.

ӘЙЛӘНӘ ДӘ КИЛӘ КЫШЛАР...

Россиядә кыш төрлечә булырга мөмкин: кайчагында быелгы кебек җылы, кайвакыт исә бик суык. Әмма Россиядә кыш һәр ел саен кабатлана, һәм киез итек тә һәрвакыт кирәк булачак.

Киез итек – мәдәниятебезнең, тарихыбызның бер өлеше ул. Кукмара итекләре кешеләрне тагын күп еллар буе җылытсын өчен, хәлебездән килгәннең барысын да эшләрбез. Т

КУКМОРСКИЕ ВАЛЕНКИ

Күпләп сату бүлеге:
e-mail: opt@kvvk.org
Телефоннар: (84364) 2-08-31,
8-800-250-11-32

Фирма кибете:
Кукмара шәһәре,
Вахитов ур., 1 йорт
Телефон: (84364) 2-08-78

ЭМИЗ гастромәйданы – традицияләрне саклыйбыз һәм мәдәниятләрне берләштерәбез

Банкетлар Китерү Кейтеринг

ЭМИЗ

8 (843) 245 00 55 | Татарстан Республикасы, Казан ш., Сафиуллин ур., 29

ЭМИЗ: йөземнең бар көче һәм файдасы – һәр йотымда

Премиаль сыйфат һәм кабатланмас тәм

ЛАУРЕАТ 2023 100 ЛУЧШИХ ТОВАРОВ РОССИИ КОНКУРСА

2023 ЛУЧШИЕ ТОВАРЫ И УСЛУГИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

100% ECO PRODUCT

NATURAL 100%

HALAL

emiz.ru

8 800 444 09 37

РЕКЛАМА

СКАНДИНАВИЯ
ИГЪТИБАРЛЫ МЕДИЦИНА КЛИНИКАСЫ

(843) 200-10-65

«Скандинавия» клиникасының бала тудыру йортында ислам кануннарына туры китереп бәби табарга була

Клиникабыз Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хәләл» стандарты комитеты тарафыннан бирелгән таныклыкка ия, ул ислам кануннары нигезендә бәби таптыру мөмкинлеген раслый.

- Палатада кеше һәм хайван сурәтләре, шулай ук исламның әхлакый-этик нормаларына каршы килгән предметлар һәм рәсемнәр юк.
- Намаз уку өчен кирәкле атрибутлар (Коръән, намазлык, тәсбихләр) бар. Изге Кәгъбә юнәлеше билгеләнгән.
- Туалет бүлмәләрендә тәһарәт алу өчен кирәкле һәрнәрсә бар.
- Хатын-кыз табиблардан гыйбарәт махсус бригада оештырылган.
- Хәләл ризык бирелә.
- Дарулар һәм дәвалау максатларында кулланыла торган әйберләрнең ислам кануннары буенча медицина хезмәтләре күрсәткәндә файдалануга рөхсәте һәм шуны раслаган документлары бар.
- Хатын-кыз бала табу бүлегендә йөргән чакта, махсус кагыйдәләр үтәлә: аны чит кешеләр һәм клиника хезмәткәрләре күрми.

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хәләл» стандарты комитеты» продукция сыйфатын контрольдә тоту шәхси учреждениесе.

Бала тудыру йорты сайтына кучү өчен, QR-кодны сканерлагыз.

ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЛӘШҮ ТАЛӘП ИТЕЛӘ

ЛИЦЕНЗИЯ БЕЛӘН КЛИНИКА САЙТЫНДА ТАНЫШЫРГА БУЛА. РЕКЛАМА

акыллы гамәлләр
игелекле эшләр
мәңгелек кыйммәтләр /

Бу санда тәкъдим итәбез:

Бәрәңгене **ничек** дөрес үстерергә

Татарстанда ак барсны **ничек** саклыйлар

Бизнеста **ничек** шаһинә булырга

Алабуга шәһәрлеген **кемнәр** күтәргән

ИСКЕ БӘРӘҢГЕГӘ – ЯҢА КАРАШ...

Руфия Фазылова

«Йодрык кадәрле,
Йомры гәүдәле,
Ак тәнле,
Аһ, тәмле,
Бигрәк тәмле бәрәңге!» –дип җырлый безнең халык. Тагын әле без аны икенче икмәк дип тә атыйбыз. Бәрәңге заманында күпме кешене ачлыктан йолып калган ризык. Бүген дә аннан башка тормышны күз алдына китереп булмый. Шуның өчен дә яз җитүгә, күпләр бәрәңге утырту мәшәкатьләре артыннан йөри башлый.

Татарстан шартларында бәрәңге утырту өчен кулай вакыт кайчан? Мул уңыш алу өчен нәрсә эшләргә кирәк? Шушы һәм башка күп кенә сорауларга Татарстан авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институтының бәрәңге үстерү үзәге баш белгече Фәния Җамалиева җавап бирде.

– Фәния ханым, республикада бәрәңге тармагын сездән дә яхшырак белүче юктыр. Бу тармакны ничек сайладыгыз?

– Без бит авыл балалары, кечкенәдән бәрәңге ашап, бәрәңге басуында эшләп үстек. Безнең Арча районында бу культура бигрәк тә популяр. Басуда трактор бәрәңге алганны бик игътибар белән карап торганым әле дә истә.

Ә мәктәптә укыганда биология белән кызыксындым, дип әйтә алмыйм, чөнки математиканы бик яраттым. Ул ничектер җиңел дә бирелде миңа. Тик югары сыйныфларда биология белән мавыгып киттем. 1975 ел: төрле кызыклы ачышлар, тәҗрибәләр турында сөйли, яза башладылар. Күрәсең, менә шулар мине кызыктырган. Тик беренче елны укырга керә алмадым. Документларымны КДУның биология факультеты, генетика кафедрасына биргән идем. Ярты балл җитмичә, конкурстан төшеп калдым. Икенче елны исә документларны биология факультетының умырткасызлар зоологиясе кафедрасына тапшырдым. Һәм конкурстан уздым. Әнә шулай итеп студент булдым. Университет ул фәнни юнәлештәге белгечләр әзерли,

Фото: Александр Ефремов, «Татарстан» архивыннан

биш ел уку дәвамында шуңа инандым. Никтер бу миндә әллә ни зур кызыксыну тудырмады. Дөресрәге, кешеләргә конкрет файда китергән юнәлештә эшлисем килде. Әлбәттә, фәнне дә өйрәнү кирәк. Тик, әйткәнемчә, мине башкарак өлкә кызыксындырды.

Университетны тәмамлагач, Татарстан авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институтына эшкә урнаштым. Монда күбрәк файда китерермен кебек тоелды. Нәтиҗәдә, шулай килеп чыкты да. Беренче көннәрдән үк бирдә Капитонова Нина Петровна кул астында эшли башладым. Ә ул нәкъ менә бәрәңге тармагын өйрәнә. Нина Петровна бәрәңгене вируссыз үстерү юлларын тикшерә иде. Ягъни бәрәңгене пробиркада үстерәләр дә аннан соң аерым җиргә утырталар. Монда инде бер авыруларсыз үскән була ул. Гадәттә бакчаларда үскән бәрәңге еллар дәвамында үзендә төрле чирләр җыя. Аны тазартып булмый. Черегән алып ташласаң да, вируслар башка бәрәңгеләрдә кала. Иң кызганычы – аның уңышы да түбән була. Хәтерлим, ул чакларда, күп дигәндә, гектарыннан 10-15 тонна бәрәңге чыга иде. Һәм 80 нче еллар башында, бу проблемага зур игътибар бирелә башлагач, нәтиҗәләр күпкә үзгәрде. Шул исәптән – Татарстанда да.

– Яхшы, лаборатор шартларда вируссыз бәрәңге орлыгы үстерелде, ди. Шуннан аны җиргә чыгарып утырттылар. Тора-бара ул барыбер вирусланадыр бит?

– Пробиркада шыткан бәрәңгене башта аерым теплицаларда үстерәләр. Сез дөрес фикер йөртәсез, тора-бара ул бәрәңге дә барыбер вируслана. Безнең шартларда, ягъни Татарстанда бу процесс бигрәк тә тиз бара, чөнки аны гөблә (үлән бете) тарата. Хәтта бер-ике ел эчендә бәрәңге вируслыга әйләнергә мөмкин. 2009 елда яклаган докторлык диссертациямне дә әлеге проблемага багышладым. Ундүрт ел дәвамында бәрәңге сортларының үлән бетеннән ничек зарарлануын, аның белән көрәш юлларын өйрәндем. Орлыклык бәрәңгене төньяк зонада, Архангельск тирәләрендә үстерергә кирәк, дип әйтәләр иде безгә. Бу аңлашыла да, анда үлән бете өчен шартлар начар, шуның өчен вируслар үрчи алмый. Тик безнең тикшеренүләр Татарстанда да орлыклык бәрәңге үстерергә мөмкин икәнне раслады. Моның өчен берничә шартны үтәргә кирәк. Беренчедән, пробиркада үстерелгән орлык бәрәңгебез вирустан чип-чиста булырга тиеш. Икенчедән, орлык бәрәңгене беренче елны ук зур күләмдә аерым майданнарда үрчетә башларга кирәк, чөнки кечкенә басуда ул тиз зарарланып бетәргә мөмкин. Әлбәттә, бу гади бакчачыларга бик кагылмый, монда орлыклык бәрәңге үстерү турында сүз бара.

– Быел яз бик иртә килде. Халык бәрәңгене елдан-ел иртәрәк утырта кебек. Быел тагын да ашыгырлар, дип уйлыйм. Бәрәңгене кайчан утыртырга кирәк?

– Бәрәңгене җир җылылыгы 8 градуска җиткәч утыртырга тәкъдим ителә. Салкын җиргә утыртудан файда юк – ул, озак тишелмичә ятудан тыш, авыруларга да бирешергә

мөмкин. Иртә утырткан бәрәңгене ризоктония авыруы зарарларга мөмкин.

Каен яфраклары бер тиенлек акча зурлыгында булгач, бәрәңге утыртырга киңәш итәбез. Шулай ук эшкәртелгән туфрак артык юеш тә, артык коры да булмасын. Туфракны учка йомарлап тоткач, ул оешырга һәм чәчеп җибәргәндә таралып китәргә тиеш. Быел җир тизрәк өлгерер кебек. Әмма иртә утыртуның бер куркынычы бар: гадәттә, май башында көннәр суытып җибәрә. Ә бу исә, әйткәнемчә, бәрәңгегә зыян салырга мөмкин. Татарстан җирлегендә бәрәңгене 9 майдан соң курыкмыйча утыртырга мөмкин.

Гадәттә, безнең зонада кыраулар 7 июньгә кадәр була. Ә узган ел 13 июньдә дә кырау төште. Тишелгән бәрәңгеләр өшеде. Күпләр курыкты. «Борчылмагыз, яңадан сабак чыгарачак ул», – дип тынычландырдык ул чакта халыкны. Һәм чынлап шулай булды да. Бәрәңгенең иртә өлгерә торган сортлары бар, аларны соңга калып утыртмыйлар. Шуның өчен бәрәңге тишелеп чыккач, салкыннар китә икән, пленка белән каплап торырга киңәш итәбез. Хәзер бит элеккеге кебек зур бакчалар түгел. Бәрәңгене хасиятләп үстерергә мөмкинлек бар.

Тагын бер киңәш: бәрәңге тишелгәч, салкыннар башланса, туфрак белән өяргә була. Яшь сабаклар җир астында кала дип куркасы түгел, ул барыбер чыга.

– Татарстан авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институты 20 елдан артык селекция белән шөгыльләнә. Үзегез уйлап тапкан бәрәңге сортлары да шактый, дип беләм. Аларның кайсыларын аеруча уңышлы дип әйтә аласыз?

– Әйе, безнең институт бу өлкәгә зур игътибар бирә. Бүген бездә селекционерлар эшли. Бу бик мөһим өлкә, чөнки үзебезнең шартларга яраклашкан бәрәңге уңышны яхшы бирә. Шунысы да бар: чит илдән алып кайткан сортлар кыйммәткә дә төшә.

Бүген Татарстан авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институты уйлап чыгарган уннан артык сорт бар. Алар барысы да тәмле, Татарстан шартларына чыдам сортлар: «Кортни», «Регги», «Танго», «Зумба», «Самба», «Сальса», «Орлан» һәм башкалар. Тик шуны аңларга кирәк: идеаль сорт бәрәңге юк. Кайсыдыр югарырак уңыш бирә, кайсыдыр тәме буенча әйбәтрәк.

Мисал өчен, зур хуҗалыклар чит илдән кергән «Гала» сортын ярата. Язга кадәр яхшы саклана ул. Дөрес, «Гала» сорты дым ярата, ягъни коры елны су сипмәсәң, уңыш начар була. Эксперимент рәвешендә төрле сортны утыртырга мөмкин, чөнки уңыш җирнең нинди булуыннан да тора.

– Бәрәңгенең сортлары гына түгел, авырулары да күбәйде кебек. Алар белән ничек көрәшергә? Һәм ул чирләр нәрсәдән барлыкка килә?

– Әйе, алар күп: фитофтороз, альтернариоз, алтынсу нематода... Соңгысы аеруча куркыныч, чөнки ул очракта бәрәңгенең уңышы бөтенләй булмый. Нематода ул шундый суалчан. Бәрәңгенең тамырына кечкенә сары күкәйләр сала. Нәтиҗәдә, бәрәңге корый. Иң аянычлысы – ул туфракта бик озак еллар саклана. Җирне дәваламыйча, нематодадан котылып булмый. Хәзерге яңа чит ил бәрәңге сортлары нәкъ менә туфракта булган алтынсу нематоданы юк итә. Ягъни теге суалчан бәрәңгене ашый һәм үлә. Әле менә яңа гына хәбәр булды: Татарстанның бер хуҗалыгында алтынсу нематода тапканнар. Әгәр аның белән көрәшмәсәң, ул тагын да үрчи.

Авырулар бит яңарып тора. Һәм алар белән көрәшү ысуллары да үзгәрә, заманчалаша. Бездә хәзер көньякта гына очрый торган бәрәңге авырулары да күзәтелә башлады. Климат үзгәрә, бәрәңгеләрне төрле җирләрдән алып кайталар. Нәтиҗәдә, менә шундый хәлләр.

– Бездә кара яки көлсу туфрак та, кызыл балчык та бар. Бәрәңге җирнең нинди булуына карап утыртылырга тиешме?

– Бәрәңге төрле туфракта да әйбәт уңыш бирергә мөмкин, әмма һәр туфракның үзенчәлекләре бар. Комлы туфрак ярлырак, көпшәк туфрак суны тиз сеңдерә һәм тиз югалта. Корылык шартларында мондый туфракта иртә өлгерешле сортлар мул уңыш бирә. Кара туфрак – туклану элементларына да, органик матдәләргә дә бай була. Суны да яхшы саклый. Мондый туфракта теләсә нинди сорт та яхшы уңыш бирә. Кызыл балчык та бәрәңге культурасы өчен начар түгел,

бай туфрак санала, тик яңгырлар еш яуса, мондый бакчаларда бәрәңгенең тамыры чери башлый. Иң мөһиме – туфракта җитәрлек туклыклы элементлар булсын, җир йомшак һәм анда җитәрлек дым булсын.

– Соңгы елларда бәрәңгене колорадо кортына каршы агулап утырта башладылар. Моңа мөнәсәбәтегез ничек? Ул чынлап та булышамы?

– Аерым хуҗалыклар бәрәңгене агулап утырту өчен күптән инде «Престиж» препаратын куллана. Аның составында – неоникотиноид һәм фунгицид, ул Россиядә рөхсәт ителгән. Үзем дә «Престиж» белән агулап утыртуга каршы түгел, чөнки аның кеше сәламәтлегенә әллә ни зыяны юк. Хәтта тикшерүләр шуны күрсәтте: язын кулланган агуның микъдары җәй көне сиптергәнгә караганда кимрәк тә. Җәен 20–30 сутый бакчага агу сиптергәндә, ул күбрәк мәйданга тарала, ул кешегә дә, табигатькә дә зыян сала. Язын эшкәртүнең плюслары күбрәк: көннәр кызу булмагач, агу кешегә ул кадәр нык тәэсир итми, бу вакытта бал кортлары да актив очмый, агулап утырткач, ул бәрәңгене 2 ай саклый. Агу яфракларда 60 көнгә кадәр саклана һәм колорадо коңгызын юк итә бара. Яңа очып килгәннәрен дә, кышлап чыкканнарны да.

Тик аны белеп кулланырга кирәк: 100 кило бәрәңгегә 100 мл препарат җитә. Монда шунысы мөһим: 100 мл препаратны эретер өчен ярты литр су җитә. Югыйсә кемдер агуны бишәр литр суга ясый да файдасын күрми. Агу су белән агып чыгып китмәсен өчен, катнашма дөрес ясалган булырга тиеш.

– Бәрәңгене еллар буе бер үк урынга утырту дөресме?

– Әлбәттә, ел саен бер урынга утыртканда, бакчаның уңдырышлылыгы кими һәм ул төрле авыруларга, корткычларга да ешрак бирешә. Шулай ук күпьеллык чүп үләннәре дә барлыкка килә. Эт эчәгесе үләне генә дә ни тора. Шуңа күрә чәчү әйләнешен (севооборот) көйләргә тырышырга кирәк. Бакчаны тулысы белән булмаса да, ярты өлешкә бүлеп, ял иттереп алу мөһим. Бәрәңгесез җиргә ике еллык үлән чәчеп тора аласыз. Шулай эшләгәндә, җир туклана, авыру-корткычлардан арына, туфракның структурасы яхшыра.

– Элек бәрәңгене гел ярып утырталар иде. Хәзер, киресенчә, бөтен көенчә утыртырга тырышабыз. Кайсы очракта уңыш яхшырак була?

– Бөтен килеш утырткан бәрәңге яхшырак. Әгәр инде чәчүлек бәрәңге кыйммәтле яки дефицит булса, кисми дә хәлең юк. Безгә дә орлыклык бәрәңгене шулай утыртырга туры килә. Шуны гына истә тотарга кирәк: кискәндә пычакны марганцовка эремәсенә тыгып алу шарт.

– Бәрәңге утыртканда төп киңәшләр?

– Бәрәңгене 8-10 см тирәнлектә утырталар. Артык тирәнгә утыртмаска киңәш итәм. Шул ук вакытта аның түбән өеп торырга кирәк. Тирән утырткан бәрәңге яңгырлы елларда җирдә үк чери. Уңышның иң беренче сере – яхшы орлыкта. Икенчесе – җирнең яхшы булуында, өченчесе – бәрәңге игү технологиясен үтәү. Җирне ашлап, йомшартып торырга кирәк. Коры елларда аңа су сибәргә дә онытмагыз. Шулай ук бәрәңгене зарарлый торган фитофтора, фузариоз, парша кебек авыруларга каршы көрәшү мөһим. Бакча ярлы икән, 10 сутыйга 3–5 тонна тирес кертергә кирәк. Тиресе булмаган бакчачылар 30–50 кило азофоска куллана ала. Шәхси яшелчә бакчаларында еш кына кальций һәм магний ачлыгын күзәтергә мөмкин. Шуңа күрә туфракка шулай ук доломит оны (1 сутыйга 30 кг) һәм кальций селитрасы (1 сутыйга 1 кг) кертергә киңәш итәм. Бу бәрәңге уңышын сизелерлек арттырырга ярдәм итәчәк.

– Фәния ханым, гадәттә, безгә килгән кунактан аның кызыксынулары, гаилә тормышы турында да сорашабыз. Сезнең турында да беләсебез килә...

– Җәмәгатем белән бер кыз, бер ул үстердек. Алар минем юлдан китмәде. Аллага шөкер, гаиләмдә иминлек. Инде оныгыбыз да бар. Балалар кечкенә чагында ук Санкт-Петербург, Пушкин шәһәрләренә барып, кандидатлык диссертациясен яклады, аннан соң докторлык эше өстендә күп утырдым. Әти-әнием дә, гаиләм дә гел терәк булды. Фән кешесе өчен болар бик мөһим. Бүгенге көндә дә якыннарымның җылысын тоеп яшим.

РЕСПУБЛИКАБЫЗНЫҢ ЗАТЛЫ АК БАРСЫ САКЛАУГА МОХТАҖ...

Николай Крушинин

Ак барс, җитмәсә әле канатлысы, Татарстанда беркайчан да яшәмәгән. Алай булгач ник соң әле ул республикабыз гербына төшерелгән дисезме? Герб герое гына да түгел ул хәзер, беләсегез килсә! Быел, 12 мартта, барс Казанда узган халыкара конференциянең төп героена әйләнде. «Дөньяда кар барсын өйрәнү һәм саклау. Тырышлыкны берләштерү» дип аталган бу чарага бөтенләй юкка чыгу куркынычы янаган әлеге хайванның язмышын кайгыртучы вәкилләр 12 илдән килгән иде.

Барлык бу илләр дә – ирбисның яшәү ареалы: Әфганстан, Бутан, Кытай, Һиндстан, Казахстан, Кыргызстан, Монголия, Непал, Пакыстан, Россия, Таҗикстан һәм Үзбәкстан. Конференция кунаклары арасында Һиндстаннан Билал Хәбиб, Кытайдан Кун Ши кебек исемнәре бөтен дөньяга танылган галимнәр дә бар иде.

Ә Казанның ирбиска нинди катнашы бар соң? Ни өчен татарларның борынгы бабалары булган Идел буе болгарлары аны үзләренең яклаучысы дип санаган?

Тарихчылар әллә никадәр документаль дәлил һәм матур легенда китерсә дә, бу бары тик ак барска карата булган мәхәббәткә генә кайтып кала, ахрысы. Татарстанлылар ак һәм йөнтәс барсларны үлеп ярата. Ә менә ни өчен – монысына инде тәфсилләбрәк тукталыйк.

АЛТАЙ РЕСПУБЛИКАСЫ – «КАР БАРСЫ ҮЗӘГЕ»Н ТӨЗҮ ӨЧЕН ИДЕАЛЬ УРЫН УЛ. ҖИТӘКЧЕЛЕК ТУЛЫСЫНЧА ХУПЛЫЙ. БАРСНЫҢ БӨТЕНЛӘЙ ЮККА ЧЫГУЫН ТЕЛӘМИБЕЗ БИТ! БЕЗНЕҢ ГАЯТЬ ЗУР ИЛЕБЕЗДӘ НИБАРЫ 90 БАШКА ЯКЫН КАР БАРСЫ ИСӘПЛӘНӘ! Ә КЫТАЙДА АЛАР – 4 МЕҢ! БҮГЕНГЕ ФОРУМ БАРС ЯШИ ТОРГАН БАРЛЫК ИЛ ҺӘМ ТӨБӘКЛӘРНЕ ҖЫЙДЫ. **БЕЗ – БЕРДӘМ. МИНЕМЧӘ, БҮГЕНГЕ РЕЗОЛЮЦИЯНЕҢ ДӘВАМЫ ДА БУЛАЧАК ӘЛЕ.**

Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Республикасы Рәисе

БОЛГАРЛАРДАН КҮЧКӘН МӘХӘББӘТ

Матур ак мехлы кыргый мәче Татарстаннан еракта – Алтай тауларында яши. Әмма герб бит ул символик мәгънәгә ия. Безнең «ак мәченең» канатлары да бар, һәм алар аңа Алтай таулары аша очып үтәр өчен бирелмәгән. Без еракка карак – хәзерге татарларның борынгы бабалары саналган болгарлар янына очыйк әле.

Кайбер тарихчылар фикеренчә, зур ак мәчеләр турындагы легендаларны болгар кабиләләре үзләренең элекке ватаннарыннан – Кара диңгез буе һәм Кавказдан алып килгән. Аларга безнең төбәккә VII гасырда Хәзәр каһанлыгы белән каршылыклар көчәйгәч күченергә туры килгән. Башка тарихчылар ирбиска мәхәббәтне борынгы болгарларның барсил кабиләсе белән бәйли, аны «барс нәселе, ыруы» дип тә тәрҗемә итәләр. Өченче берәүләр исә Идел болгарлары ак барсны уңдырышлылык алласы һәм балаларны яклаучы буларак хөрмәтләгән, дигән фикердә. Дүртенчеләр астрология һәм тел үзенчәлекләре белән бәйләмәкче була: янәсе, борын-борын заманда шәрык календаренда Идел болгарларының әлгәрләре юлбарыс елын «Барс елы»на үзгәрткән... Бишенче берәүләр исә XVI гасырга караган «Титулярник»та тасвирланган «Болгар кенәзе (ягъни Идел Болгары хакиме. – ред.) гербына» таяна. Анда уң аягын күтәргән барска охшаган хайван сурәтләнгән. «Титулярник» авторы хайванны «пардус» дип атый, әйтергә кирәк, элек капланны да, гепардны да шулай атаганнар. 1666 елгы «Болгар гербында» һәм дәүләт флагында да барс сурәтләнгән...

ТАТАРЛАР ОЛЫЛАГАН ХАЙВАН

Димәк, барыбер бөтен юллар да ак барска таба илтә. Һәм 1992 елда ак барс сурәтләнгән герб Татарстан Республикасы Югары Советы сессиясендә раслана.

Символ сыйфатында барсны ул чакта филология фәннәре кандидаты (соңрак – филология фәннәре докторы), Ш.Мәрҗани исемендәге мәдәният җәмгыятенең вице-президенты Назыйм Ханзафаров тәкъдим итә.

Фото: goodfon.ru.ru

КАР БАРСЫ ПОПУЛЯЦИЯСЕ КИМҮНЕҢ ТӨП СӘБӘПЛӘРЕННӘН БЕРСЕ – БРАКОНЬЕРЛЫК, ҺӘМ УЛ МАКСАТЧАН ГЫНА ТҮГЕЛ, ОЧРАКЛЫ ДА БУЛЫРГА МӨМКИН, МӘСӘЛӘН, БОЛАННАРГА ҺӘМ БАШКА ХАЙВАННАРГА ДИП КУЕЛГАН ТИМЕРЧЫБЫКЛЫ ЭЛМӘКЛӘР ЯРДӘМЕНДӘ. ШУЛАЙ УК ЕРТКЫЧНЫҢ ТӨП РИЗЫГЫ САНАЛГАН ТОЯКЛЫЛАР САНЫНЫҢ КИМҮЕ ДӘ ТӨРНЕҢ ЮККА ЧЫГУЫНА ЯНЫЙ. ШУНЫҢ АРКАСЫНДА ЙОРТ ТЕРЛЕКЛӘРЕНӘ ҺӨҖҮМ ИТӘРГӘ МӘҖБҮР БУЛГАН ЕРТКЫЧЛАРНЫ ҖИРЛЕ ХАЛЫК АТЫП ҮТЕРӘ.

Аның фикеренчә, Идел болгарларында байлык, уңдырышлылык һәм затлылык символы саналган канатлы барс Татарстан гербында үзәк урынга куелырга тиеш була. Ак барс гәүдәсенең һәр өлеше нәрсәнедер белдерә. Тырнак һәм тешләре – көч һәм яклауны. Бераз күтәрелгән алгы уң аягы югары хакимиятнең бөеклегенә ишарә ясый. Өскә күтәрелгән койрыгы ышаныч һәм ирек сөюне күрсәтә. Барс канатының җиде каурыйга бүленеше җиде кат күккә ишарәли. Барс тәңречеләр табынган кызыл кояш җирлегендә сурәтләнә – ә Идел болгарларының күбесе ислам динен кабул иткәнче Тәңрегә инана. Кызыл кояш аяз күк йөзе, тынычлык, сафлык, игелек, бәхет символы булып тора.

Гербның фәнни нигезләмәсеннән без барсның «борынгы заманнарда халык табынган хайван, болгарларның дәүләт символы булуын» аңлыйбыз. Авторлар фикеренчә, герб татарстанлыларның үзләренең борынгы мәдәнияте һәм татар халкының дәүләтчелек традицияләре белән горурлануын һәм аларны хөрмәт итүен күрсәтә. Барлык символларны да берләштереп, «тотем» хайванны гербка рәссам Риф Фәхретдинов ясый.

– «Экология» милли проекты кысаларындагы биотөрлелекне саклау федераль программасына кар барсын саклау программасын кертергә Татарстан тәкъдим итте. Кар барсы республикабыз символы булып тора, ул барлык төрки халыкларның изге (тотем) хайваны санала, һәм аны саклау – безнең бурычыбыз, – дип искәртте конференция ачылышында ТР экология

һәм табигый ресурслар министры Александр Шадриков.

СИМВОЛДАН – САКЛАУГА

«Тотем» хайванны шулкадәр яратуга карамастан (кар барсы, Татарстанныкыннан тыш, тагын әле Хакасиянең, Алматы, Сәмәрканд, Бишкәк шәһәрләренең һәм Красноярск краендагы Шушенское районының да гербларын бизи), дөньяның 12 илендә яшәүче зур ак мәчеләр аларның барысында да сирәк очрый яки бөтенләй юкка чыгу куркынычы алдында тора. Россиядә хәзер барлыгы 90 лап ирбис исәпләнә. Бу гүзәл җан ияләре Саян экотөбәгендәге Алтай тауларында яши, дәүләт тарафыннан саклана, әмма аларга барыбер браконьерлар һөҗүме, инфраструктура үсеше, зыян күргән терлек асраучыларның үче һәм климат үзгәрешләре яный.

Кар барсы яшәгән илләрдә 2013 елдан «Кар барсын һәм аның экосистемаларын саклау буенча глобаль программа» кабул ителгән, ул җанварларны саклау буенча махсус чаралар күрүне (браконьерлыкка каршы көрәш, аеруча саклана торган табигать территорияләре булдыру, асраган маллары кар барсыннан зыян күргән фермерларга субсидияләр бирү һ.б.) күздә тота.

РЕСПУБЛИКАЛАРНЫ БЕРЛӘШТЕРӘ

Үзенең «тотем хайваны» популяциясен саклауга Татарстан күптән инде актив кушылган. Биредә сирәк очрый торган мәчесыманнарны өйрәнү буенча «Ак Барс» үзәген булдыру проекты эшләнгән. Ул «Биологик төрлелекне саклау һәм экологик туризмны үстерү» федераль проектына кертелгән.

Климат үзенчәлекләрен исәпкә алып, «Кар барсы» биологик төрлелекне саклау үзәген Алтайда, Маймин районындагы «Карым» комплексы территориясендә урнаштырырга карар кылалар. Ул чакта, 2023 елның гыйнварында, Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов һәм Алтай башлыгы Олег Хорохордин төп фәнни бурычы хайваннарның халәтен мониторинглау, аларны ясалма үрчетү, яралы яки зәгыйфьләнгән кыргый хайваннарны тернәкләндерү ысулларын эшләү булган үзәк булдыру турында килешә.

Ә БҮГЕН?

«Ирбис» кар барсын өйрәнү һәм саклау үзәге» төбәкара ассоциациясенең күзәтү советы рәисе Али Узденов әйтүенчә, узган унъеллыкта Россиядә нибары 10 баш ирбис исәпләнгән. Хәзер исә аларның баш саны 87 гә җиткән.

– 2024 елда без энтузиастлар көче белән беренче бөтенроссия кар барсы җанисәбен алуны оештырдык. – ди ул. – Барлыгы 3 мең километрдан артыграк юл үтелде, 400 дән артык фототозак тикшерелде, 200 мең фотосурәт өйрәнелде. Ясалма фәһем ярдәмендә без Алтай территориясендә – 54, Тыва Республикасында – 15, Красноярск краенда – 1, Бурятиядә 7 барс яшәвен ачыкладык. Кызганыч ки, кайчандыр кар барсы яшәгән Иркутск өлкәсендә һәм Хакасиядә ул очрамады.

УЗГАН УНЪЕЛЛЫКТА РОССИЯДӘ НИБАРЫ 10 БАШ ИРБИС ИСӘПЛӘНГӘН. ХӘЗЕР ИСӘ АЛАРНЫҢ БАШ САНЫ 87 ГӘ ҖИТКӘН. БУ ТӨРНЕҢ БӨТЕН ДӨНЬЯДАГЫ САНЫННАН ИКЕ ПРОЦЕНТТАН ТА КИМРӘК. **2030–2035 ЕЛЛАРГА РОССИЯДӘ ИРБИСЛАР ПОПУЛЯЦИЯСЕН 150 БАШКА ҖИТКЕРҮ ПЛАНЛАШТЫРЫЛА.**

РФ Табигый ресурслар һәм экология министрлыгының Аеруча саклана торган табигать территорияләрен үстерү тармагында дәүләт сәясәте департаменты директоры Ирина Маканова әйтүенчә, Россиядә ирбислар саны төрнең бөтен дөньядагы санынннан ике процентган да кимрәк.

Ул ирбисларның гомерен саклауга юнәлтелгән чараларга мисаллар китерде. Мәсәлән, 2022 елда «Тыва» табигать паркында мөгезле вак терлек көтүләре булдырылган – әгәр кар барсы фермерның сарыгын бугазлый икән, терлек асраучыга компенсация итеп башка сарык бирелә.

Браконьерларга килгәндә исә, аларга каршы көрәшкә, дәүләт инспекторларыннан тыш, волонтерларны да, җирле халыкны да җәлеп итү сорала.

РФ Табигый ресурслар һәм экология министрлыгы аеруча саклана торган табигать территорияләре челтәрен киңәйтүне дә кайгырта. Кар барсы яшәгән төп урыннарның әлегә нибары 16 проценты гына дәүләт тарафыннан саклана.

Ирина Маканова әйтүенчә, 2030–2035 елларга Россиядә ирбислар популяциясен 150 башка җиткерү планлаштырыла.

Конференциянең беренче көне азагында кар барсын саклау буенча Казан резолюциясе кабул ителде.

Фотолар Раджана Солтанова архивыннан. РЕКЛАМА

БИЗНЕСТА НИЧЕК ШАҺИНӘ БУЛЫП КАЛЫРГА:

РАДЖАНА СОЛТАНОВА РУХИ МИРАС, ЛИДЕРЛЫК ҺӘМ БАЛАНС ТУРЫНДА

Олеся Бондаревская

Бүген традицияләр – чикләү түгел, ә бәлки тиз үзгәрүчән дөньяда тотрыклылыкны саклау мөмкинлеге бирә торган ресурс ул. «Тәрҗемәләр дөньясы» агентлыгын оештыручы һәм гүзәллек конкурслары җиңүчесе Раджана Солтанова ничек итеп гаилә кыйммәтләренең кыю карарлар һәм үсеш өчен таяну ноктасына әйләнүе турында сөйли.

– Былтыр октябрьдә Көньяк Кореядә узган «Галәм гүзәле» конкурсында сез дизайнерлар бәйге өчен махсус уйлап тапкан милли күлмәктән идегез. Ни өчен нәкъ менә төрки кием сайларга булдыгыз?

– Милли кием – үз халкыңның мәдәни коды ул: элгәрләрнең гореф-гадәтләрен күрсәтү дә, әлеге кыйммәтләрне киләчәк буыннарга тапшыру да, киемнең формасы, бизәлешендәге мәгънәләрне варисларга аңлату да. Мин милли киемемдә үзем тәрбияләнгән азәрбайҗан традицияләрен дә, төрки мәдәниятләрне берләштергән символларны да чагылдырып, төп принциплардан берсен – гармония һәм бердәмлекне күрсәтергә омтылдым. Шулар барысы бергә Галәмне тәшкил итә дә бит инде! Конкурс аудиториясенең мине сүзсез дә аңлавын теләдем. Милли киемемнең авторы Элара Камил кызы Шәйхигә зур рәхмәтемне җиткерәсем килә. Ул – Татарстан Республикасы Дизайнерлар берлеге советының мактаулы әгъзасы, Казандагы BURO BANU брендына нигез салучы, милли кием өлкәсендә танылган эксперт.

«МИН ҺӘРВАКЫТ ҮЗ ГАИЛӘМӘ ЛАЕК БУЛЫРГА ТЕЛӘДЕМ»

– Сез «Галәм гүзәле» конкурсында Азәрбайҗан данын якладыгыз. Бу сезнең өчен мөһимме?

– Минем әти-әнием – Азәрбайҗандагы кенәзләр нәселеннән. Алар 1987 елда Татарстанга күчеп килгәч, мин Казанда тусам да, безнең гаилә милли гореф-гадәтләребезне саклап калды. Мин үз ата-бабаларыма бик рәхмәтле һәм нәсел-нәсәбем белән бик горурланам. Шунлыктан минем бу конкурста катнашуым – кече ватаныма һәм тамырларыма хөрмәт билгесе дә.

– Традицион тормыш рәвеше хатын-кыз йорт һәм балаларны карарга, бизнес белән исә ирләр шөгыльләнергә тиеш, дип саный. Сез исә студент вакытта ук үз компаниягезне булдыргансыз һәм инде аның белән 15 елдан артык җитәкчелек итәсез. Болар ничек яраша соң?

– Әтием искиткеч игелекле кеше иде. Аны безнең райондагы күп кеше белде һәм хөрмәт итте. Ул эшләдә, әнием хуҗабикә иде. Әти эштән кайтканда, без аны каршыларга алгы бүлмәгә чыга идек, барыбыз да чыкмыйча, ул бусагадан атлап кермәде. Миңа 14 яшь чагында әтием бакыйлыкка күчте, һәм тормышыбыз кискен үзгәрде. Әнием эшкә чыкты, мин сеңелләремне карадым, өйне тәртиптә тоттым. Бу җаваплылык минем киләчәгемне хәл итте дә инде.

– Максатчанлык һәм тырышлык сезнең гаиләгә хас сыйфатлармы?

– Мин шулай дип уйлыйм. Бабамның әтисе Мәһди Исмаил оглы Солтанов һәм аның җәмәгате Мирзә ханымның революциягә кадәр үз хуҗалыгы булган, крестьяннар аларны ихтирам иткән. Минем бабам Бөек Ватан сугышында катнашкан, батырлыгы өчен II дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән бүләкләнгән. Әтием бик лаеклы, кешелекле иде. Аның вафатыннан соң әнием югалып калмады, эшкә чыкты, урта белемле генә булса да, тормышыбызны алып барды. Мин һәрвакыт үз гаиләмә лаек булырга омтылдым, шуңа күрә сигезенче сыйныфтан ук Казан дәүләт университетына укырга керергә әзерләнә башладым. Әтием минем һичшиксез укырга керәчәгемә ышанды, һәм шулай булды да.

«ӨСТЕНЛЕКЛӘР ҺӘРВАКЫТ БАР»

– Сезнең агентлык дөньяның 49 телендәге документлар белән эшли. Тәрҗемә тармагындагы бизнесыгыз нигезендә нәрсә ята?

– Ике кыйммәт ята – минем тәрҗемә процессы белән кызыксынуым һәм мәдәниятнең иң мөһим

РАДЖАНА СОЛТАНОВА

«Тәрҗемәләр дөньясы» агентлыгы» ҖЧҖнең оештыручысы һәм директоры

Туган шәһәре: Казан

Белеме:
- В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты, стратегик менеджмент (2005)
- «ТИСБИ» идарә университеты, гражданлык хокукы (2009)

Карьерасы:
- 2004 елдан – шәхси эшмәкәр
- 2009 елдан – «Тәрҗемәләр дөньясы» агентлыгы» ҖЧҖ директоры һәм хуҗасы

Телләре:
- Рус, азәрбайҗан – ана телләре
- Төрек – сөйләм дәрәҗәсендә
- Инглиз, татар

Хобби һәм мавыгулары:
- Кулинария һәм сервировка
- Бию
- Сәяхәт итү
- Гүзәллек конкурслары

Шәхси кредосы:

«Башкаларны да үз энергетикаң белән җәлеп итеп, гел үсәргә»

Казанышлары:
- «Татарстанның бизнес гүзәле-2024» конкурсында Гран-При
- Бөтенроссия «Россиянең бизнес гүзәле-2024» конкурсында Гран-При
- Халыкара Mrs. Universe гүзәллек конкурсында беренче унлыкка керү
- Элегантлык һәм стиль өчен «Perfect Style» халыкара титулы

өлешләреннән берсе булган телгә тирән ихтирамым. Бу да гаиләдән килә. Гомумән, «Тәрҗемәләр дөньясы» агентлыгының бөтен эшчәнлеге дә үзара хөрмәткә нигезләнеп төзелгән. Шунлыктан без бөтен заказчылар – физик һәм юридик затлар белән дә, шулай ук дәүләт структуралары белән дә эшлибез.

– Бигрәк тә нинди заказлар еш очрый? Яңа тенденцияләр күзәтеләме?

– Юридик затлар (нигездә – дәүләт структуралары) аеруча мөһим рәсми документларны, норматив-хокукый документацияне тәрҗемә иттерә. Нигездә – инглиз теленә, соңгы вакытта исә төрек, фарсы, кытай һәм гарәп телләренә тәрҗемәгә дә ихтыяҗ артуы күзәтелә. Физик затлар ихтыяҗының 70 проценты – чит телләрдән шәхси документларны тәрҗемә иттерү, 50 проценты – БДБ илләре телләреннән тәрҗемәләр, 30 проценты – төрле характердагы текстларны Европа телләренә тәрҗемә итү. Шулай ук кече һәм урта бизнес өчен дә тәрҗемә итәбез. Биредә яңа тенденцияләрдән IT, финанслар һәм криптовалюта тармагындагы текстларны тәрҗемәләүне атарга була.

– Сезгә зур компанияләр мөрәҗәгать итәме?

– Булгалый, әмма республикадагы мөһим вакыйгалар вакытында федераль тәрҗемә компанияләре хезмәт күрсәтә шул.

– Җирле подрядчылар белән эшләүнең өстенлекләре бармы?

– Җирле подрядчылар белән хезмәттәшлектә өстенлекләр һәрвакыт бар. Бәяләр арзанрак, аралашу җиңелрәк, эш сыйфатын контрольдә тоту мөмкинлекләре күбрәк. Моннан тыш, бу төбәк икътисадына файда китерү мөмкинлеге дә әле.

«ФАМИЛИЯМНЕ ДӨНЬЯГА ТАНЫТУЫМ – ТРАДИЦИЯЛӘРНЕ САКЛАУГА, ТОРМЫШНЫ ЯХШЫРТУГА КЕРТКӘН ӨЛЕШЕМ»

– 2024 елның язында сез беренче тапкыр «Татарстанның бизнес гүзәле-2024» төбәк конкурсында катнаштыгыз, ә октябрьдә инде «Галәм гүзәле»нең беренче дистәсенә кереп, баллар буенча 7 нче урын, шулай ук Perfect Style номинациясендә җиңү яуладыгыз. Әлеге искиткеч казаныш сезгә куәтле шәхси брендыгыздан тыш тагын нәрсә бирде?

– Мин һәрвакыт көч һәм зирәклекне, бигрәк тә бизнеста, яраштыра белдем. Максатка ирешү һәм яңарак, тагын да кыюрак бурычларны алга кую ошый миңа. Тик менә үземне башта төбәк, аннары федераль дәрәҗәдә, аннан соң дөнья күләмендә сәхнәдә күрсәтү бурычы бик катлаулы булып чыкты. Эчке курку, шөбһәләр, чикләүләр, фаҗигале хатирәләрнең күп булуы ачыкланды. Боларның барысыннан да тиз арада котылырга кирәк иде. Аларны җиңеп чыгу сөенече миңа яуланган җиңүемнән дә кадерлерәк булды.

– «Галәм гүзәле» Раджана Солтанованың төп нәтиҗәсе нинди?

– Хатын-кыз үзенең сөйкемлелеген югалтмыйча, бернинди низаг-

ларсыз гына да бизнесын җитәкли ала. Гаиләмдә дә, эшемдә дә хуплау табам. Үз фамилиямне данлый алуым белән горурланам. Бу – традицияләрне саклауга, тормышны яхшыртуга керткән өлешем.

– Бәйгедән соң тормышыгыз үзгәрдеме?

– Үсеш өчен күп идеяләр пәйда булды. «Тәрҗемәләр дөньясы» агентлыгын тагын да үстерү, инде быел ук филиаллар ачу планы бар. Моннан тыш, конкурстан соң мөмкин кадәр күбрәк хатын-кызның үзен чибәр итеп сизүен телим. Хатын-кыз мөлаемлеге бик кирәк, ул җәмгыятьтәге балансқа ярдәм итә. Әмма син бер үк вакытта әни дә, хуҗабикә дә, һөнәр иясе дә булганда, үзеңне кайгыртуга көч калмый. Җәмгыять исә синнән яңадан-яңа батырлыклар таләп итә. Киләчәктә матурлык һәм эстетика мәктәбе ачып, хатын-кызларга үзләренә булган ышанычны кире кайтарырга булышу турында да хыялланам.

– Без традицияләргә хөрмәт хакында күп сөйләштек. Ә сезнең өчен үзеңә хөрмәт нәрсә ул?

– Бала чагымда әтием мине принцесса, шаһинә дип йөртә иде. Минем исемем шулай тәрҗемә ителә дә. Минем өчен бу – үземне, хисләремне хөрмәт итү. Үземне кайгырту да – тормышымның мөһим өлеше. Мәсәлән, мин матур савыт-саба яратам. Дөрес сыйлану – тәмле ризык һәм матур итеп корылган табын ул. Бу һәркемнең хәленнән килерлек нәрсә. Әйбер кыйммәт тә булмаска мөмкин, тик ул сиңа эстетик канәгатьләнү хисе китерсен. Бөтен матур нәрсә – минем өчен, шундый фикер белән яшим. Бу мине сөенеч һәм энергия белән туендыра һәм үз көчемә ышаныч тудыра.

– Сезнең иң яратып әзерли торган ризыгыгыз бармы? Пешерергә яратасызмы?

– Чын Кавказ хатын-кызы буларак, мин өйдәге бөтен эшне дә эшли беләм. Кызларым теләсә, өчесенә өч төрле иртәнге аш әзерләп бирә алам. Гаилә бәйрәмнәренә хан-пылау әзерлим. Бу бик озак процесс, әмма бик тәмле була. Шул ук вакытта, көчем яки вакытым булмаса, өйгә ризык китертүне дә гаепкә санамыйм.

«МИҢА РӘХМӘТ ХИСЕ БУЛЫША»

– Авыр чакта нәрсәгә таянасыз?

– Шулкадәр авыр хезмәт белән табылган казанышларымны югалтудан курку хисенәдер, мөгаен. Кимрәк нәрсәгә ризалашмау теләге көчле миндә. Хыял һәм максатларым көч бирә. Кызларыма иң яхшы тормыш бүләк итәргә телим, моның өчен үземне җаваплы тоям. Яраткан һәм якын кешеләремне сөендерә алсам, үзем дә бәхетле булам.

– Сезнең гаилә традицияләрегез бармы?

– Кайчандыр сеңелләрем белән әтине эштән каршылаган кебек, кызларым да мине каршы ала. Алар белән гел күп вакыт үткәрә алмыйм, шунлыктан бергә чакларыбызны бик рәхәт итеп уздырырга тырышам. Һәрчак тыныч йокы телим, көннәренең ничек үтүе хакында сораштырам. Кием-салым, бергәләп ял итү урынын сайлаганда мөстәкыйльлеккә өйрәтергә тырышам. Еш кына алардан киңәш сорыйм. Һәм һәрвакыт үзләренә сокланам. Алар – минем иң матур, иң акыллы һәм иң сәләтле балаларым. Мин аларны беркайчан да ирексезләмәячәкмен. Аларның үзләрен яратуларын, комплекслары булмавын телим.

– Тәрбиядә иң мөһиме нәрсә дип саныйсыз?

– Мин традицион кыйммәтләр хөкем сөргән гаиләдән, мондый яшәү рәвешен бүген дә саклау иң мөһиме, дип уйлыйм. Бу – бәхетле киләчәкнең нигезе. Тиздән олы кызыма инде 18 тула, бу яшьтә дөньядагы бөтен нәрсәне сынап карыйсы килә. Мин аны үз кадерен белергә өйрәтәм, киләчәге өчен мөһим максатларын онытмасын иде, дип тырышам.

– Өйләнә-тирәдә даими үзгәреш булганда, эчке тотрыклылыкны ничек сакларга соң?

– Мин Ходай Тәгаләгә, ата-бабаларыма, әти-әниемә, тормыш тәҗрибәмә рәхмәтлемен. Бу эчке ориентирны формалаштыра, чыннан да мөһим нәрсәләрне аера белергә өйрәтә. Теләсә нинди вазгыятьтә дә мин шуны онытмаска тырышам: болар барысы да кызларымның бәхетле киләчәге өчен кирәк, һәм алар да әлеге кыйммәтләрнең кадерен белергә өйрәнергә тиеш. Үзгәрешләр һәрвакыт булачак, әмма үзең беркайчан да хыянәт итмәячәк асыл кыйммәтләргә таянып яшисең икән, алга таба ныклы ышаныч белән бара аласың.

«Тәрҗемәләр дөньясында» агентлыгы» ҖЧҖ

Девизы: «Сүзләр генә түгел!»

Төзелү елы: 2009

Күрсәтә торган хезмәтләре:

- Шәхси һәм корпоратив документларны язмача тәрҗемә итү;
- Теләсә нинди телдәге нотариаль документларны дөньяның теләсә кайсы теленә тәрҗемә итү;
- Бизнес һәм дәүләт структуралары өчен юридик, техник, IT, финанс тәрҗемәләре;
- Заказчы тәрҗемәләрен тикшерү һәм редакцияләү;
- Хокук саклау органнары: тикшерү, судлар, халыкара йомышлар өчен тәрҗемәләр;
- Телдән эзлекле һәм синхрон тәрҗемәләр;
- Дәүләт органнары өчен тәрҗемәләр: боерыклар, хатлар, презентацияләр, тендер документацияләре һ.б.

Партнёрлары:

Татарстан Республикасы министрлык һәм идарәләре, хокук саклау органнары һәм суд хакимияте органнары, абонент килешүләре буенча бизнес-клиентлар

Үзенчәлекләре:

- Төрле юнәлештәге тәрҗемәләр хезмәте даирәсендә 16 ел эшләү;
- «Россия тәрҗемәчеләр берлеге» гомумроссия иҗтимагый оешмасы әгъзасы;
- Россиянең иң яхшы предприятиеләре лигасы бергәлеге рейтингы нигезендә «Елның иң яхшы предприятиесе 2023–2024» бүләк-статусы иясе;
- Россия тәрҗемә компанияләре ассоциациясе рейтингының ТОП-50 сенә керә;
- Төбәктәге иң яхшы татар теле тәрҗемәчеләре коллективларыннан берсе;
- Эш сыйфатын бәяләүнең үз системасы (KPI)

Өстенлекләре:

- Тизлек (паспортны тәрҗемә итү 30 минуттан башлана)
- Җаваплылык (NDA, нотариат, легальләштерү)
- Шәхси якын килү һәм сыйфатны контрольдә тоту
- Хезмәттәшлек шартлары һәм форматларында зирәклек күрсәтү

Фәлсәфәсе:

«Бөтен нәрсәне тәрҗемә итеп була, әмма һәр сүз артында җаваплылык һәм эшкә хөрмәт торуы мөһим» – Раджана Солтанова.

www.protatarstan.ru
ТАТАРСТАН
Сайттагы яңалык
Финансовая грамотность
Реклама 16+

АЛТЫНЫГЫЗНЫ КЫЙММӘТКӘ САТЫГЫЗ, АКЧАСЫН ШУНДА УК АЛЫГЫЗ!

• КАЗАНДАГЫ ФИЛИАЛЛАРЫ • ЗӘРКӘНЧЕ ӨЕГЕЗГӘ БУШЛАЙ КИЛӘЧӘК •

583/585 нче келәймә – 1 г өчен 4500 сум, 750 нче келәймә – 1 г өчен 6500 сум. Тәңкәләр, көмеш, стоматология коронкалары – кыйммәт хактан.

ШУНДА УК АКЧА АЛЫРГА ЯИСӘ КАРТАГА КҮЧЕРТТЕРЕРГӘ БУЛА!

8 (800) 551-84-34

Зәркәнчене чакыру

«Аурум» алтын һәм зәркән эшләнмәләрен сатып алу компаниясе – бу өлкәдә иң зур федераль компанияләрнең берсе. Ул зәркән эшләнмәләрен дәүләт үрнәге буенча кабул итә. Алтын валютасы биржасына йөз тота, заманча төгәл итеп бәяли.

«Аурум» компаниясе рәсми рәвештә эшли, Федераль пробир палатасының лицензиясенә ия.

1. «Аурум» компаниясенә мөрәҗәгать итүнең өстенлекләрен һәм уңайлыкларын карап узыйк.

«Аурум» федераль челтәре биржада теркәлгән бәягә йөз тота, дәүләт үрнәгендә эшли, штатында һөнәри яктан әзерлекле зәркәнчеләр тупланган. «Аурум» компаниясе сезнең алтынга, зәркән эшләнмәләренә һәм кыйммәтле металлга, алар нинди генә хәлдә булса да, югары бәя тәкъдим итә. Сатып алганда, «Аурум» алтынның авырлыгын гына түгел, ташларның бәясен дә исәпкә ала. Сатып алганда бәясе күп тапкырларга югары була. Сез шунда ук алтын һәм зәркән эшләнмәләрегезгә иң югары хак аласыз, шунда ук акча алырга яисә картагызга күчерттерергә була.

2. «Аурум»га алтын сатуның үзенчәлеге нидә?

Россиядә алтын сатып алу буенча иң зур федераль челтәрләрнең берсе. Үзенең зәркән кибетләре бар. Эшләнмәләрнең бер өлеше шунда сатыла. «Аурум» компаниясенә тапшырылган эшләнмәләргә шактыйга күбрәк акча алачаксыз, чөнки аларның бер өлеше аның үз кибетләрендә сатылачак, алтын ватыгы буларак кулланылмаячак.

3. «Аурум» компаниясе өегезгә килеп сатып алу мөмкинлегенә ия.

Сезнең уңайлык өчен яңа сервис. Безнең югары һөнәри осталыкка ия булган зәркәнче (фотода ул үзе, алай тынычрак, шулай бит?) бушлай сезгә уңайлы вакытта өйгә, эшкә килә ала, кафеда очрашу билгеләргә була. Үзендә кирәкле бөтен кораллары да бар, сезнең алда бәяли, сорауларыгызга җавап бирә.

Өегезгә килеп сатып алу – бу никадәр уңайлы? Укучыбыз Расторгуева Валентина Ивановнадан сорыйбыз:

– Шалтыраттым. Күңелгә ятышлы яшь кенә бер егет килде. Чәй белән сыйладым. Артём өстәлгә үзенең эш коралларын чыгарып тезде. Ничек итеп келәймәсен билгеләвен, кыйммәтле ташларны бәяләве турында сөйләде. Бик мавыктыргыч. Гәпләшеп алдык... Ахыр чиктә, миңа иске, инде кулланылмый торган йөзек һәм алкаларым өчен 73 000 мең сум тәкъдим итте. Ризалаштым, акча шунда ук картага килде. Биредә намус белән эшлиләр!

«Аурум» компаниясе турында тулырак мәгълүмат белән www.aurum-skupka.gold сайтында танышырга була

БУ ИГЪЛАННЫ КҮРСӘТЕГЕЗ ҺӘМ ӨСТӘМӘ 500 СУМ АЛЫГЫЗ!

Казан: «Тукай мәйданы» метро станциясе, Пушкин ур., 5/43 йорт

Лицензия – Л023-00119-77/00389972 2021 елның 22 декабреннән РЕКЛАМА. «АУРУМ» ҖЧҖ. ОГРН: 1207700387245. Юр. адресы: 127051, Мәскәү ш., Петровка ур., 26 йорт, 2 корылма, 1 подвал, 29 бүлмә.

АЛЬБЕРТ НИГАМАЕВ: «АЛАБУГА ШӘҺӘРЛЕГЕН БЕЗ КҮТӘРДЕК»

Гомәр Даутов

Алабуга кечкенә генә провинциаль шәһәр булса да, аның меңьеллык тарихы бар. Шәһәрдән ерак түгел генә урнашкан «Алабуга» МИЗ бөтен дөньяга билгеле. КФУның Алабуга институтын элек «Кама аръягы академиясе» дип йөрткәннәр. Гаҗәп кешеләр эшләгән монда: татар хатын-кызлары арасында беренче филология фәннәре кандидаты Маһинур Фәйзуллина, Татарстанның халык язучысы Тәлгат Галиуллин, күп төрки телләрдә иркен сөйләшкән Кәрим Җаманаклы һ.б.

Алабуга институты бүген дә һәм халыкны, һәм фәнни җәмәгатьчелекне гаҗәпләндереп яши. Мәсәлән, «Артефакт» исемле студентлар археология түгәрәге 2012 елдан бирле бөтен Россия күләмендә үткәрелгән конкурс һәм конференцияләрдә һәрвакыт беренче урынны алып килә. Ә бит бу фәнни җыелыш-киңәшмәләрнең исемнәре генә дә үзләренең колачын һәм дәрәҗәсен раслый: Урал-Идел буе студентлар археология конференциясе, Башкорт студентлар археология конференциясе... Әлеге түгәрәкнең җитәкчесе Альберт Зөфәр улы Нигамаевның исеме дә шәһәрдәшләребезгә яхшы таныш. Тирән белемле, үз эшенә бирелгән кеше, диләр аның турында. Студентларга карата да таләпчән. Ул укыткан фәннән зачет яисә имтихан биреп чыккан кеше ул көнне үзенең икенче туган көне саный. Ләкин бер студентны да «батырып», төшереп калдырмый.

Эш мәсьәләсендә үзенә карата да, башкаларга да чын мәгънәсендә аяусыз. Шуны белгәнгә, бервакыт телефоннан сөйләшкәндә аңа: «Әгәр синең кул астында булса, мин эшләмим», – дигән идем, Альберт Зөфәрович бик озак тиргәнде. Аның бөтен сыйфатларыннан иң көчлесе – милли җанлы булуы. Ул бу турыда кычкырып йөрми, ә эше белән исбатлый: тарихны өйрәнә, өзлексез археологик эзләнүләр үткәрә, яңа дәлилләр табып, мәгълүм бер шагыйрьнең «Без ким түгел җирдә һичкемнән» дигән сүзләрен фәнни яктан исбатлый...

Әңгәмәбезне башлаганда, беренче соравым да шуңа кагылышлы булды.

«ХАЛКЫҢНЫ ЯРАТУ – ТАБИГЫЙ КҮРЕНЕШ»

– Сезнең өчен милләт, халык нәрсә ул?

– Мин авыл укытучылары гаиләсендә туып үстем, шуңа күрә кечкенәдән үк беренче урынга җәмгыять, халык мәнфәгатьләрен куярга өйрәттеләр. Сүз уңаеннан әйтеп китим әле, әни рус теленнән укытты һәм мәктәпне тәмамлаганда имтиханда ул миңа дүртле куйды. «Бишлелек белмисең, балакаем», – диде, югыйсә, калган бөтен фәннәрдән бишле иде. Менә сез кайчакта мине гаепләгән таләпчәнлекнең тамырлары каян килә ул.

Барлык предметларны да татарча укыдык, мәктәптә үткән барлык чараларда да катнаштык, һәм шул рәвешле бездә туган халкыбызның яшәешенә, теленә мәхәббәт тәрбияләнде. Гаяз Исхакый, Дәрдемәнд иҗатларында урын алган «татарлык» дияр идем мин аны. Шунысын да искәртик: бездә милли җанлы кешеләр күп бит ул, ләкин күбесе аны бөтен дөньяга кычкырып кына йөрми, алар өчен халкыңны ярату – табигый күренеш. Минем фикеремчә, милләт тарихын дөрес өйрәнеп, аны балаларга җиткерү, шуның нигезендә аларны тәрбияләү – безнең бурыч...

– Сез кемнәрне остазларым дип саныйсыз?

– Әнием тәрбиясе хакында әйттем, этигә дә тукталып узыйм инде. Әти Казаннан бөтен татарча вакытлы матбугатны яздырып ала иде. Татарстаннан килгән һәр фәнни экспедиция – фольклор буенча булсынмы ул, тел буенчамы – барысы да безгә туктала. Кичләрен кызыклы да, бәхәсле дә әңгәмәләр була иде. Мин шуларны

Фотолар авторның шәхси архивыннан алынды

тыңлап һәм, вакыты җиткәч, үзем дә катнашып үскәнлектән, татар тарихы белән кызыксыну көчле иде. Инде Пермь дәүләт университетында укый башлагач, ул кызыксыну миндә гыйльми тикшеренү рәвешен алды.

Археологиягә җитәкләп алып кергән укытучым, бөтен СССРга даны таралган профессор Владимир Антонович Оборин, моны сизгәч, курс эшләрен, фәнни тикшеренү темаларын Болгар һәм Казан ханлыгының мәдәни, матди һәм башка төрле элементләре буенча бирә башлады. Шуңа күрә еш кына Казанга барырга туры килә иде. Шул вакытта Фаяз Шәрипович Хуҗин белән таныштык. Ул элемтәләр, шөкер, бүгенгәчә дәвам итә. Ул миңа букча-букча китап бирә, Казан археологларының яңа ачышлары белән таныштыра. Өченче курста миңа хәтта Казан университетына күчәргә дә тәкъдим булды.

Фаяз Хуҗин мине Альфред Халиков белән дә таныштырды. Альфред Хәсәнович янына кереп чыккач, бу галимгә ошамадым бугай дигән фикер дә туды әле. Күпмедер вакыттан соң, остазым Фаяз ага: «Сине Халиков бик якын кабул иткән, Пермьдә диплом алгач, кайда укыячагыңны, кайда эшләячәгеңне сөйләшеп, билгеләп куйды инде. Ул мондый мөнәсәбәтне бик сирәкләргә күрсәтә», – диде. Менә шул олуг галим сызган юл буйлап барып мин Казанда аспирантурада укыдым. Фаяз Хуҗин җитәкчелегендә кандидатлык диссертациясен якладым, фән кандидаты гыйльми дәрәҗәсен алдым. Бүгенге көнгә кадәр Алабуга институтында эшләвемне дәвам итәм.

– Сөйләвегезгә караганда, сезне фән өлкәсенә хәерхаһлы булып каршы алганнар. Фәндәге юлыгыз да җиңел-җайлы гына бардымы?

– Остазларыма мин һичшиксез рәхмәтле. Әлбәттә, бу юл гомер буена җиңел генә булмады. Инде бишенче курс ахырына таба ук Альфред Хәсәнович мине тулысынча Татарстанда барган археологик казыну эшләренә «җикте». Монда эшлим-эшлим һәм иртәгә дәүләт имтиханнары дигән көнне Пермьгә кайтып китәм, имтиханны тапшырган көнне үк – кире Татарстанга, археологик казынуларга... Бик киеренке булуга карамастан, яшьлек барысын да күтәрә һәм җиңә икән.

«БУ ЯДКӘР ҮЗЕ ГЕНӘ БУЛА АЛМЫЙ...»

– Институтта төрле-төрле түгәрәкләр эшли, ләкин сез җитәкләгән «Артефакт» Россия күләмендә бәйгеләрдә җиңү яулый, эшчәнлеге, кем әйтмешли, кайнап тора. Бу бит инде югарыда телгә алган тәрбия нәтиҗәсе, әмма моңа ирешү җиңел түгелдер?

– Безнең түгәрәк 1994 елны студентларның фәнни җәмгыяте буларак оешты. Шул елны без Биләрдә археологик казынулар үткәрдек. Ул ни студентларның, ни матди базаның зур эшләргә сәләтле түгеллеген күрсәтте: палаткалар, йокы капчыклары гына түгел, хәтта көрәкләребез дә юк иде, авыл буйлап көрәк җыеп йөрдек. Шуннан уйладык: болай булмый, нидер эшләргә кирәк. Пермь университетында укыганда профессор Оборин җитәкләгән түгәрәкнең, Казанда Альфред Халиковның археологик түгәрәге тәҗрибәләрен берләштереп, үзебездә дә шундыйны оештырып җибәрдек. Әйтергә кирәк, 90 нчы еллар ахыры, 2000 нче еллар башында безнең түгәрәккә язылырга теләүчеләрнең саны институтка керү конкурсыннан зуррак иде.

– Нәрсә белән, ничек итеп шулай җәлеп итә алдыгыз?

– Аның заманасы шундый иде. Халыкның милли үзаңы күтәрелгән чак, ә тарихи мәгълүмат бик аз. Хәтерлисезме, «Без кем?», «Тарихта безнең урыныбыз нинди?» дигән сораулар туган чорны? Белемгә омтылыш, ихтыяҗ зур, ә уку әсбаплары, китаплар әле юк...

– Мәгълүмати ачлык...

– Нәкъ шулай. Боларга өстәп, ул заман студентларында фәнни ачышлар романтикасы дигән әйбер дә бар иде. Шунысын да әйтик: институтта театр, баянчылар түгәрәге эшли, әлбәттә, алары да кирәк, ләкин фәнни түгәрәк безнеке генә. Икенчедән, безнең түгәрәкнең гамәли әһәмияте дә зур, чөнки ул Татарстан археологиясе белән бәйләнгән һәм аны үстерүгә хезмәт итә. Без тулаем Татарстан истәлекләре, хронологик яктан да бары IX–XIII гасырлар белән генә эш итәбез.

– Ярый, 90 нчы еллар күтәрелеше аңлашыла, ләкин бүгенге студент – ул инде икенче, чор икенче, әмма түгәрәк темпларын һич киметмичә эшли.

– Студентлар белән утыз ел эшләү тәҗрибәсенә таянып, аларның үсеш-үзгәреш картинасын бик яхшы күзаллыйм. 90 нчы еллар студенты физик эштән курыкмый, гаять зур казу эшлә-

ренә сәләтле иде. Әгәр алар булмаса, без Алабуганың 1000 еллыгын исбатлый, кирмәннең реконструкциясен дә эшли алмаган булыр идек. Әмма әле аларда белгәннәрен халыкка чыгару, чыгышлар ясау осталыгы юк иде. Ул вакытта безне институтта беләләр дә, археологлар даирәсендә, ә киңрәк масштабта – юк диярлек.

Алабугада урта гасырларга бәйле бердәнбер археологик истәлек бар. Ул – тау башында, менә хәзер сез, халык үзе дә белә торган Алабуга шәһәрлеге. Без күтәрдек бит аны. Шунда, эшләрне инде тәмамлап килгәндә, Альфред Хәсәнович: «Кара әле, Альберт, бу ядкәр үзе генә була алмый, юк андый әйбер археологиядә. Кемдер яшәгән икән, аның каберлеге булырга тиеш. Бу ядкәр урнашкан җир уңайсыз, димәк, халык кайдадыр бистә булып урнашып яшәгәндер», – диде. Үзе, урыны оҗмахта булсын, күп тә үтмәде, вафат булды.

Мин аның бу сүзләрен васыяте дип кабул иттем. Һәр яз саен елга буйларында, якын-тирә болыннарда эзләнеп йөри башладым. Эзләнә торгач, шәһәрлеккә терәлеп үк урнашкан каберлекне, 1997 елны Покровск чиркәве янында бистә урынын таптык. Болар – Алтын Урдага кадәр булган ядкәрләр. Археологик казыну эшләрен тагын да тулырак көч белән башлап җибәрдек. Халыкны кызыксындыру өчен,

БЕЗНЕҢ ИҢ ЗУР ДӘЛИЛЕБЕЗ – ҺӘМ УЛ ТАТАРСТАНДА БҮТӘН ЮК – ҖИР ӨСТЕНДӘ САКЛАНГАН ХӘРАБӘЛӘР. ШУҢА КҮРӘ БЕЗГӘ ИСБАТЛАУ БУРЫЧЫ КУЕЛМАДЫ, АЧЫКЛАРГА, ЯГЪНИ КОНКРЕТЛАШТЫРЫРГА ГЫНА КИРӘК ИДЕ. БОЛАРНЫҢ БАРЫСЫ ДА «АРТЕФАКТ» АРХЕОЛОГИЯ ТҮГӘРӘГЕНӘ ЙӨРҮЧЕ СТУДЕНТЛАР ЯРДӘМЕ БЕЛӘН БАШКАРЫЛДЫ.

шул елны «Борынгы Алабуга» дип аталган конференция оештырдык, газета-журналларда, телевидениедә чыгышлар ясый башладык. Сүз әле Алабуганың 800 еллыгы хакында бара иде. Ләкин конференциягә килгән галимнәр безнең күргәзмәгә куелган ядкәрләр белән танышкач, сүзнең тагын да борынгырак чорлар турында баруын әйтә башладылар. Бу этәргеч булды, һәм 2003 елга шәһәребезнең 1000 еллыгы турында кире каккысыз, фәнни яктан исбатланган материаллар туплый алдык.

– Шулай да, заман студентлары археология эшенә атлыгып торамы? Энтузиастлар бармы?

– Хәзерге студент һәр эшне кирәкме-юкмы, аңа ул файдалымы-юкмы бизмәненә салып карый. Кирәк түгел дип таба икән, ул аннан ничек тә читкә китү ягын карый. Ләкин ул эшен күрсәтә белә, язып бастыруга басым ясый. Безнең түгәрәкнең мәкаләләр саны бөтен институт студентларының публикацияләре суммасыннан күбрәк.

– Шулай да аңлашылып бетми, рациональ уйлый торган контингент белән түгәрәк эшчәнлеген барыбер дә югары кимәлдә ничек саклап калырга мөмкин?

– Дөресен генә әйткәндә, ул хәзер автомат рәвештә бара. Беренче курслар өлкәнрәк студентларның казанышларын күрәләр. Күп кенә электрон басмалар түгәрәк эшендә аеруча нәтиҗәле катнашкан студентлардан интервью ала башладылар...

– Ягъни популярлык, танылу...

– Әйе, күбесе: «Монда укырга килгәндә үк үзебезнең археология түгәрәгенә йөриячәгебезне белеп килдек», – диләр. Быел Россия күләмендә беренче тапкыр студентларның фәнни түгәрәкләре арасында конкурс үткәрелде, һәм без анда I урын яуладык. II урын алган түгәрәк 50% ка ким тавыш җыйган булып чыкты.

Без озак сөйләштек. Мөхәммәт ага Мәһдиев «Яңа гына баласы туган яшь ана белән сөйләшү авыр», – дип яза. Чөнки ул гел сабыен гына сөйли һәм сәгатьләр буе туктамый. Альберт Зөфәр улының археология түгәрәге хакындагы әңгәмәсе дә шул әнине хәтерләтә һәм бу табигый да. Чөнки күпме көч салган, күпме авырлыкларны җиңгән ул шушы биеклекләргә ирешер өчен.

Әлбәттә, Болгар, Алтын Урда тирәсендә купкан бәхәсләр турында да сөйләштек. Катлаулы тарихи процессларга үз мөнәсәбәте, үз фикере бар Альберт Зөфәровичның. Тәрәзәдән күренеп торган урман-кырларга карадым. Анда хәзер зур төзелеш бара, җитмешәр тонналы Кытай машиналары ком-таш ташый. Ләкин археология музееның бер читендә урнашкан Альберт Нигамаевның тар гына кабинетында тарих һәм хәтер яши, фикер кайный, җәйге казулардан алып кайткан ядкәрләр дә үз вакытын көтеп ята. Билгеле инде, хакыйкать тә.

Мәңгелек кыйммәтләр /

акыллы гамәлләр

игелекле эшләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Гагаринның билгесез фотосын **кем** ясаган

Батыр егетләр «тел»не **ничек** кулга төшергән

Сугыш чоры балалары авырлыкларны **ничек** җиңгән

Олы Мишә авылы бүген **ничек** яши

Казанда агач архитектура һәйкәлләре **ни** хәлдә

ТИМУР ХӘЗРӘТТӘН – ГАГАРИННЫҢ БИЛГЕСЕЗ СУРӘТЕ

Дмитрий Сивков

Югары Ослан районы Кызыл Байрак авылы мәчете мәхәлләсе җитәкчесенә беренчеләр рәтендә булу гайре табигый хәл түгел: ул – Татарстанның кадрдагы офицерлар составында булган бердәнбер рухани. Болардан тыш, тагын әле чалма урау буенча да, мәдрәсә каршында илдә бердәнбер умартачылыкка өйрәтү «кафедрасы» ачу буенча да беренче ул. Җирнең тәүге космонавтының моңарчы беркайда да басылып чыкмаган сурәтләрен саклау буенча да.

Фото: Александр Ефремов, tatarstan.top, islam.ru, gctc.ru



ФРОНТОВИК АБЫЙСЫ ИЛҺАМЛАНДЫРА

1954 ел. Үзбәкстанның Наманган шәһәре янындагы мамык басуы өстендә Ан-2 очып йөри. Биплан, мамык басуын аста калдырып, бер болытларга кадәр күтәрелә, бер, аска томырылып, җиргә тиям-тиям дип оча. «Ак алтын» чәчүлекләрен серкәләндереп йөргән «кукурузник»ны абыйлы-энеле икәү күзәтә. Алты яшьлек Тимур Ибраһимов, башын өскә чөеп, эфсенләгәндәй, Янка Купаланың шигырен кабатлый:

Возьми меня, лётчик отважный,
В полёт по Советской стране:
Я смелый, и мне не однажды
Летать приходилось во сне…

Шигырьне беренче класстагы Марат абыйсы ятлаган иде. Гаиләдә барлыгы – 13 бала, беренче дүртьюллык шуңа истә калган да.

28 яшьлек Спартак (пулемёт взводы командиры, Кызыл Йолдыз ордены кавалеры һәм II дәрәҗә Бөек Ватан сугышы ордены иясе!) исә фашист «мессершмитт»ларының алар урнашкан позицияләрне «кырып узуын» исенә төшерә. Ул хәтерендә калганнарны кечкенә энекәшләренә дә сөйли.

– Әнә шул чакта хәрби очучы булу хыялы яралды да инде миндә, – дип елмая Тимур хәзрәт.

Балачак хыяллары сирәк чынга аша. Әмма мамык басуы читендә яралган хыял Тимурда, ни гаҗәп, елдан-ел ныгый гына бара. Бу хыялга әтисе дә канат куя. Гагаринның галәмгә беренче очышыннан соң, ул улына болай ди: «Гагарин – менә кемнән үрнәк алырга кирәк, улым!» Бу егетне яхшы итеп укырга гына түгел, ә спорт белән шөгыльләнергә дә этәрә. Мәктәпне тәмамлагач, ул генерал Полбин исемендәге Кызыл Байраклы Оренбург югары хәрби авиация училищесына укырга керә. Тугыз ел элек бу уку йортын Гагарин тәмамлаган була.

Әмма әле ул чакта курсант Ибраһимов үзенең кумирын чын тормышта күрәсен, аны хәтта фотографиягә дә төшерәсен башына да китерми.

«ЮРИЙ АЛЕКСЕЕВИЧ, ХӘЗЕР КОШ ОЧЫП ЧЫГАЧАК!»

Беренче курс ахыры. Училищеда бары тик беренче курслар гына кала, өлкәннәр – хәрби частьларда практикада. Бөтенесе дә уйлары белән инде – өйдә, каникул ялында. Әмма ике атнаны казармада уздырырга мәҗбүрләр: җибәрмиләр дә, ник җибәрмәгәнне аңлатмыйлар да. Ниһаять, ачыклана: «Иртәгә Гагарин килә!» Бөтен ризасызлык кул белән сөрткәндәй юкка чыга. Шулай булмыйча, миллионлаган совет малайларының кумирын үз күзләрең белән күрү бәхетенә иреш тә! Бу бит – төшкә дә кермәгән бәхет! Тимур Яхъя улыннан 1967 елның 28 июне вакыйгаларын җентекләбрәк сорашам.

– Туган училищесында Юрий Алексеевич вакыты-вакыты белән булып китә торган иде, – дип искә ала Тимур хәзрәт. – Аның хатыны Валентина Ивановна – чыгыш буенча Оренбургтан, алар училищеда бию кичәсендә танышканнар. Шуңа күрә Оренбургка кайткач, Гагарин альма-матерга керми калмый, моның өчен һәрчак җай таба. Безнең белән очрашудан соң да ул, шунда ук машинага утырып, икенче очрашуга китеп барды.

– Нәрсә сөйләде курсантларга Гагарин? Сез аңа нинди сораулар бирдегез?

– Нигездә, сүз самолётларның тактик-техник яклары хакында барды. Һәм, әлбәттә, галәмгә очуы турында да. Ике сәгать эчендә ул шактый нәрсә сөйләргә өлгерде. Хәзер барысы да истә калмаган. Күбрәк сурәтләр булып хәтердә саклана. Аннары, мин тыңлавын да колак читем белән генә тыңлаганмын, ахрысы…

1
Юрий Гагарин тирәсендә – хис-тойгылары ташып чыккан курсантлар, һәм ул, әйтерсең, үзе дә бер мизгелгә генә булса да укыган елларына, яшьлегенә әйләнеп кайткан.

2
Кадерле фотосурәт.

3
Майор Тимур Ибраһимовның Әфганстан күкләрен гизгән чагы.

4

Курсант Юрий Гагарин белән медучилище студенткасы Валентина Горячева Оренбург очучылар училищесында бию кичәсендә танышалар.

5

Зенит-С – бер объективлы һәм көзгеле беренче совет фотоаппараты, нәкъ менә аңа Гагаринлы кадерле кадрны төшереп алу насыйп була да инде. Аппарат 1955 елдан 1961 елга кадәр чыгарыла, барлыгы 232 949 данә фотоаппарат сатылган.

6

Диңгез авиациясе өлкән лейтенанты Габдулла Ибраһимов. Владивосток, 2024 ел.

7

Имамнарның традицион баш киеме – чалманы урау өчен 11 метр марля кирәк.

8

Ана кортларны үрчетү өчен әлеге раманы Тимур хәзрәт Донбасста ташландык умарталыкта тапкан.

– Ничек инде ул, «колак чите» белән генә?

– Чөнки курста бердәнбер фотограф идем, миңа очрашуны фотога төшерергә кушылды. Әнә шул төшерүгә тулаем бирелгәннәнме... Җитмәсә, залда яктылык бик начар иде, «озак выдержка»га куярга туры килде. Аппарат селкенмәсен, чайкалмасын өчен, сулыш алырга да куркасың. Шулай да сурәтләр әллә ни яхшы чыкмаган, «выдержка»ны тагын да озаккарак куярга кирәк булган... Ә менә урамдагы кадрлар әйбәт кенә чыккан, аларның берсе Гагарин турындагы китапка да әлэкте хәтта.

Тагын шунысы исемдә калган: үземә игътибарын җәлеп итәргә теләп, Гагаринга болай дип кычкырдым: «Юрий Алексеевич, хәзер кош очып чыгачак!» Һәм «Зенит-С» фотоаппаратының төймәсенә берничә тапкыр бастым. Училище фотолабораториясендә аннары фотоларны һәркемгә истәлеккә бастырдылар. Ә миңа нәрсә белән мактанырга? Курсантлар Юрий Алексеевич белән төшкән фотода мин бөтенләй юк.

Шуны да әйтергә кирәк: фотоплёнка шуннан бирле, илле сигез ел дәвамында, кагылгысыз яткан да яткан. Һәм менә үз сәгате килеп җитте: Тимур хәзрәт аны «Татарстан» журналына скан ясар һәм бастырып алыр өчен бирде.

ПОЛЯР АРЪЯГЫНДА ЧИКТӘ – ГАГАРИН ЭЗЛӘРЕННӘН...

77 яшьлек яр-егетнең тормышында әһәмиятле даталар шактый була, кайберләрен ул инде тик-

торганнан гына исенә дә төшерми. Тимур хәзрәт аз сүзле, бигрәк тә – хис-тойгылар белән бүлешүгә килгәндә. Шуңа да Үзбәкстанда туып-үскән малай өчен Гагарин белән очрашуның нинди эмоцияләр уятканлыгын аңлау читенрәк булды.

Әмма беренче космонавт белән күзгә күренмәс бәйләнеш моның белән генә өзелми. Чыгарылыштан соң, лейтенант Ибраһимов аның эзләре буйлап китә – Поляр арьягына, чиккә. Лейтенант Гагарин Луостари бистәсендә, Хәрби-һава көчләренең Төньяк флотындагы истребительләр авиация полкында хезмәт иткән һәм МиГ-15бис самолётында очкан булса, лейтенант Ибраһимов 180 километрга көнбатыштарак хезмәт итә – су көймәләренә каршы авиациядә, Сафоново бистәсендә.

– Эшкә юллама биргәндә, мин үземне Төньяк флотка җибәрүләрен үтендем, Гагарин хезмәт иткән тарафларга, – дип сөйли отставкадагы авиация подполковнигы Тимур Ибраһимов. – Дөрес, Гагарин истребитель була, мин исә Бе-12 су асты көймәләренә каршы самолёт-амфибия белән идарә иттем. Безнең экипаж алдына куелган бурыч – НАТО су асты көймәләрен эзләп табу һәм аларны күзәтү иде.

1977 елда очучы өенә якынрак җирләргә күчә – Урта Азия хәрби округына. Ан-26 хәрби-транспорт штурвалына утыра. Озак та үтми, Әфганстанда сугышчан бурыч үтәргә туры килә аңа. Сүз уңаеннан, аларның часте СССР территориясендә урнашкан булганга, экипаж хезмәт хакына хәрби өстәмәләр дә, ташламалар да алмый. Бары тик гаскәрне Әфганстан территорриясеннән чыгаргач кына, аларны шулай да «әфганчылар» рәтендә исәпләп йөртә башлыйлар. Горбачёв имзасы белән грамоталар һәм медальләр дә тапшыралар.

***

Әйтергә кирәк, Тимур хәзрәтнең кечкенә улы Габдулла әтисенең эшен дәвам итә. Өч ел элек ул Краснодарда очучылар әзерли торган авиация училищесын тәмамлый. Хәзерге вакытта – өлкән сержант, Тын океан флотында диңгез авиациясендә хезмәт итә, Ил-38 су асты көймәләренә каршы самолётларда оча. Нәкъ әтисе кебек, ул да хәзер дошман көймәләрен сагалый һәм аулый.

ЧАЛМА УРАУ ҺӘМ УМАРТА ОСТАСЫ

Отставкага чыканнан соң, Тимур Яхъя улы тамырларына әйләнеп кайта – тарихи ватанына. Әле Ташкентта чагында ук ул Имам Бохари исемендәге ислам университетына укырга керә, ә 47 яшендә Татарстанга күченеп килгәч, Исламны кабул итүнең 1000 еллыгы исемендәге Казан Югары мөселман мәдрәсәсен тәмамлый. Шуннан соң инде – Россия ислам университетын. Авыл имамы булырга тәкъдим булгач, ике дә уйлап тормый. Җитмәсә, бу аңа бала чагында өйрәнергә туры килмәгән туган телен яхшылап үзләштерү өчен дә менә дигән мөмкинлек, дип исәпли.

2005 елда, «Кол Шәриф» мәчете ачылышында, барлык имамнарга да чапан белән чалмадан булырга кушыла. Чапаннарны тегеп кияләр, ә менә чалма белән кыенлык килеп чыга – урап бирүче осталар юк. Шулчакта мәдрәсәдә чалма урау осталыгы буенча дәресләр бирүче имамны искә төшерәләр.

– ТР мөфтие Госман хәзрәт Исхаков миңа болай диде: «Аерым бина бирәбез, шартлар тудырабыз – эшне генә башкарып чык! Хатыныңа аңлат – кичектереп булмый торган эш бу, диген!» Хәер, аңа нәрсә аңлатып торырга – ул офицер хатыны, андый нәрсәгә күнеккән. Булышыр өчен, мәдрәсә студентларын бирделәр, бер ай дигәндә, 500 данә чалма урап чыктык. Мин шулай берсендә көнгә 33 чалма урап ясадым. Бу рекордны кем дә булса миннән арттырып үтәп карасын, – дип, горурлык белән елмая мулла.

Әфганстанның бөтенләй көтелмәгән кайтавазы ул Татарстанга күчеп килгәч үзен сиздерә. Ан-26 хәрби-транспорт экипажы нигездә элемтә белән тәэмин итү вазыйфасында була. Таулы илдә радиосигналлар ярдәмендә эшләү шактый катлаулы бурыч, шуңа да аларның самолётлары бортында команда пунктының вертолёт белән элемтәгә чыга торган аппаратурасы урнашкан була.

– Көннәр буена һавада чаклар булды, – ди ветеран Тимур хәзрәт. – Еллык очу нормативы – 120 сәгать, без аны ярты айда куып тота идек кайчак. Техник тәэмин ителеш, ягулык салу өчен бу илдә шартлар юк. Шуңа да очышлар Үзбәкстан ССРның Кокайды аэродромыннан була иде. Техник яктан самолётларны төннәрен карыйлар, прожектор яктысы астында, ә таңнан – кабат һавага.

Бу аның сәламәтлегендә чагылмый калмый. Тимур Ибраһимов сул кулының оеп, тою сәләтен югалта башлавына игътибар итә. Бу хәлдә очсаң, самолёт белән бергә экипажны да харап итүең бар. Медиклар очучыга ышанмый, очудан баш тартыр өчен кылана, дип шикләнәләр. Капитан Әфганстанга авианаводчик булып та китәргә әзермен, ди. Әмма аңа кул гына селтиләр. Менә шул чакта ул, интуициясенә ышанып, кулын бал кортларыннан чактырып дәвалап карарга була. Ни гаҗәп, булыша. Кулы рәтләнеп китә, ә менә үзенә умарта «вирусы» йогып кала.

Татарстанга килгәч, ул Югары Осландагы тәҗрибәле умарта остасы белән таныша, аңардан берничә ел умарта асрау серләренә төшенә. Соңрак мәдрәсә ректоры Ильяс хәзрәт Җиһаншинга уку программасына «Умартачылык» дисциплинасы кертү тәкъдиме белән мөрәҗәгать итә. Ректор аның тәкъдимен хуплый. Нәтиҗәдә, мәдрәсә Тәмтедәге 86 нчы һөнәр училищесының эшен дәвам итә – кайчандыр Татарстан умартачыларын шунда әзерләгәннәр. Чирек гасыр эчендә йөзләгән рухани, дини белемнән тыш, өстәмә 3–4 нче дәрәҗә умартачы дипломы да алып чыккан.

– Муллага үз умартачылыгы булса, һәрчак уңайга гына: өстәлендә бал өзелми, азмы-күпме керем чыганагы да, – ди Тимур хәзрәт.

Шуны да әйтергә кирәк: мәдрәсәне тәмамлап чыккан дин әһелләре аларга тормыш итәр өчен файдалы күнекмәләр биргән уку йортын онытмыйлар, ел саен бал уңышыннан бер өлешне мәдрәсәгә бүлеп тапшыралар.

Болар барысы да имам һәм умартачы Тимур хәзрәтнең йөрәген җылыта. Әмма шулай да, 1967 елның 28 июнендә төшкән фото уяткан хис-тойгылар – икенче, алар бит – яшьлектән, үсмер чактан. Бу тойгыларны «Татарстан»ны укучылар да кичерер, дип ышанып калабыз.

6

7

8

ХӘТЕРНЕҢ ДӘҺШӘТЛЕ БИТЛӘРЕ

2025 ВАТАННЫ САКЛАУЧЫЛАР ЕЛЫ

80 ЖИҢҮ!

1948 елда Казан Тел һәм әдәбият институтының фольклор секторы галимнәре Хәмит Ярми, Халидә Гатина һәм булачак язучы, ул вакытта Казан университеты студенты Нурихан Фәттахов сугыштан соң беренче тапкыр Татарстанның Актаныш, Калинин (бу район 1959 елдан Актаныш һәм Мөслим районнарына бүлеп бирелә), Мөслим һәм Минзәлә районнарына фольклор экспедициясенә чыга. Сугыш тәмамланып өч ел узган. Әмма тыныч тормыш башлануга карамастан, сугыш турындагы истәлекләр дә, ул калдырган яралар да яңа була әле. Бу экспедицияләр вакытында галимнәр белән аралашучыларның, мәгълүмат бирүчеләрнең дә күбесе – Бөек Ватан сугышында катнашкан кешеләр, фронтовиклар. Алар Бөек Ватан сугышы турында истәлекләре белән дә уртаклашалар, үзләре катнашкан яулар, дошман тылына разведкага барулары, сугышчан дуслары турында да сөйлиләр.

Сезне дә 1948 елгы шушы фольклор экспедициясе вакытында Халидә Гатина белән Нурихан Фәттахов язып алган сугыш истәлекләре белән таныштырырга телибез. Язмаларны Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге тәкъдим итте. Сөйләүчеләрнең сөйләм үзенчәлекләрен саклаган хәлдә, үзгәрешсез диярлек бирәбез. Сугыш ветераннарының җанлы сөйләме истәлекләрдәге вакыйгаларны тулырак күзалларга, шул чорның дәһшәтен тоярга ярдәм итәр, дип өметләнәбез.

Фотолар Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге фондыннан.

МӨХӘММӘТЗЫЯ ВӘЛИЕВ: «БЕЗ НИЧЕК «ТЕЛ» АЛЫП КАЙТТЫК...»

Илсөяр Закирова

Истәлекләре белән уртаклашучыларның беренчесе – Калинин районы Уразмәт авылыннан Мөхәммәтзыя Вәлиев. Ул булачак әдип Нурихан Фәттахка сугыш турында истәлекләрен сөйләгәндә 36 яшендә була. Истәлекләр 1948 елның 22 июнендә язып алына.

Мөхәммәтзыя Вәлиев – разведчик-ефрейтор. Дүрт тапкыр яраланган. Сугышка 1941 елның августында алынган. Ленинград һәм Сталинград фронтларында өч ел разведчик булган. Ул Сталинград фронтында сугышканда разведкага барган бер көнен искә төшерә.

–1943 елның 23 гыйнвары. Сәгать төнге 2-3 тирәсе. Безгә бирелә задача – «язык» алып кайтырга. Без өчәү: мин, ягъни Вәлиев, Мещеряков, Емоглатов, алар – руслар. Аларга мин старший. Пуртанк* дигән рабочий поселок бар. Разветрота командиры Семепота безгә шунда барырга приказ бирә. Чыгып китәбез. Барабыз тау башына, поселокка.

Поселокка килеп керәбез. Җортлар тактадан нык итеп эшләнгән. Нимес тавышлары ишетелми. Бер бәләкәй генә җортка килеп керәбез. 16-17 яшьләрдәге бер кыз бар. Тагын бер карчык, анасыдыр. Без алай-болай охран калдырмадык бит. Ә кыз минем муеннан кочаклап алды. Безнең, ди, кызылармеецлар бит бу, ди кыз әнкәсенә. Сөенә бу кыз, җылый. Карчык әйтә: «Атаң кайда икән?» - ди. Озак та үтми, бер карт кеше килеп керә. Тегеләр өчәү, без дә өчәү шул җортта. Хәзер алты кеше булдык. Мин әйтәм Мещеряковка: «Бу бабайдан сораштыр, нимесләр кайда?» – дим, үзем русча яхшы белмим бит инде. «Кая хәзер, – ди карт әйтә, – сезгә сүләп торырга вакыт юк, – ди. – Каян килдегез, шунда китегез, мин сезне җәлләп әйтәм. Шушы җортта унбер нимес тора. Хәзер кайтып керерләр, тизрәк чыгып китегез», – ди. Шул сүзгә каршы мин әйтәм: «Шуларны эзлибез бит, бабай, алардан качарга килмәдек». «Юк, балакаем, чыгып китегез, барыбер әрәм буласыз бит, – ди. – Әнә кайталар да инде!» – ди.

Мөслим районы кырларында. 1948 ел.

*Спартáновка, Портяновка – Сталинградның төньяк тарафындагы поселок.

Вакыт әз. Уже шатырдап килеп тә керәләр, бер сүз әйтеп булмый. Кул белән генә үзебезнең җегетләргә мич артына керегез, дим. Үлсәм үзем генә үләрмен, бөтенебезгә берьюлы үләргә кирәкмәс. Немесләр ишекне ачып җибәрә. Минем кулда – автомат. Немеснең гәүдәсе ишектән кереп җитмәде, мин автоматтан ата башладым. Тегеләр, коридор тар булу сәбәпле, артка чигә башладылар. Минем атуым ату булды, өчебезнең тегеләрне таптап чыгып китүе булды.

Мещеряковка задание бирдем: «Иптәш Мещеряков, син боларның икесенең дүкәмитен ал!» – дим. Безгә башка нәрсә кирәкми. Без бик ашыктык. Без киткәндә, өйдәгеләр ап-ак булып калдылар. Тизрәк китәргә кирәк бит. Мещеряков документларын алды боларның. Без озакламый үзебезнең штабка кайтып киттек.

Хәзер комротага дүкәмитләрне бирдек, доложить иттек. Комрота безгә: «Задача моның белән генә бетмәде, – диде. – Безгә, – диде, – тере «язык» тотып алып кайтырга кирәк. Бик авыр эш вакыты, ашагыз да, тагын китәрсез», – диде.

Азрак тамакка капкаладык та чыгарга әзерләндек. Монысы трактор заводы буеннан барырга инде. «Иптәш Вәлиев, – диде комрота, – мин бая сезгә «язык» алып кайтырга дигән идем. Сез алып кайта алмасагыз да, зур эш эшләдегез», – ди. Ләкин безгә шундый задача: «язык»ны ничек тә алып кайтырга. Әле без Пуртанкка барган идек, хәзер Борба дигән рабочий поселокка барабыз. Комрота безгә карта буенча күрсәтеп бирә. «Сез барасыз шунда, задача – немецлар торамы-юкмы, аннан соң «язык» алып кайтырга», – ди.

Без чыгып киттек. Төнге сәгать 4-5 тирәләре. Ай яктысы якты ул вакытта. Кышкы төн бит. Безнең фронт туктаган җиргә килеп җиттек бер чокыр буйлап. Пулеметная рота командиры белән сөйләштек тә үзебезнең кая китәсене белгерттек тегеңә карта буенча. «Бу тирәгә атмагыз, – дибез, – әгәр без атына башласак, уң яклап безгә ярдәм итәрсез», – дибез.

Яр буенда – әрәмәлек арасы. Ята-тора барабыз. Япанга килеп чыктык. Бер җорт шәүләсе күренә җыракта, 150-200 метрлар чамасы бар. Хәзер түш белән шуып барабыз шунда. Җортның кырына килеп җиттек. Бер аяк тавышы ишетелә. Бу җортлар икәү икән. Бер-берсенең арасы 30-35 метрлар тирәсе. Шул ике арада бер часовой тора. Часовойны күрдек. Мещеряковка әйтәм, шул часовойны кулга төшерергә кирәк, дим. Мещеряков бара да часовойның йөрәгенә кадый. Кызу канлы бит егет. Аның первый эше әле. Ә безгә «язык» кирәк. Бу эшне бозды. Мин тегенең янына килеп чыгам да: «Эх, эшне боздың. Хәзер нишлибез? Икенчене эзләргә туры килер», – дим. Мещеряков әйтә: «Кире киттек», – ди. Мин: «Юк!» – дим. «Өйгә керәбез», – мин әйтәм.

Барабыз тагын. Өйгә таба бара башлаган идек, бер аяксыз инвалид килеп чыга, безнең кеше, коралсыз. Без тегенең белән сөйләшәбез. Шул җортның хуҗасы икән. «Бу йортта

Сабан туенда да галимнәр халык белән аралаша. Мөслим районы. 1948 ел.

нимесләр бар», – ди ул. «Нәрсә эшләйләр?» – мин сораймын. «Алар барсы да җоклайлар әле, алҗып кайттылар», – ди. «Алар ничәү соң?» «14 ахрысы алар», – ди ул. «Коралллары кайда соң?» – дибез. «Коридорда да, өйдә дә бар», – ди теге.

Без решать итәбез: боларның башта коралларын кулга төшерергә, аннары – үзләрен.

Коридорда – алты винтовка. Өйгә кердек. Өйдән алдык җиде автомат. Әле нимесләрдә күтәрелү юк. Хәзер боларның кеше саны 14 була. Корал 13 кенә, дип күңел белән уйлыймын. Давай эзләргә, дим мин, кайда бер корал? Командирныкы карават башында эленеп тора икән, пистолет кына. Куркыныч калмады. Мещеряковка задача бирдем. «Иптәш Мещеряков, сиңа 15 минут вакыт. Боларны тышка чыгарып бастыр!» Ә үзем икенче өйгә киттем. Ишекне ачтым. Бер-икесе уяу яткан төсле тоела бит. Кешенең санын белмим. Барып керүем булды, автоматтан боларга җибәрдем очередь.

Вакыт әз. Бер-икесе чыгып киткән бит моның. Башкалары шунда, үле калганнар. Емоглатов чыкканын барсын кулга ала тора. Бу өйдә куркыныч калмады.

Чыксам тышка, бер кешене дә чыгармаган. Аякларына, өсләренә киендереп ята Мещеряков, тегендә барып керсәм. Мин бер-икесенә аттым да, шунда ук тегеләр тышка чыгып бастылар. Моннан – унике, теге йорттан икәү чыкты болар.

Хәзер боларны алып кайтып китәргә кирәк бит. Без кызулык белән сизмәгәнбез, таң атып килә. Карасак, трактор заводы – тау башында. Ә анда нимесләр утыра икән. Безне сизгәннәр бит, пулеметтан аталар. 150 метрлар чамасы алар. Үләсе килмәй бит, яшеренергә мәҗбүр булдык. Нимесләр дә безнең белән. Тегеләрнең аякларына киендердек.

Нишләргә, үзебезнең якка чыгып булмай бит. Безнең урын – ышык. Үзебезнең як күренә, болар ягы күренмәй. Тракторный да күренә. Без монда көне буена утырырга мәҗбүр булдык. Көндезге сәгать икедә җиде нимес опять бу җортка кайттылар. Безне белмиләр. Монда торалар икән. Коралларын ташладылар болар тышка. Боларны да кулга алдык.

Безнең хәзер ундүрт тә җиде – җегерме бер нимес булды, ә без – өч кеше. Безгә үзебезнең яктан связной килде. «Давай, – ди, – күпме пленный бар, алып чыгыгыз», – ди. Ул кеше шулай дип әйтеп тә бетерәлмәй, шундук аңа пуля тиде, яшеренмәгән.

Хәзер көн кичкә авышты. Җан түзмәй, җөрәк ашыга. Ничек тә боларны алып кайтып тапшырасы килә. Мещеряковка әйтәм: «Иптәш Мещеряков, икегез монда каласыз, мин шушы тал арасыннан чыгып китәм. Ә сез минем арттан нимесләрне озатыгыз. Мин чокырдан чокырга түш белән үзебезнең якка шуып китәм. Озак та үтмәй, Мещеряков тегеләрне минем арттан берәмтекләп тезеп чыгарып җибәрә башлый. Әгәр чыкмасалар, атарга приказ бирдем мин аңа. Мин хәзер – үзебезнең якта. Нимесләр берәмләп минем арттан чыга башладылар. Урын аулак, чокыр эче. Безнең үзебезнең яктан, нинди кешеләр микән, дип, карап торалар безне. Килә бер старший лейтенант: «Бу нимесләрне обысковать итәргә кирәк!» – ди. «Иптәш лейтенант, мин әйтәм, болар, дим, обысковать ителгән, кулга да алынган. Кирәк булса, тегеннән кереп ал инде». Теге аптырады инде. «Син нинди кеше?» – дип сораштырмакчы була. «Ничек боларны берүзең генә тоттың?» – ди. Мин тегеңә: «Вакыт юк, тизрәк үзебезнекеләргә алып кайтырга кирәк», – дим.

Экспедициягә килүчеләр истәлекләрне терки. 1948 ел.

Ундүрт нимес минем кырга килеп җитте. Күңел тынычланды. Теге яктагылары өчен дә куркыныч юк – ике иптәш анда. Җан ашыга бит. Бу ундүртен тизрәк алып кайтып китәм. Үзебезнең торган җиргә кайткан идем, безнекеләр каядыр киткәннәр. Төн караңгы. Сораштыра торгач, үзебезнең частьны таптым. Алып кайттым тегеләрне, ундүртен дә. Капитанга сдавать иттем. Мещеряков белән Емоглатов та озакламый икесе дүртне алып кайттылар. Өч нимес чыкканда пуля тиеп үлгән.

Моннан соң миңа капитан рәхмәт белдерде. Мине штабка алып китте бу. Нимесләр белән барабыз. Үзебезнең начальствога күрсәтте. Шуннан соң мине «За отвагу» медале белән наградить иттеләр. Мещеряков белән Емоглатовка да бирделәр. Дивизия алдында генерал-майор Усенко безнең өчебезгә благодарность белдерде.

Шушы көннән соң мин һәр сугышта катнаштым. Ә 2 февраль көнне нимесне, Сталинградта тәмам тар-мар итеп, җирләп тә куйдык. Безне ялга озаттылар.

«БЕЗНЕҢ ДӘҮЛӘТНЕҢ ТӨП КРЕПОСТЕ – КЕШЕ»

Луиза Янсуар

Бу сүзләрне Сталинград сугышыннан соң әйтә Василий Чуйков. Яу кырында сугышчыларның башка сыймас нинди батырлыкларга сәләтле булуын үз күзләре белән күргәнгә, алар белән ут һәм туфракны бергә йотып, исән чykканга, чын күңеленнән инанып әйтә.

Тумышы, чыгышы белән үзе безнең яклардан булмаса да, Василий Чуйков исеме Татарстан һәм Казан белән тыгыз бәйләнгән. 1919 елда ул Көнчыгыш фронтта 5 нче армиянең 28 нче дивизиясе 40 нчы укчы полкын җитәкли һәм безнең төбәкне акгвардиячеләрдән азат итүдә катнаша. Аның оста җитәкчелеге Кызыл Армиянең хәлиткеч җиңүенә өлеш кертә.

Быел Советлар Союзы маршалы Василий Чуйковның тууына 125 ел.

ӘЗМӘВЕР ИОНЫЧ

Василий Чуйковның туган авылы Серебряные Пруды бик борынгы җирләр санала. Дозор, сак пункты буларак яши башлаган, күпсанлы узгыннар-баскыннарны кичкән авыл XIX гасыр азагына тәмам ныгый, аякка баса. Анда 4 меңнән артык кеше исәпләнә, сәүдә юллары уза, ул хәтта өяз шәһәре Венёвтан да мулрак яши.

Гади сословие халкы да ачтан интекми. Чуйковлар крестьяннардан була, гомер-гомергә иген игә, терлек асрый, балта эше белән көн күрә. Иван Ионыч та бу традицияне дәвам итә. Сукса, тимер бөгә торган бу әзмәвер ирнең ишле гаиләсендә зәмһәрир февраль таңында сигезенче бала булып тагын бер углан дөньяга килә – СССР ның булачак маршалы, ә әлегә – бәләкәч Василий. Сигез ир бала һәм 4 кыз үскән бу гаиләнең башлыгы Ионыч авылны дер селкетеп тотса да, гаилә дилбегәсен әниләре, Елизавета Федоровна, беразга гына да бушатмыйча, үз кулында тота. Ире белән каршылыкка кергәндә дә, шунда ук күкерт кебек кабынып киткән Ионычка түбәннән – үз буе биеклегеннән туп-туры карап: «Мин әйттем, бетте-китте!» – дия торган була.

«ХОДАЙДАН ЯЛВАРЫП САКЛАП КАЛДЫМ!»

Әниләре Елизавета Федоровна 12 баланы тәрбияләү, җир эше белән беррәттән, беркайчан да чиркәүне калдырмый. Күп еллар дәвамында Никольский приходы советын җитәкли, чиркәү старостасы була. Чиркәүләрне җимергән елларда ул Серебряные Пруды гыйбадәтханәсен саклап калуга ирешә. Храмны ябалар, 30 нчы елларда рәшәткәләрен, тышкы якларын сүтәргә керешәләр. Сугыш вакытында аны немецлар атлар тотар өчен куллана. 40 нчы елларда Никольский храмы авылда бердәнбер ябып кадаклап куелмаган яки шартлатылмаган храм булып кала бирә. Ул үз чиратын көтә... Авыл картлары тетрәнеп искә ала: шул чакта Елизавета Федоровна, җыенып, Мәскәүгә «Сталин белән күрешергә» чыгып китә. «Бөтенсоюз старостасы» Михаил Калинин янына керергә мөмкинлек таба. Ул авылга әйләнеп кайтканнан соң, чиркәүгә орынмыйлар.

Уллары Гражданнар сугышында, Кытай, Маньчжурия чикләре янындагы бәрелешләрдә катнаша, Бөек Ватан сугышының соңгы көненәчә алгы сызыкларда була. Берсе дә һәлак

Фото: ТР Милли музее, waralbum.ru сайтыннан

булмый, аяксыз-кулсыз калмый, репрессия иттарткычына эләкми. Ялардан соң, дөньяга тынычлык килгәч, төп нигездә җыелганда, Елизавета Федоровна: «Мин сезне дога белән Ходайдан ялварып саклап калдым!» - дия торган була.

Кызыл Армия, партия сафларында булган уллары да һәрчак әниләренең фатихасын алып китә торган була. Елизавета Федоровна аларга хач һәм дога язып хәстәрләгән бөтиләрен биреп, озатып кала.

«МАЛИНОВЫЙ ЗВОН», ЯКИ КЫЗЫЛ ЯШЬЛЕК

Крестьян балалары тиз үсә һәм үз көнен күрә башлый. Василий да шулай – җиде яшендә аны чиркәү-приход мәктәбенә бирәләр. Беренче укытучысы Ефанов аның тырыш, зирәк, башлы малай булуын искәртә. Чуйков Бөек Ватан сугышын кичеп кайткач та, укытучысының хәлен белеп тора.

Чиркәү мәктәбеннән соң, малай авылдагы башлангыч белем бирү училищесында укый. Училищены тәмамлап, 12 яшендә Петербургка «акча эшләргә» барырга ниятли. Анда инде олы абыйлары барып төпләнгән була.

Гаилә ишле булгач, атасы белән анасы каршы килми, бала да ныгыр дип, ризалык бирә. Әтисенең улы юлга чыкканда биргән киңәшләре искиткеч гыйбрәтле. Алар Василий Чуйковның истәлекләр дәфтәрендә теркәлгән:

«Бәләкәй әле син, Василий, әмма үсә төшкәч, бу сүзләрне аңларсың. Кешеләр бер-берсенә ышанмый башлады, һәркем үзе өчен генә яши, бөтен зур бәлаләр дә – шуннан. Ә син, улым, башкача яшәргә тырыш. Артык шапырынма, халык кичергән кайгыларны ташлап, качып китмә. Дөрес, туры, гадел яшә. Намусы югалганнан соң, күзләрен күтәреп карый алмый торган кайберәүләр кебек булма. Гади кешеләргә ышан һәм таян: алар сине аңлар да, сатмас, сынатмас та, бәладә дә ташламас. Бөтен көч – гадиләрдә. Халкың өчен үзеңне кызганма, улым».

Малай баштарак йөк ташый, ишегаллары себерә. Аннары абыйлары юньлерәк эш юнәтеп бирә – мунчада парадная баскычында йомышчы малай булып тора башлый. Иртәнге 7 дән төнге 11 гә кадәр йомышта чабып йөри. Озакламый кечкенә генә бер ялгышы өчен куып чыгаралар. Аннары Нева проспектында җиһазланган бүлмәләр биреп торган бер йортка урнаша, аннары – бер кунакханәгә. Мондагы башбаштаклык һәм бозыклыкларны күреп, Василий үзе чыгып кача.

Ул шпорлар ясау буенча атаклы мастер Савельев остаханәсенә ярдәмче булып эшкә керә, һөнәргә өйрәнә башлый. «Малиновый звон» чыгара торган иң затлы шпорларны

Василий Чуйков һәм Валентина Чуйкова – төрле елларда.

ул чакта Петроградта нәкъ менә Савельев ясый. 10-12 шәр сәгать дәвам иткән сменада 3-5 пар ясарга кушылса, Василий, тырышып, җиренә җиткереп, җидешәр пар ясап куя.

Ул арада башкала инде митинг, демонстрацияләрдән кайнап тора. Вакытлы хакимият урнаша. Июль демонстрациясе, атулардан соң, Петроградта яшәү чын-чынлап куркыныч була башлый. Остаханә ябыла. Василий Кронштадтка барып эләгә, юнга булып хезмәткә урнаша. Авылга кайтып, ата-аналары белән күрешеп ала да, 1918 елның язында Мәскәүгә Лефортовога килеп, Кызыл Армия командирлары әзерли торган хәрби-инструкторлык курсларына языла.

Башка курсантлар белән бергә, Көньяк фронтка җибәрелә. Краснов отрядлары белән көрәштә катнаша – инде рота командиры ярдәмчесе сыйфатында. Монда аның булдыклылыгын күреп алалар, хәтта ике-өч мәртәбә өлкәнрәкләр, Беренче бөтендөнья сугышын кичкәннәр дә яшь малайга хөрмәт белән карый башлый. Лефортовода имтиханнар тапшыргач, «кызыл офицер» таныклыгын тоттырып, Чуйковны атаклы 40 нчы укчы полкка командир ярдәмчесе итеп Казанга җибәрәләр.

«ВИНТОВКА ГАЕПЛЕ ТҮГЕЛ»

Казанда аңа губерна хәрби комиссариатында янә бер мәртәбә имтихан тотарга туры килә. 40 нчы полкта да күбесе әтисе яшендә булган командирлар белән сугышчылар бу малай-шалайга башта бик гаҗәпсенеп, шикләнебрәк карый. Көньяк фронтта булуы турында белүен беләләр, әмма кем әле ул – аларны укытырга һәм өйрәтергә...

Ләкин армия – армия инде, биредә фәрманны үтәмәү һәм синнән өстен торган офицерга буйсынмау фетнәгә тиңләнә. Шуңа да ачыктан-ачык ризасызлык белдерергә базмыйлар, әмма сынавын – сыныйлар.

Кызыл командир.

Шулай берсе «винтовка яхшы атмый» дип зарланырга килгән. Мин шунда ук янына сузылып ятам:

– Әйдә, сынап карыйбыз.

Атып җибәрәм. Бер атам, ике, өч. Читкә китмәсә генә ярар иде, дип уйлыйм эчемнән. Бәхеткә, бөтен пулялар да мишеньнең кара бөҗрасына туп-туры ята. Тыныч кына торам да сугышчыга әйтәм:

– Күрдеңме? Күз кылый карый икән, винтовка гаепле түгел.

– Күзем туры карый ла минем, – ди ул, мыек астыннан гына елмаеп, – дөресен әйткәндә, сезне сынар өчен генә иде, иптәш командир...

(Василий Чуйков мемуарларыннан)

Өч айдан 150 шәр кешедән торган ике ротаның әзерлеген 2 нче армия командующие Василий Иванович Шорин кабул итә. Рус армиясенең элеккеге полковнигы, хәрби бүләкләр кавалеры, данлыклы гаскәри. Чуйков бик дулкынлана, билгеле, җитмәсә, полктагылар аңа малай-шалай итеп карый... Әмма, ни гаҗәп, ике полк та ялт итеп, югары әзерлек күрсәтеп, сынауны бик яхшыга уза. Инде хәзер аларның якындагы армия сафларына барып кушыласы гына кала. Шорин Чуйковны бик югары бәяли һәм аларны күренекле 28 нче дивизия составына тәкъдим итә. Бу дивизиянең сугышчылар телендәге исеме – «Тимер дивизия». Ә башында легендар командир – 23 яшьлек Владимир Мартинович Азин тора...

Чуйков начдивны бер күрүдә, танышу белән үк ошата – аңардан үрнәк алырга тырыша. Ни кызганыч, аларның сугышчан дуслыгы озакка сузылмый, 1919 елның августында Азинны Көньяк фронтка җибәрәләр, Маныч елгасы буенда ак казаклар белән бәрелештә ул әсирлеккә эләгә. Озак тилмерткәннән соң, аны җәзалап үтерәләр.

40 нчы полк тимер юл буйлап Казаннан Вятские Поляныга күчерелә. Колчакның атаклы «Полёт к Волге» операциясен туктату бурычы йөкләнә аларга.

Сталинград фронты: сугыш стратегиясен планлаштырганда.

«ПУЛЕМЁТЛАР ҖИТМИ ИКӘН, АКЛАРДАН ҖЫЕП АЛЫГЫЗ!»

1919 елның мартында Колчакның яңа һөҗүме башлана. Аның гаскәрләре Бөрене алып, 11 мартта Уфаны буйсындыра. Чаллы белән Чистайга якыйлар. Аннан бөтен Идел буе уч төпләрендә, дигән сүз.

Чуйков полкы өч зур авылда урнаша: Тойма, Түбән Тойма һәм Югары Тойма. Чулманда илнең үзәгенә кирәк булган икмәк запаслары тупланган була. Полкка, 2 нче һәм 5 нче армияләр арасындагы «өзеклекне» кыскартып, Россиянең үзәгенә ипи илтүне яңадан эзгә салу бурычы куела. Язгы ташуга кадәр бу пунктларны кулда тоту да.

Әмма сүздә генә җиңел, асылда, бу – башкарып чыкмастай бурыч, чөнки корал җитми, бигрәк тә пулемётлар. Бөтен полкка – өч «максимка». Ачлык, арыганлык.

Полк командиры штат буенча җитешмәгән пулемётларны сорап, армия командующиена мөрәҗәгать итә. Командарм Шорин моңа болай җавап бирә: «Акларда пулемётлар күп, җитми икән, аклардан җыеп алыгыз, начдив Азин шулай итә иде». Снарядлар белән дә шулай: үзегезнеке бетте икән, «дошман тылына үтеп кереп, кирәк кадәрне табып алып чыгарга».

«МИНЗӘЛӘ ОПЕРАЦИЯСЕ»

40 нчы полк килеп урнашканда, акгвардиячеләр инде Минзәләне ала. Әмма Минзәләне бирергә ярамый, дигән карарга килә Азин кайнарлыгын һәм ныклыгын инде тоеп һәм үзләштереп алган Василий Чуйков.

Күп еллар дәвамында ТР Милли музее системасында эшләгән, фондларны да, тере локацияләрне дә яхшы күзаллаган эзтабар-журналист һәм музей белгече Михаил Черепанов фикеренчә, Минзәләдә Чуйковның «йолдызлы сәгате» суга: ул беренче мәртәбә җитәкчелек каршында үзенең тактик карарын раслый һәм аны югары дәрәҗәдә башкарып та чыга. «Минзәлә операциясе» фронтның бу өлешендә барган сугышларда хәлиткеч роль уйный.

«Алабугада дошманның инде килеп җитүе турында имеш-мимешләр йөри иде. Менәменә, ул шәһәрне алачак, дип сөйләнәләр. Паникёрлар, нинди дә булса сәбәп табып, я Мамадышка юл тотты, я – туп-туры Казанга. Алабугада төн кунып, без таң белән Чаллы ягына юнәлдек. Анда безгә коммунистик батальон кушылды – 400 штык белән кылыч. Минзәләдән дә кешеләр бар иде, җирлекне беләләр, димәк, дошманны кыен хәлдә калдыра торган итеп, тизрәк алга ыргылырга кирәк».

(Василий Чуйков мемуарларыннан)

Чуйков полк командирына коммунистик батальон составы турында белдерә: төнгә каршы Минзәләгә кузгалыйк, дигән тәкъдим ясый. Югыйсә, Бөредән дошман дивизиясенең өстәмә

көчләре килеп җитәчәк, сугышырга кыенрак булачак, вакыт хәл итә барысын да...

– Мин андый рөхсәт бирә алмыйм, хокукым юк, – дип, бүлдерә аның сүзен полк командиры. – Командарм рөхсәте юк, 28 нченең начдивы да Минзәләгә барырга команда бирмәде...

Ул арада яңа гына полкка килеп кушылган комиссар Алексей Юрьев сүз ала – Питер эшчесе, Октябрь восстаниесен узган кеше. Чуйковны хуплый:

– Пассив рәвештә Чаллыны саклау тактик яктан дөрес түгел, – ди ул кинәт. – Бу сугыш өчен җайлы позицияләр районда гомумән юк. Чулман ярында дошманны көтеп утыру да – ахмаклык.

Озак сөйләшүләрдән соң, командир, ниһаять, алар белән килешә. Әмма үзе Яр Чаллыда кала – кирәк булганда армия штабы белән элемтә тотарга.

– Сөйләшү тәмалангач, – дип искә ала Чуйков, – Юрьев, килеп, нык итеп кулымны кысты: «Питер ныклыгы синдә, алга таба да шулай тот».

МОНЫСЫ ИНДЕ – БӨТЕНЛӘЙ БАШКА ТАРИХ...

Казан, Татарстан җирлеге белән бәйле сәхифәләр уңышлы тәмамлана. Чуйков акгвардиячеләргә Мәскәүгә узарга юл калдырмый. Озакламый аның үзен Көнбатыш фронтка җибәрәләр.

Бу сугышларда Василий Чуйков 4 тапкыр авыр яралана: 1919 елның маенда, Көнчыгыш фронтта, Алабуга астында – кулы өзелә яза; 1919 елның июлендә, Көнчыгыш фронтта, Мөслим янында – аягына зур зыян килә; 1920 елда Көнбатыш фронтта, Белоруссиядә, Лепель астында – аягы имгәнә; 1920 елның сентябрендә, Көнбатыш фронтта, Псков тирәсендә – иңбашы бик каты чәрдәкләнә, сөякләренә кадәр үтеп керә.

Соңгысында аны алгы сызыктан бик зур авырлык белән алып чыгып, госпитальгә озаталар, аннан, ай-ваена каршы килеп, өенә ял итәргә кайтаралар. Ике Кызыл Байрак ордены белән «Омега» алтын сәгате һәм исемле корал белән бүләклиләр.

1925 елда ул Серебряные Пруды авылына ялга кайткач, булачак тормыш иптәше Валентинаны очрата. 1926 елда Валентина Павлова аның хатыны була, бу мәхәббәт гомер буена дәвам итә.

Бөек Ватан сугышына кадәр дә ул озын һәм озак юл уза. 1927 елдан – Мәскәү хәрби округы штабында башлык ярдәмчесе. 1928 елның гыйнварыннан – Кытайда киңәшче. Маньчжуриядәге аяныч, хәтәр хәлләрне үз күзләре белән күрә, үзе аша кичерә. 1932 елдан – разведка буенча начсостав курслары җитәкчесе санала.

1936 елда академик курсларны тәмамлый, Белоруссия юнәлешендә була, Совет-фин сугышында Төньяк Карелияне саклый, Төньяк махсус хәрби округының 4 нче армиясе белән командалык итә.

1940–1942 елларда – Кытайда хәрби атташе һәм төп хәрби киңәшче. Аннан соң инде – Бөек Ватан сугышының иң кайнар нокталары, Сталинград кырлары, Висла-Одер операциясе, «Майданек» лагерен азат итү, Берлинны алу, армия генералы булу... 1955 елда аңа Советлар Союзы маршалы исеме бирелә...

Ә сугыш тәмамлангач, илгә югары дәрәҗәдә – партия эшелонында хезмәт итә.

Страна должна знать своих героев
Тов. Чуйков, В. И.
КРАСНАЯ ЗВЕЗДА

ЦК КПСС КА ХАТ ҺӘМ ДОГА КӘГАЗЕ

1981 елның июлендә Василий Чуйков олы җитәкчелеккә мондый хат белән мөрәҗәгать итә:

«Көннәремнең санаулы гына калганын сизгәнгә, аек үз акылымда Сезгә үтенеч белән язам: үлемемнән соң, мине Сталинградта Мамай курганында җирләгез. 1942 елның 12 сентябрендә минем команда пункты оешкан урында... Ул җирдә Идел суының ыргылып акканы, корал тавышы һәм Сталинград хәрабәләренең сыкравы ишетелә, анда мин командалык иткән меңләгән сугышчы үзенең соңгы ышыгын тапты.

27 июль, 1981 ел.

В. Чуйков.

Василий Чуйков 1982 елның 18 мартында дөнья куя. Васыятен истә тотып, аны Волгоградтагы Мамай курганында, «Ватан-анаЕ» монументы итәгендә, үз армиясе яугирләре яткан урында җирлиләр.

Улы Александр Чуйков, әтисе үлеменнән соң, аның партбилеты белән хәрби кенәгәсе саклана торган портмоне эченнән әбисе язып тыккан дога кәгазен тартып чыгара. Советлар Союзы маршалы Василий Чуйков ул дога кәгазен үзе белән хәрби юлында гомере буена йөрткән...

Бөек Җиңүгә 80 ел тулу уңаеннан башланган «41 нче ел балалары» проектын дәвам итәбез. Бөек Ватан сугышы башланган чорда туган, тәпи киткән бу сабыйларның язмышы ничек булып беткән? Нинди могҗиза белән исән калганнар? Әнә шундый өлкәннәребезнең гыйбрәтле язмышларын барларга булдык.

2025 ВАТАННЫ САКЛАУЧЫЛАР ЕЛЫ

80 ЖИҢҮ!

ҖИР ҮЗЕ БУЛЫШТЫ...

Руфия Фазылова

Үстерде, кеше итәргә тырышты,
Иң әүвәл без әнкәйләргә бурычлы.
Сугыш чоры буыны сау: көч алдык
Үлән сутыннан – Җир үзе булышты!

Татарстанның халык шагыйре Рәдиф Гаташ үзенең сугышка туры килгән сабый чагын әнә шулай дүрт юлга сыйдырган. Әтисе Кәшфулла фронтка киткәндә аңа биш ай да булмый әле. 1941 елның августында Кәшфулла берсеннән-берсе кечкенә өч улын кулына алып сөя: «Бәлки кайтып та булмас, бәхил бул», – дип, яраткан җәмәгате Сәвия белән хушлаша. Ир күңеле дөрес сизенгән – октябрь аенда Кәшфулланың үлгән хәбәре килә. Фронтка киткәннән соң, ул бары тик бер генә хат язарга өлгерә.

«ӘНИГӘ ГОМЕРЕМ БУЕ РӘХМӘТЛЕМЕН»

Язмыш, диген, Кәшфулланың өч бертуган абый-энесе дә сугыштан исән-имин әйләнеп кайта. Әйе, язмышлардан узмыш юк. Ләкин кечкенә Рәдиф бу хакыйкатьне аңламый әле: туганнарының әтиләре – янында, ә аларныкы кайтмады. Ни өчен шулай? Югыйсә, ул да хәзер әтисе белән басу-кырларда ат җигеп эшләр иде. Ә, юк, ихаталарын төзәтерләр иде, чөнки өйгә дә, каралты-курага да ир кулы кирәк... Әнә бит, әнисе ялгыз булгач, бөтен физик эшне үзе генә башкара. Әтисе исән булса, хатын-кыз башы белән болай үгез җигеп тилмермәс иде. «Эх, әти, әти...»

«Сугыш беткән көн истә түгел», – ди Рәдиф абый. Аның каравы, ятимлек ачысының ни икәнен һәр күзәнәге белән хәтерли.

Фото: Лилиана Вәлитова

Үзеннән бигрәк, әнисен кызгана ул, чөнки тормышның бөтен авырлыгын шушы күркәм ханым үз җилкәсенә алган.

– Әнием Сәвия гомере буе Башкортостанның Кушнаренко районы Марс авылында яшәде, – дип искә алды Рәдиф абый. – Ул шулкадәр йомшак, якты күңелле, йөзендә нур уйнап торган гади авыл хатыны иде... Әтидән 32 яшьтә калган. Гомере буе аңа тугрылык белән яшәде. Әтигә дә фронтка киткәндә 32 яшь була. Әнкәй безне бик авырлык белән үстерде. Ләкин шулай булса да, абыйларны да, мине дә авыр эшкә чыгарып җибәрмәде. Иң хикмәтлесе – бөтен йөкне үзе тартса да, әни безне укудан аермады. Арабыздан киткәненә кырык елдан артык инде. Ә мин әле дә ятимлек ачысын тоям. Әниләрдән дә якын кеше була алмый, моңа яши-яши тагын мең кат инанасың.

«БЕЗ ИПИ АШАМАДЫК...»

Сугыш чорында туган балаларның барысын да бер нәрсә берләштерә – ачлык. Туйганчы кара икмәк ашау аларның иң зур хыялы була. Рәдиф Гаташ та искәрмә түгел. Хәер, өйдә бит әле 1938 елгы игезәк абыйлары Рәшит белән Рәфит тә була.

Ризык турында сүз чыккач, халык шагыйре, күңеленә нык кереп калган бер истәлек белән бүлеште:

– Җәен песи борчагын бик яратып ашадык. Ә миңа кычытканнан курка идем. Югыйсә аны әни әйбәтләп пешереп тә бирә, барыбер чагар дип шикләнеп, авызга алырга кыймадым. Әнинең кычытканны безгә бик тә ашатасы килә, витамин булсын, дип уйлагандыр инде. Миңа балачак турында сүз чыкса, гел шул ашарга булмау, фәкыйрьлек кабат күз алында килеп баса... 1959 елда мәктәпне тәмамлап, Уфага укырга киттем. Шунда гына туйганчы ипи ашаганымны хәтерлим.

Ашау дигәннән, Рәдиф абый кызык та, кызганыч та тагын бер хәлне искә ала. Ул аны «качып кына ипи пешерү» дип атый. Арыш, бодай өлгергәч, Сәвия апа төнлә башаклар кыркып кайта торган була. Базга төшеп, кул тегермәне белән тарттырып, аннан он ясый. Әйе, заманасына күрә Сәвия апа бик зур «җинаять» эшли. Бу хакта колхоз бригадиры яки рәисе белеп алса, бетте баш. Өч бала, дип тормыйлар, утыртып та куярга мөмкиннәр. Өч улын ялгыз тәрбияләүче ана кеше моны яхшы аңлаган, әлбәттә, тик газизләренә бер телем ипи ашату теләге бөтен куркуларны да җиңгән. Сәвия апа улларын каткат кисәтә: «Карагыз аны, минем он тартканны кешегә сөйлисе булмагыз!»

– Иң аянычы, мин безгә кергән кешегә, сорасалар да, сорамасалар да: «Без ипи ашамадык», – дип шар ярып сала идем. Бала бит, нишлисең... – дип елмая хәзер Рәдиф абый. – Бу инде куркудан, беркатлылык белән әйтелгән сүзләр.

Курку дигәннән, халык шагыйре яшерми: гаиләдә өч ир бала булса да, ул авылдагы агайлардан бераз гына шүрләбрәк үскән. Бу аңлашыла да, өйдә әти кеше юк. Әнисе исә улларына кычкырып, дорфа итеп тә эндәшми. Ә пар канатлы гаиләдә үскән балалар әтиләреннән әнә ничек куркып тора! Шулай булгач, булачак шагыйрьнең балачагын начар дип әйтергә мөмкинме соң? Юктыр. Рәдиф абый хәзер әнә шулай дип фикер йөртә.

– Рәдиф абый, ә сезнең балачактагы хыялыгыз нинди иде? – дим.

– Очучы булырга хыялландым, – ди ул, күзләре шунда ук очкынланып китә. – Әдәби китаплар укуның нәтиҗәсе дә булгандыр. Тик күзем начар булганлыктан, әлеге хыялның тормышка ашмаячагын тиз аңладым. Хыяллар күп иде ул балачакта. Матур кием дә киясе килгәндер, чөнки абыйлардан калган иске-москы белән үсәргә туры килде. Чоры, заманы шундый булган, берәүгә дә үпкәләп булмый. Ашарга ризык, кияргә кием булмаса да, без ул вакытта рухи байлыкка кинәндек. Абыйлар белән китапханәгә кайткан һәр китапны алып, ярышаярыша укыдык. Нәтиҗәдә, барыбыз да әдәбият юлыннан киттек.

...Рәдиф Гаташны якыннан белгән кешеләр килешер, дип уйлыйм: хатын-кызга аның кебек мәдхия укыган, шул дәрәҗәдә хөрмәт иткән шагыйрьләр тагын бармы икән? Моның сере, һичшиксез, өч баласын ялгыз үстергән Сәвия апада кебек. Аңа таянып үскән балалар хатын-кызны олыламый торган була алыр идемени?! Иң авыр елларда да улларының күңеленә әнә нинди оеткы салган бит ул! Бу турыда Рәдиф абыйның үзеннән дә яхшырак әйтеп булмас:

Йөз ел тоташ Җир иде ут эчендә,
Янды асыл ирләр «сугыш миче»ндә.
Дөньяны сөйрәп барды кем? Хатан-кыз,
Әле дә шулай! Язам белгән өчен дә!..



– Ә мин әле дә ятимлек ачысын тоям. Әниләрдән дә якын кеше була алмый, моңа яши-яши тагын мең кат инанасың...

китап к

«ТАТАР КЕШЕСЕ ҮЗ ӘДӘБИ МИРАСЫН БЕЛЕРГӘ ТИЕШ»

Луиза Янсуар

Апрель – Тукай ае, аның белән бәйле чаралар ае. Бу айда без янә бер мәртәбә аның исемен һәм шәхесен яд итеп кенә калмыйбыз, ә әдәбиятның торышын да бизмәннәргә салып үлчибез. Йөзебезне, асылыбызны барлыйбыз. Кемнәр белән горурлана алабыз? Тукайлар калдырган мираска лаекмы без? Заман әдипләрен ничек бәялибез һәм кадерлибез?

«Китап киштәсе»ндә бу юлы сүзне 2025 елгы Тукай премиясе кандидатларына бирергә булдык.

Фото: culture.ru, livelib.ru

«КИТАП МИНЕМ ӨЧЕН – АНТИДЕПРЕССАНТ»

Мансур Гыйләҗев, драматург

«Словарь любви» пьесалар җыентыгы («Бичура», «Баскетболист», «Игезәкләр» һ.б.) өчен

Беренче китабымны хәтерләмим. Шөкер, әнием исән, ул исемә төшерде – «Әлифба» иде ул, улым», – диде. Безнең ул «Әлифба» хәзер дә Займищедагы дачада саклана, нык таушалган инде үзе. Тагын бөтен гаилә белән «Чаян» журналын актарырга яратканбыз икән. Аларны әти брошюровка ясап җыеп бара иде. Андый матур, кызыклы журналлар юк инде

киштәсе

хәзер. Брошюралар архивыбызда саклана. «Татар халык әкиятләре», Габдулла Тукай һәм Шәүкәт Галиев китаплары да исемдә.

Балачакта мине Редьярд Киплингның «Маугли» китабы тетрәндерде. Ул вакытта бик талантлы итеп эшләнгән мультфильмы да бар иде. Мин бертуктаусыз шуларны укырга һәм карарга ярата идем.

Әтинең эш кабинетында бер киштә бар – анда иң кадерле китаплар саклана. Болар – Антон Чехов, Генрик Ибсен, Әмирхан Еники, Эрнест Хемингуэй, Бернард Шоу, «В мире мудрых мыслей» китабы һ.б. Шул киштәдә мәктәп укучысы вакытымда Эрих Мария Ремаркның «Триумфальная арка» романын таптым. Шуннан туплана башлады да инде минем башта җитди фикерләр...

Хәзер Еникинең «Рәшә» китабын укыйм. Моңарчы аны укыганым юк иде... Камал театрында Айдар Җаббаровның «Рәшә» спектаклен карадым да бик кызыксындым бу әсәр белән. Татар телен бик начар беләм шул. Мин «рәшә» сүзен «мираж» дип кенә аңлый идем...

Гомерем буе Достоевский тетрәндерә. Мәктәптә безне класс белән «Преступление и наказание» фильмына алып барганнар иде. Ул вакытта мин күп нәрсәне аңламаганмын. Хәзер генә төшенә башладым.

Искерми торган классика да ул, минемчә, Достоевский. Бөтен дөнья телләренә тәрҗемә ителгән һәм бөтен халыклар да аны якын күрәләр.

Һәр китапның үз вакыты бар. Хәтерлим, мәктәп чорында үземне мәҗбүр итә-итә «Война и мир»ны укып чыктым. Мин бик тәртипле малай идем, кушканны үти торган... Ләкин монда яртысы француз телендә, күп нәрсә аңлашылмый... Түздем, шулай да ахырына кадәр барып җиттем. Аны бит без еш кына «Сугыш һәм тынычлык», яки «Сугыш һәм солых» дип аңлыйбыз, ә асылда ул – «Сугыш һәм дөнья», болай мәгънә тагын да тирәнәя...

Иң яраткан китапларым – Аяз Гыйләҗев әсәрләре. Анда һәр кешегә кирәк булган тема һәм фәлсәфә бар. Башыннан ахырына кадәр укып чыксаң, фикерләр өчен шул җитә. Хатларын да – онытмаска!

Өстәл китапларым гел алышынып тора. Мин үзем дә үзгәрәм бит. Тормыш та үзгәрә.

Минем өчен кадерле һәм якын бер шәхес бар. Ул кешенең фикерләрен күбесе кабул итми, үзен дә... Никита Михалков турында әйтүем. «Публичное одиночество» китабын укып карарга киңәш итәр идем. Ул татар дөньясын бик хөрмәт итә, аңа соклана, ислам динен дә чит күрми. Безнең Коръән укучылар конкурсын мактый, «Мухаммад: Посланник Бога» фильмын руслрга үрнәк итеп күрсәтә.

Мин – архаик кеше, кәгазь китапны яратам. Ләкин мин ретроград түгелмен, шуңа аудиоформатны да кабул итәм. Машинада барганда, «Китап» радиосын тыңлыйм. Анда минем яраткан артистларым әдәби әсәрләр укыйлар. Аларны тыңлау – үзе бер ләззәт!

Китап минем өчен – антидепрессант. Беренче урында – оныклар, алар белән теләсә нинди депрессияне онытасың, икенче урында – китап.

Мине бәхетле итә торган китап – «Маугли». Ул мине кабат балачагыма алып кайта. Тагын – Эрнест Сетон-Томпсонның «Рассказы о животных» китабы.

Бүгенге укучыга чын классика кирәк. Аяз Гыйләҗев киштәсендәге китаплар.

Соңгы вакытта Илон Маскны хөрмәт итә башладым. Чөнки ул шундый сүзләр әйтте: «Одна книга Достоевского заменяет всю современную литературу по психологии...» Илон Маск – Америка гражданины. Нишләп соң әле ул Хәмингуэй, Фолкнер, Фицджеральдларны атамый? Димәк, Достоевскийда дөньяның бар халыклары өчен дә әһәмиятле нәрсәләр яшеренгән...

Драматургларда «боҗралап кую» дигән төшенчә бар. Сүз башым бит «Әлифба» иде, инде шуның белән төгәллисем дә килә... Сүземне генә, димим, ә тормышымны да. Үзем өчен укыдым, үзләштердем, хәзер инде бу китапны оныкларыма укыйм. Быел экраннарга Сәләй Вәгыйзов белән Рәмзия Вәлитова турында төшерелгән бик талантлы фильм чыга. Аны минем дусларым төшерде.







«КИТАП – МИНЕМ ЯЗМЫШЫМ...»

Рәниф Шәрипов, шагыйрь, драматург, публицист; «Җомга», «Бөртек-бөртек яктылык» китаплары өчен

Мин җете хәтерләгән беренче китап – «Том Сойер маҗаралары». Анда балачак кичерешләре бик төгәл сурәтләнгән, үзе гаҗәеп мавыктыргыч.

Балачак китапларым, дигәндә, алар китап кына түгел, ә журналлар да. Күп еллар дәвамында әллә ничә буын баланы тәрбияләп үстергән китап – «Әлифба», билгеле. Шундый ук миссиясе булган журнал – «Ялкын». Тагын бер миңа бик кадерле басма – «Кызыклы физика».

«Тарихкача яшәгән малайның күргәннәре». Бу китап миңа үсмер елларда бик көчле тәэсир итте. Шул малайның күргәннәре хәзер дә исемдә.



Тормышымда иң мөһим карар кабул итәргә булышкан китап – Николай Амосовның «Мысли и сердце» китабы. Ул – күренекле хирург, галим һәм язучы. Китабы көндәлек язмалар характерында, табиб анда үзенең профессиональ өлкәдәге уңышларын, уңышсызлыкларын, тойгыларын, борчуларын терки, бик катлаулы сорауларга җавап табарга тырыша. Мин медицина белән бик кызыксынам, һәм бу китапның кулыма килеп керүе яхшы булды...

Мөхәммәт Мәһдиев әсәрләрен кабат укыйм. Бу – юмор белән өретелгән татар тормышының энциклопедиясе.

Беркайчан да искерми торган мәңгелек классика дип тә Мәһдиевне саныйм. Бездән соңгы буыннарга да татар тормышының ни икәнен сөйләячәк ул. Татар кешесе гомумән үз классик әдәби мирасын белергә тиеш, дип исәплим.

«Доктор Живаго» әсәре мине бөтенләй җәлеп итмәде. Югыйсә, ул бит инде бөтен дөнья таныган роман булып санала. Әмма мин, никадәр тырышсам да, эченә кереп китә алмадым.

Өстәл китабым – Рабиндранат Тагорның кыска шигырьләре. Ике-өч юлга сыйган могҗиза дип атар идем мин аларны.

Кәгазь китапны яратам. Аудиокитапларны кабул итмим, без китапны кәгазьдә укып үскән буын.

Китап – минем язмышым, таянычым, юл күрсәткечем.

Берничә дефицит китабымны укырга дип алдылар да кире кайтармадылар. Ул китаплар үземә бик кадерле иде. Шуларның берсе – Олжас Сөләймановның «АЗиЯ» китабы.

Бүгенге укучыга кыска, ләкин эчтәлекле китаплар кирәк. Замана укучысы китапны безнең кебек комсызланып «йотмый», бик сайланып кына укый.



Танылган журналист, укытучы, шагыйрә. КДПУның тарих-филология һәм КДУның журналистика факультетларында белем ала. Озак еллар мәгариф системасында эшли, массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек итә. Соңрак үзе дә журналистика өлкәсендә хезмәт куя. Бүгенге көндә газета-журнал битләрендә аның шигырьләре, хикәяләре даими басылып тора. Мәгариф һәм ММЧ өлкәләрендә күпсанлы бүләкләргә ия. Татарстан Журналистлар берлеге әгъзасы.

Хәмидә Гарипова

ЯЗ ИСЕ

(хикәя)

Газиз әнкәемә –
тыл ветераны
Әминә Сабитовага багышлыйм

***

Әле генә унсигезе тулган Әминә инде өченче елын Кошман авылында хат ташучы булып эшли. Шөкер, сугыш бетте. Юкса сизгер күңелле җиткү кыз фронттан җибәрелгән кара мөһерле хатларны ияләренә тапшыруның читенлеген үзе генә белә. Әйтерсең, бу хатның килүенә почтальон кыз үзе гаепле. Хат ташучының фронттагы әтиләреннән, ирләреннән, улларыннан, сөйгән ярларыннан сөенечле хәбәр китерүен һәрдаим өзелеп көтеп торалар шул авылда. Кызның үзләре ихатасына таба борылуын әллә каян күреп алалар да, олысы-кечесе атыла-бәрелә каршысына йөгереп чыга. Зур букчасыннан шул кара мөһерле конвертны тартып чыгарганда ук Әминәнең бармак битләре пешкәндәй була, карашы уйчанлана, йөзенә шомлы күләгә йөгерә. Шул хәерсез мәктүпне иясенә тапшырган мәлдә авылдашларының якты өметен ул гына кисә кебек тоела.

Айга берничә мәртәбә аның күз алдында үзәк өзгеч күренеш кабатлана. Яман хәбәр алучы бәхетсез җан әүвәл, гаҗизләнеп-тилмереп, хат китерүчегә күтәрелеп карый. «Иясен бутамадыңмы? Бәлки, бу хат безгә түгелдер» дигән сыман, сораулы караш ташлый. Ә аннан соң чын мәхшәр куба. Ул тапшырган кайгылы хатларны ачып укыган хатыннарның кайберләре шунда ук йөрәгән тотып егыла, кайсы тораташ булып ката, телсез-авазсыз кала. Аптырагач, Әминә район больницасыннан нашатырь спирты сорап алды, шешәне сумкасында йөртә башлады. Урам уртасында аңсыз егылучыларга шуны иснәткән чаклары еш булды. Чәчләрен йолкып, җирне тырный-тырный илереп елаган әниләренә кушылып, ачлыктан эчкә баткан күзләрен нәни куллары белән уа-уа яшь түккән ыштансыз нарасыйлар, чандыр үсмерләр һәм коры сөяккә калган карт-карчыклар иңрәве Әминәнең колагында әле дә яңгырап тора сыман.

Күрше Мәхүпҗамал әби сугышка бөркеттәй өч улын озаткан иде. Беренче елда ук олы уллары Хамисның кайгылы хәбәре килде, уртанчысы – Харисы – Мәскәү янында ятып калды. Ананың күз текәп көткәне, бөтен өмете-юанычы Ленинград фронтындагы Хәмзәсе иде. Төпчеге хатларны ешрак язды. Апрель азагында Берлинның үзеннән үк җибәрелгәнен соңгы хатын, өй борынча кулдан-кулга йөртеп, сөенешеп укыдылар. «Әткәй-әнкәй, тиздән сугыш бетә. Фрицларның өннәрен тузгытабыз, өйләренә кереп тукмый башладык. Гитлерны тиздән дөмектерәбез! Язгы чәчәүгә үк өлгереп булмаса да, Сабантуйга кайтып җитәрмен, дип өметләнәм», – диелгән иде анда.

Хәмзәнең үлем хәбәре авылга 9 май көнне килеп ирешә. Бөтен халык урамга сибелеп, берсен-берсе котлый, кочаклаша, шау-гөр килеп, сөенеч уртаклаша. Җиңү көнен җырлап-биеп, бергәләп бәйрәм иткән мәл иде. Әминә аптырап бетте: шом-

Әмир Мәҗитов картинасы

лы конвертны кулына бер алды, бер куйды. Ныклы карарга килгән сыман аны, яулыгына төреп, сумкасының төбенә үк төшерде: «Бүген тапшырмыйм. Булдыра алмыйм... Шундый зур бәйрәмдә күрше әбекәйнең соңгы өметен өзәргә кулым бармый. Мәхүпҗамалэттәй бер генә көн булса да тынычлап яшәп калсын», – дип пышылдады ул үз-үзенә.

Сугыш чорының кануннары кырыс. Әминә аны бик шәп белә. Бер хат-хәбәрне дә сумкаңда яшереп калдырырга хакың юк. Өйгә кергәч, кеше-кара күзенә чалынмасын дип, букчасын сәндерә өстенә үк томырды.

Икенче көнне таң белән тәрәзә шакыган тавышка дертләп уянып китте. Көтү куарга йоклап калынганмы әллә дип, дивардагы герле сәгатькә күз салды. Ишек ачарга яланөс кенә йөгереп чыккан кызның, Мәхүпҗамалэттәйне күргәч, эче жу итте. Таң төбеннән ник кергән? Соңгы елларда өрлектәй улларын югалту хәсрәтеннән бик нык бетерешкән, бөкрәеп кенә атлаучы хәлсез карчык бүген ничектер тагын да кечерәебрәк калган кебек тоелды. Әбекәй, моң тулы соры күзләрен мөлдерәтеп, кызга туп-туры карады. Әйтерсең карчык аны үтәли күрә, яшерен серен белә кебек тоелды. Әминә үзен угрылык өстендә тотылган карактай уңайсыз хис итте. Кызарып чыкты, карашын аяк астында аунап ятучы, кыр тычканыдай озын койрыклы тишек чабатага текәде.

Карчык авырлык белән генә телгә килде: «Өченче төн бер үк төрле төш күрәм. Бүген таң алдыннан Хәмзәм тагын төшемә керде. Балакаемның кулындагы зуп-зур, түптүгәрәк ипие коега төшеп китте... Йөрәгем сизә, юньлегә түгел бу. Багалмамның ризыгы өзелде микәнни соң?» – дип, елап җибәрде. Аннары: «Сизгер ана йөрәген барыбер алдый алмассың, дөресен әйт! Төпчегемнән ул-бу хәбәр юктыр бит?» – дип, инәлеп бакты. Әминәнең аңа «похоронка»ны чыгарып бирми чарасы калмады.

Карчык кәкреле-бөкреле соргылт агач тамырына охшаган кытыршы бармаклары белән әүвәл конвертны сыйпап куйды, аннары хәлсез күкрәгенә кысты. Күзлексез берни күрмәсә дә, төпчегеннән килгән мәктүпне битенә якын ук китерде. Шул мәлдә аның күзләре конверт тышындагы зур кара пичәтне абайлап алды. Колак төбендә «зеңзең» иткән тавышлар ишетелә башлагач, ул болдыр идәненә чүмәште. Мәктүпне кызга сузды. «Күршекәем, укып кына чыксаңчы», – дип пышылдады.

«Ваш сын, рядовой Хамидуллин Хамза Ханифович, пал смертью храбрых при штурме Берлина...» – дигән сүзләрне укып бетергәч, Әминә тып-тын калган карчыкка моңаеп күз ташлады. Соңгы өметенең өзелүен кичерә алмаган карт ананың җыерчыклы йөзе чытылып, бер якка чалшайган, ярымачык соры күзләрендә газаплы әрнү билгеләре ярылып ята. Нечкә иреннәре зәңгәрләнеп чыккан. Мәхүпҗамалэттәй, тешсез авызын җилкапка чаклы киереп ачып, буыла-буыла соңгы сулышын ала иде...

***

Әминәнең энисе Әһликамал Тәүгелде кырына окоп казырга барган җиреннән үпкәсенә салкын тидереп кайтты. Ире Ризатдинның ни үлесе, ни тересе хакында бернинди хәбәре булмаса да, өйдәгеләр өметне өзмәде әле. «Күр дә тор, этиең шул нәгъләт Гитлерны дөмектереп, авызын колагына шае җәеп кайтып керәчәк әле, кызым. Ут йөрәкле ир, җир тоткасы бит ул! Көче ташып тора бит аның. Сугыш чыгасы елны эзмәвердәй сугым үгезен берүзе мөгезеннән каерып егып, тирә-күршене шаккатырганые ул. Кулыннан бөтен эш килә бит бәгырькәемнең. Ни тотса, шуны гөл итә дә куя иде инде. Атаң тырышлыгы белән шушы җыйнак-җылы өебезгә тиендек, кызым. Ә шаянлыгы, уен-көлке яратуы тагын! Мәҗлестәге бөтен кешене үз авызына карата да куя иде инде. Тальянын сызды-

рып, йөрәкләргә үтәрлек моңлы тавышы белән бер сузып җырлап җибәрсә, бар кеше таң калып тыңлый! Тормышны шулчаклы сөйгән, яше кырыкка җитмәгән ирнең җанын кыярга Газраил галәйһиссәламның кулы күтәрелмәс әле...», – дип сөйли-сөйли, баласын юатты ана. Көзге ачы җилләр тәрәзәне какса да, буранлы төндә капка шыгырдап куйса да, Әминә: «Әткәй кайтты бугай!» – дип йөгереп чыкты. Әмма этиләре тирән суга төшеп югалган көмеш тәңкә сыман гаип булды.

Гаиләне тетрәндергән вакыйга, сугыш бетеп, ел ярым узгач, 46 елның көзендә йөрәккә яра салды. Яңарак кына силсәвиткә сәркатип булып урнашкан иптәш кызы Кәримә Әминәгә этисе Ризатдинның батырларча һәлак булуы турындагы «похоронка»ны китереп тоттырды. Ул аны, авыл советы рәисе Сәет абзый эшеннән алынгач, документларны тәртипкә китергәндә, хуҗа өстәленең аскы тартмасыннан табып алган икән. Конверт тышындагы почта штемпеленнән күренгәнчә, бу хат авылга 1942 елның язында ук килгән булган, әмма ни гомер мәкерле ният белән иясенә тапшырылмыйча яткан.

Этиләре сугышта үлгән балаларга азмыкүпме пособие түләнде, туендыручысын югалткан гаиләләр коточкыч зур салымнардан азат ителде, аларны мәҗбүриләп – елатып займга яздырмадылар бит. Балалы тол солдаткаларның бик сирәген генә ирексезләп окоп казырга җибәрделәр. Этиләре һәлак булган килеш, нишләп алар бу ташламаларның берсеннән дә файдалана алмый калган соң? Боларны уйлап, Әминәнең башы катты.

Чуалган йомгакның очы берничә елдан соң гына табылды. Дөрес булса, Сәет абзый, бугазына яман шеш чыгып, су белән сыек шулпадан гайре берни йота алмыйча, үлем түшәгендә тилмереп ятканда, тәүбәгә килгән, әлеге гөнаһлы гамәле өчен, тол хатыннардан, шул исәптән Әһликамалдан да, үзен кичерүен сорамакчы булган икән, дип сөйләделәр. Менә сиңа мә! Кызыл Байрак орденлы атаклы гвардиянең сугыш кырларында тиңдәшсез зур батырлыклар күрсәткән мотоукчылар полкы каһарманы, туган җирен яклап шәһит киткән кече лейтенант Ризатдин Шәмсетдиновның толятим газизләренең үз авызларыннан өзеп фронтка дип тапшырган сөтен, итен, маен, йомыркасын ничәмә-ничә еллар буена Сәетенекеләр тыгынып яткан булып чыга түгелме соң?!

Әһликамал саусызланып калды. Этисез көн итүнең авыр йөге чандыр гәүдәле, өзелергә торган нечкә билле, диңгез суыдай фирүзә күзле, көнбагыш чәчәгедәй сары чәчле Әминәгә дә бик иртә төште. Ул коеп яуган яңгырга, котырынган кар-буранга, ми кайнатырлык челләгә карамыйча, көндәлек почтаны, тап-тар иңнәренә букча асып, ел әйләнәсе биш чакрым ераклыктагы район үзәгеннән күтәреп ташый. Эт булып арыса да, шул көнне үк авыл буенча тарата. Эшен җиренә җиткереп башкара. Шуның өстенә, авылдашларының мең төрле йомышын үти. Кемгәдер райүзәктән белешмә юлларга кирәк. Кайсының салымын түлисе бар. Кемнең камыт инәсе сынган, кайсының тегәрҗебе беткән. Берәүнең баласы чирләгән, икенчесенең сыерының җилене шешкән. Гозер тыңлап, юл уңаеннан «әптиккә», ветучастокка, кибеткә, төрле оешмаларга сугылып чыкмый булмый.

Язгы җилдәй җитез кыз барысына да өлгерә. Карт-корыга хатлар языша, еактан килгәнен укып бирергә иренми. Ачык йөзле, тәмле телле «пушталиун»ны һәркайда көтеп алалар, рәхмәт әйтеп озатып калалар. Әбекәйләр, үз итеп, аркасыннан сөя, уллары буй җиткергән аналар сынаптикшереп бага, егет-җилән яшертен генә күз атып кала.

Сугыш вакытында Әминәгә агитаторлык вазыйфасы йөкләнгән иде әле. Уңган кыз фронт хәбәрләрен, илдәге яңалыкларны кыр станнарына, ындыр табакларына барып, таңнан төнгәчә ачлы-туклы бил бөккән, Җиңү көнен якынайту өчен үз-үзләрен аямый эшләгән тол-ятимнәргә, чая солдаткаларга, төсен салган карт-корыга, башбирмәс үсмерләргә, тиктормас бала-чагага бәйнә-бәйнә төшендерә килде. Шатлыклы Җиңү хәбәрен райүзәктә ишетеп алгач, биш чакрым араны җилдәй җитез йөгереп үтеп, Симәки басуында бәрәңге утыртучы авылдашларына беренче булып җиткерүче, сөенче алучы кеше дә – хат ташучы Әминә үзе иде!

Ул яхшы хәбәргә сугыш чыкканнан бирле туйганчы ашамаган, чандыр гәүдәле, көлсу йөзле үсмерләр һәм моңсу күзле ятим балалар да, хәсрәттән саргайган, бирчәйгән бармаклы, яшьле күзле тол хатыннар да, тиздән ирләренең кайтып җитәчәген түземсезләнеп, әчке ашкыну белән көткән дәртле йөрәкле солдаткалар да, хәтта бөкшәйгән карт-коры да чиксез сөенгән иде ул чакта. Авылдашларның кайсы аны үз итеп кочаклап ук алды. Кайберсе, аның форма кәчтүме аша беленеп торган кабыргаларын чытырдатып, үзенең какча күкрәгенә кысты. Форсаттан файдаланып, кызның бит очыннан үбеп алучысы да табылды. Олылар каты, сөякчел куллары белән, шапы-шопы китереп, иңнәреннән, аркасыннан какты. Авызлар ерык иде, күзләрдә шатлык яшьләре җемелдәде... *(Дәвамы бар)*

ОЛЫ МИШӘНЕҢ ЯМЬЛЕ ЯЗЫ

Фото: Лилиана Вәлитова

ОЛЫ МИШӘ

Олы юлдан Олы Мишә авылына таба борылдык. Үзебез Мишә елгасын эзлибез: авылның атамасы бит әнә ничек атала. Тапмадык. Күрәсең, Мишә елгасы икенче якта, дип уйлаштык. Карасак, ике бала юл кырыендагы гөрләвекләрдә уйный. Тын да алмый шуларны күзәтәбез: бала чакның иң рәхәт шөгыле... Балалар да безгә игътибар итте, сагаеп гына күз төшерделәр.

– Мәдәният йорты кирәк иде безгә, – дип елмайдык.

– Менә бу юл белән туры гына барсагыз, күрерсез, апа.

– Аңлашылды, рәхмәт...

Руфия Фазылова

МӘДӘНИЯТЛЕ ТӨБӘК

Мәдәният йорты белән мәктәп кара-каршы тора икән, ике бина да төзек, күренеп тора, ремонт ясалган. Башта мәдәният йортына керергә булдык, чөнки авылның актив хатын-кызлары безне биредә көтеп тора иде.

– Рузалия Газизова булам, 2006 елдан бирле Олы Мишә китапханәсен җитәклим, – дип каршы алды безне мөлаем гына апа. – 2015 елда мәдәният йортыбызга, шул исәптән китапханәгә дә, капиталь төзекләндерү үткәрелде. Хәзер инде эшкә сөенеп киләбез.

Мәдәният йорты 1995 елда салынган икән, 150 урынга исәпләнгән.

Авыллар буенча йөргәндә шуңа игътибар итәбез: күп җирдә фольклор ансамбльләре оешкан. Алар авыл сәхнәсендә генә түгел, район, республика күләмендәге бәйгеләрдә чыгыш ясыйлар, урыннар яулыйлар. Олы Мишәнең дә талантлы хатын-кызлары, берләшеп, «Ядкарь» ансамбле оештырган. Махсус сәхнә костюмнары сатып алганнар, репертуар туплаганнар.

Мәдәният йортында авылның актив хатын-кызлары безне көтеп тора иде.

Фаягөл Фәтхуллина күп еллар – китапханәдә, Рәкыя Галимова мәдәният йортында эшләгән.

– Баянчыбыз гына юк, – дип уфтанды апалар. – Ә болай бик күңелле яшибез. Казанга да ничә тапкыр барып кайттык. Икенче сулыш ачылды диярсең, йөрисе генә килеп тора.

Олы Мишә бик зур авыл түгел: 106 хуҗалыгы бар, 273 кеше яши. Аның каравы, яшь гаиләләр шактый икән. Ким дигәндә, шундый ун гаилә санадылар. Мәдәният йортына җыелган апалардан авылның үткәне турында сораштык. Иң беренче булып Фаягөл апа Фәтхуллина сүз алды:

– 1976 елда китапханәгә кергән идем, утыз елга якын эшләдем. Ул вакытта әле Саба районына карый идек. Клуб белән китапханә исә аерым иде. Совет власте килеп, мәчет манараларын кисә башлагач, Олы Мишәнең Аллаһ йортын китапханә иткәннәр. Агач бина иде ул. Кышын утын яктык. Янәшәдә генә клуб урнашкан иде. Халык кичләрен я клубта, я китапханәдә булды. Ул вакытта телевизорлар бик юк та, булса да хәзерге кебек дистәләгән канал күрсәтми. Шуның өчен дә кешеләр егылып китеп китап укыды. Һич онытмыйм: китапханәнең исемлегендә сигез йөз кеше теркәлгән иде.

Фаягөл апа 1999 елда Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре исеме дә алган. Бүген дә өйрәнелгән гадәт буенча мәдәният йортына килә. Хәер, ул гына түгел, күп еллар мәдәният йортында эшләгән Рәкыя Галимова да авылның мәдәни тормышы өчен һаман сакта тора.

– 1946 елда туганмын, – диде Рәкыя апа. – Мин бәләкәй чакта Олы Мишәдә башлангыч мәктәп кенә иде. Аннары җиде классны Олы Саурыш мәктәбенә йөреп укыдык. Алабуга мәдәни-агарту училищесын тәмамлагач, үзебезнең авыл клубында эшли башладым. 1982 ел иде ул. Утыз өч ел әнә шулай халыкны агарту эшендә булдым.

– Клубка колхоз булыша идеме? Сабан туе, Яңа ел бәйрәмнәре турында әйтүем, – дим Рәкыя апага.

– Колхозга үзебез булыша идек. Безнең «Ленин» колхозы дүрт авылны берләштерде, халык күп, төрле бәйрәмнәр үткәрергә кирәк. Махсус газетага кадәр чыгардык. Көзге урып-җыю вакытында амбардан кайтып кермәдек. Хәтта сыер саварга да йөрдек. Шулай да колхозның бер зур ярдәме булды. Эшли башлагач та, Казанга мәдә-

ният министрлыгына уен кораллары сорап бардым. Авыл зур, урта мәктәп ачылды, балалар күп. Ә бер уен коралы да юк. Хәлне аңлаттым. Министрлыкта безнең колхоз рәисен яхшы беләләр булып чыкты, чөнки Ислам Хаҗиев республикада билгеле шәхес. Шулай итеп, авылга әллә никадәр заманча уен кораллары алып кайттым. Әле район үзәгендә дә андый әйберләр юк иде. Әнә шуның белән мәдәният йорты тормышы күзгә күренеп үзгәрде.

АБРУЙЛЫ МӘКТӘП

Әлбәттә, урта мәктәпкә дә кердек, чөнки бүген андый авыллар сирәк. Дөрес, укучылар язгы каникулда иде, аның каравы, укытучылар белән иркенләп сөйләшергә җай булды.

– Без бүген эш киеменнән. Әле менә махсус хәрби операция зонасына дип дистәдән артык җаймә токмач кисеп, киптерергә куйдык, – диеште мөгаллимнәр.

Олы Мишә урта мәктәбендә бүген 47 бала укый. Унберенче сыйныфта – бер, унынчыда алты укучы икән. Тулаем алганда, алдагы дүрт-биш елда укучылар санга кимемәячәк, дип ышандырды укытучылар.

– Коллективта нигездә тәҗрибәле мөгаллимнәр, – диде Олы Мишә урта мәктәбенең укыту эшләре буенча директор урынбасары Люция Сәхәбиева. – Яшь укытучыларыбыз да бар, шөкер. Информатика укытучысы быел гына кайтты, бик сөенәбез. Бөтен фәннәр дә укытыла, укытучылар кытлыгы юк. Һәрхәлдә, әлегә шулай.

Һәр мәктәпнең абруйлы укытучылары була, тәҗрибәсе, белеме белән алар мәктәпкә яхшы күрсәткечләр бирә. Биредә дә без әнә шундый мөгаллимнәрнең берсе – Гөлфая Хуҗина белән таныштык. Рус теле, әдәбияты укытучысы ул, кырык еллык эш тәҗрибәсе бар. Укучылары даими рәвештә БДИ дан югары баллар җыя икән.

– Узган ел Олы Мишә мәктәбен өч укучы тәмамлады, – диде Гөлфая ханым. – Рус теленнән БДИны 96, 92 балларга бирделәр. Шулай ук Зәринә Гыйлаҗиева рус әдәбиятыннан да имтихан тапшырды, 100 балл җыйды. Быел исә унберенчене бер генә укучы тәмамлый, медальгә бара. Имтихан нәтиҗәләре яхшы булыр, дип уйлыйм.

– Башка фәннәр буенча да шулай югары баллармы? – дим.

– Әйе, югары баллар. Әлбәттә, кайбер елда кайтышрак булгалый. Тик нигездә укучыларыбыз имтиханнарны гел уңышлы тапшыра.

– Моның сере нәрсәдә? Укучылар мәктәптән тыш та тагын берәр җирдә имтиханга әзерләнәме?

– Куркып әйтмим: безнең бер генә бала да репетиторга йөрми, үзебез әзерлибез. Дөрес, балаларыбыз да тырыш, бергәләп аңлашып эшлибез. Үземнең фән буенча, менә мәсәлән, инша язу өстендә озаклап утырабыз, бу БДИда мөһим.

Башка фән укытучылары белән дә аралашып алдык: фикерле, тәҗрибәле мөгаллимнәр. «Олы Мишә мәктәбе гомергә районда алдынгылар рәтендә йөрде, хәзер дә шул югарылыктан төшмәс өчен, көнне төнгә ялгап эшлибез», – диделәр. Монда эш сәгате бетте дигән нәрсә юк: укучының соравы бар икән, укытучыга теләсә кайсы вакытта язып җибәрә.

Олы Мишә мәктәбе укытучылары хәрби операция зонасына дип дистәдән артык җәймә токмач кисканнәр.

Олы Мишә урта мәктәбенең фикерле, тәҗрибәле мөгаллимнәре.

– Тәрбиягә дә нык игътибар итәбез. Безнең балалар исәнләшмичә китми. Конкурсларга баргач, үзебезнең балалар белән башкаларны чагыштырабыз да, безнекеләр өчен сөенеп кайтабыз, – диделәр.

Олы Мишә урта мәктәбенә берничә ел элек капиталь төзекләндерү булган. Сыйныфлар иркен, заманча, тик менә агач идәннәрне алмаштырырга акча җитмәгән. Киләчәктә анысы да булыр дигән өмет белән яшиләр биредә.

– Безнең төп горурлыгыбыз – укучыларыбыз, – диде мөгаллимнәрнең берсе Раушания Муллахмэтова. – Олы Мишә мәктәбен тәмамлаучылар нинди генә зур урыннарда эшләми. Барысын да санап китсәң, тулы бер исемлек җыела. Ә бит аның тарихы әллә ни зур түгел: кырык елдан гына артык. Киләчәктә бу исемлек тагын да артыр дип уйлыйбыз, укучыларыбыз бик көчле!

ДҮРТ ЯШЕННӘН – АТ ӨСТЕНДӘ!

Олы Мишәдә урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханәдән тыш, ФАП, мәчет, кибетләр, кыскасы, барлык социаль үзәкләр дә эшли. Юллар яхшы, асфальт түшәлгән. Тагын шунысына игътибар иттек: ишелгән, хуҗасыз йортлар юк дәрәҗәсендә.

– Соңгы биш ел эчендә авылда ун яңа йорт салынды, – диде Олы Мишә авыл җирлеге башлыгы Фиргать Җамалетдинов.

Әнә шул яңа йортларның берсе – Хәмидуллиннарныкы.

Өч ел эчендә заманча ике катлы яңа йорт салып чыкканнар. Апрель аенда яңа нигезгә күченергә җыеналар икән.

– Бу – әби-бабамның нигезе, – диде Искәндәр Хәмидуллин. – Үзебезнең йорт исә каршыда гына. Әби белән бабай мәрхүм булгач, бу нигезгә яңа йорт салырга булдык. Тормыш иптәшем белән ике кыз үстерәбез. Әлегә барыбыз бергә әти-әниләр белән яшибез.

Искәндәр – фермер, шәхси ярдәмче хуҗалык булып теркәлгән. Ике ел элек ферма салу өчен 600 мең сум грант откан. Шулай итеп, заманча мини-ферма барлыкка килгән. Сыерларны исә үз акчаларына алган. Бүген Искәндәрнең хуҗалыгында егермегә якын сөтлебикә бар. Маллар өчен игенен, печәнен үзләре үстерәләр. Егерме ике гектар пай җирләре бар, берничә елдан бирле шулай үзләре эшкәртә икән.

– Техниканы үз акчабызга юнәттек, әти белән бергә эшлибез, – диде яшь фермер. – Мин әтигә охшаган – мал җанлы, авылда яшәүдән рәхәтлек табам. Казанда ветеринария академиясендә белем алдым. Беренче курста укыганда ук үзем өчен хәл иттем: шәһәр минеке түгел, авылга кайтачакмын. Һәм шулай эшләдем дә.

Искәндәрнең шөгыльләре күп: көрәшче дә ул. Теләченең атаклы көрәшчеләр нәселе дәвамчысы. Дөрес, хәзер Сабан туйларында көрәшми икән, шулай да бу спорт төреннән ераклашмаган. Бүген ул Олы Мишә урта мәктәбендә көрәш түгәрәген җитәкли.

Яшь фермерның тагын бер күңеленә якын, юк, иң яраткан шөгыле бар: ул ат өстендә чаба, ягъни җайдак. Иң гаҗәбе, үзен белгәннән бирле атлар янында икән.

– Әти мине беренче тапкыр дүрт яшемдә ат өстенә утырткан, – диде Искәндәр. – Мин ул чакны бик хәтерләмим. Ә менә беренче тапкыр Сабан туенда ат өстендә чапканымны хәтерлим. Ул чакта миңа алты яшь иде. Әни хәзер көлеп тә, борчылып та сөйли: фермадан әти усал атны алып чыга да мине утыртып куя. Әни, куркып, мине аттан төшерә, әти яңадан күтәреп утырта. Шулай итеп, әти барыбер үзенекендә торган. Нәтиҗәдә, теләсә нинди атта утырып чаба алам.

– Кечкенә чагында да курку юк идеме? – дим.

– Техниканы үз акчабызга юнәттек, әти белән бергә эшлибез, – ди Искәндәр Хәмидуллин.

Яшь гаилә өч ел эчендә заманча ике катлы йорт салып чыккан.

– Юк иде. Һәм эти шуны аңлаган да. Ат үзеннән курыкканны сизсә, сине тыңламый. Шуның өчен, иң беренче эш итеп, куркуны җиңәргә кирәк.

– Тик кечкенә балада ул хисне ничек тәрбияләдең?

– Ул бирелгән буладыр инде. Мин гомер буе атларга мөкиббән. Хәзер дә шулай. Әни әйтә, балалар бакчасыннан качып атлар янына килә идең, ди. Ә минә энекәш алай атлар белән җенләнмәде. Әйтәм бит, ул яктан мин этигә охшаган. Гомумән, безнең нәселдә ат белән «чирләүчеләр» күп. Әтинең энесе дә Теләчедә нәселле атлар тота.

Искәндәр ярышларда әллә нинди исемле атларны да җиңеп килгән. Хәзер дә өендә аты бар. Дөрес, ул чабышкы ат түгел, тик Сабан туе җиткәнче бер юртак алып кайтырга нияте бар. Нишлисең, үзе әйткәнчә, шуннан башка яши алмый...

МАШИНАҢ ВАТЫЛСА, ПРОБЛЕМА ТҮГЕЛ!

Олы Мишәдә үз эшен башлаучылар шактый. Күбесенең шөгыле авыл хуҗалыгы белән бәйле. Тик менә сала өчен шактый ят шөгыльләр дә бар: шиномонтаж белән машина юуу пункты ачканнар биредә. Иң кызыгы – алар да бер-берсенә карап тора. Димәк, башта машинаңны юдырасың да, аннары көпчәкләрне алыштырасың. Ә күрше урамда автосервис та бар. Кыскасы, машинаң пычранса да, ватылса да, читкә чыгып йөрисе түгел.

– Бу инде күбрәк сезонлы эш, – дип аклангандай итте шиномонтаж хуҗасы Рәмис Хисмәтуллин. – Әлеге гаражда берничә ел пластик тәрәзәләр ясадым, хәзер дә заказлар булганда эшлим. Тик хәзер тәрәзәләр кую кыйммәткә төшә, элек сорау бик күп иде. Ә шиномонтаж эшләре белән өч-дүрт еллап шөгыльләнәм. Акмаса да, тама инде.

– Күрше авыллардан да киләләрме? – дим.

– Килгәлиләр. Шәһәрдән кайтучылар да була, чөнки Казан бәяләре белән чагыштырганда, мин ярты бәясенә генә эшлим.

Шиномонтаж каршысында торган гараж, ягъни машина юдыру пункты бикле иде. Күбрәк анда алдан язылып киләләр икән.

– Хуҗасы эштә әле аның, безнең монда һәр кешенең әллә ничә эше бар, – диде Рәмис Хисмәтуллин.

Ул да түгел, башларына яулык бәйләгән кызларны очраттык, мәдрәсәгә барулары икән. Олы Мишә мәчете каршында малай-кызлар өчен курслар оештырганнар. Шунда йөреп, гарәп хәрефләре, Коръән аятьләре өйрәнәләр. Остазлары – дини белеме булган Нурия Бәширова. Үзе дә әле кызлар кебек яп-яшь. Нурия мәктәптә тарих дәресләре дә алып бара һәм балаларга дини белем дә бирә. Бик матур башлангыч дип таптык.

...Олы Мишәдә шактый кеше белән аралаштык. Борчулары булса да, шатлыклары турында да алар тыйнак кына сөйли. Моны җирле халыкның бер үзенчәлеге дип кабул иттек. Һәм ул килешә аларга. Кайбер чакта лаф орып йөргәнче, әнә шулай тыйнак кына яшәү хәерлерәктер ул, чөнки мишәләрнең кемлеге турында эшләре, йорт-җирләре сөйли.

– Бу күбрәк сезонлы эш, – диде шиномонтаж хуҗасы Рәмис Хисмәтуллин.

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

– Чыганакларга таянсаң, Олы Мишә авылының оешуы XVII гасыр ахыры – XVIII гасыр башына туры килә. Шул елларда авылга Биккенә нәселе килеп урнаша. Алар Саба районы Өчнарат авылында туып үскәннәр. Бүген әлеге нәселнең дәвамчысы булып Илдус Нәбиулла улы Хәмидуллин тора. Яңа гына нигез салынган авылга исемне озак уйламыйлар, аңа Яна авыл исеме тагыла. Дөрес, бүген халык телендә авыл шулай дип йөртелсә дә, колхозлашу чорыннан алып документларда ул Олы Мишә буларак теркәлгән. Авылның урманга бик якын урнашуы яшәү өчен уңайлы шартлар тудыра. Авыл халкының төп кәсебе игенчелек һәм терлекчелек була.

Нурия Бәширова, Олы Мишә урта мәктәбенең тарих укытучысы

ГҮЗӘЛ ЭПОХА ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ (12+)

Европа өчен иң бәхетле һәм имин еллар, чәчәк ату һәм тынычлык чоры... Бу кайсы чор соң? Моннан йөз еллар элек, XIX гасырның соңгы дистә елы белән 1914 ел арасы. Бу чор рәсем сәнгатенең чәчәк атуы белән аерылып тора, бигрәк тә Франциядә, дөньяга Камил Писсарро, Клод Моне, Поль Гоген, Андре Дерен, Огюст Ренуар, Анри Море, Альфред Сислей, Поль Сезанн, Анри Матисс, Пабло Пикассо, Анри Руссо, Альфред Моурер, Альфонс Мухи, Анри де Тулуза-Лотрек Эжен Грассе һәм башка осталарның әсәрләрен бүләк итә. «Эрмитаж-Казан» үзәгендә ачылган экспозиция безгә рәссамнарның даһи әсәрләрен күрергә мөмкинлек бирә. Биредә рәсем сәнгатенә, графикага, декоратив-гамәли сәнгатькә караган әсәрләр бар. Кешелекнең Belle Époque – Гүзәл эпохасында туган бөек мирас белән танышыгыз, өйрәнегез, ләззәтләнегез.

Көн саен 10:00 сәг.тән 18:00 гә кадәр (җомга – 11:00 дән 20:00 гә кадәр)
Ял көне – дүшәмбе
«Эрмитаж-Казан» үзәге, 3 кат «Казан Кремле» музей-тыюлыгы

СУЛЫШ АЛУГА ТИҢ ИҖАТ (0+)

Барыннан да бигрәк Виктор Сынков замандашларын үзенең рәсемнәре белән сокландыра. Карандаш, тушь, ручка яки акварель буяулар белән кечерәк кәгазь битләрендә, шырпы тартмаларында үзенчәлекле сәнгать идеяләрен гәүдәләндерә, үзенең беркемгә дә охшамаган өслүбе һәм дөньяга карашы белән гаҗәпләндерә. Тормыштан алынган тәэсирләр, гаҗәеп хәлләр, көндәлек вакыйгалар һәм рәссам тирәсендәге кешеләр аның өчен илһам чыганагы булып хезмәт итә. Күпкырлы талант нииндидер стереотипларга, мәҗбүри стандартларга корылган совет чынбарлыгын үз итә алмый, гомере буе каршы тора, шуңа күрә принципиаль рәвештә рәссамнар берлегенә дә керми. Виктор Сынков монументаль һәм станок рәсем сәнгате, китап графикасы, скульптура белән шөгыльләнә. Экспозициядә рәссамның 400 рәсем һәм графика әсәре тәкъдим ителгән.

28 марттан көн саен 11:00 сәг. тән 20:00 гә кадәр
ДССМның «Хәзинә» милли сәнгать галереясы
Казан Кремле, 3 подъезд

КАЮМ НАСЫЙРИДА КУНАКТА (0+)

Күренекле татар мәгърифәтчесе һәм галиме яшәгән һәм иҗат иткән йортка ничек әләгергә... Чыннан да мавыктыргыч сәяхәт булыр кебек. Өстәвенә, Каюм Насыйри музее урнашкан йорт үзе XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы Казан татарларының агач архитектура һәйкәле булып тора. Бүлмә интерьерлары сакланып калган тасвирламалар буенча торгызылган. Биредә Иске Татар бистәсендә яшәүче урта хәлле катламга хас яшәү шартларын күрергә була. Музей экспозициясендә Каюм Насыйриның шәхси әйберләре: сәгать-хронометр, таягы, уку йортының шәхси мөһере язылган китаплар тәкъдим ителгән.

Көн саен 10:00 сәг. тән 18:00 гә кадәр (пәнҗешәмбе – 13:00 дән 20:00 гә кадәр, җомга – 10:00 дән 17:00 гә кадәр). Ял көне – дүшәмбе. Каюм Насыйри музее
Казан, Париж Коммунасы ур., 35

афиша

Фото: kazan-kremlin.ru, izo-museum.ru, kamalteatr.ru, tinchurinteatr.ru, tatfil.ru, кадр «Соединяющий миры» фильмыннан

«ХАН КЫЗЫ ТУРАНДЫК» (12+)

Итальян драматургы Карло Гоциянең «Турандот» пьесасы буенча Кәрим Тинчурин тарафыннан ирекле тәрҗемә итеп язылган спектакль бер тамашачыны да битараф калдырмый. «Хан кызы Турандык» император Альтоум (спектакльдә – Алтын хан) идарәсе чорында Кытайда яшәгән рәхимсез принцесса Турандот (Турандык) турында сөйли. Император фәрманы буенча принцессага яучы җибәрүче һәркем аның өч табышмагына җавап бирергә тиеш. Уңышсызлык очрагында кияүне үлем җәзасы көтә. Әмма Турандыкның матурлыгына гашыйк булган нугай принцы Калафны (Хәләфне) үлем җәзасы куркытмый. Ул ничек тә принцессаны үзенә каратырга карар кыла. Спектакль татар телендә рус теленә синхрон тәрҗемә белән бара.

29 апрель, 18:30 сәг. тә
К. Тинчурин исем. Татар дәүләт драма һәм комедия театры
Казан, Горький ур., 13

КАЙСЫ КИЯҮ ШӘБРӘК? (12+)

Гөргөри абзый һәм Кәтернә тутинең олы кызлары икесе дә атасыз бала үстерә. Төпчек кызлары Үринәне нинди язмыш көтә икән? Әмма кызны берьюлы өч егет яратып йөри. Шуңа күрә Гөргөри абзый Үринәне керәшен татарлары йоласы буенча гына кияүгә бирергә карар кыла. Шуннан китә кыз йортына яучы җибәрүләр, җыр, биюдә сынашулар. Җебегән Микуш та сынатмый, хәтта иң күркәм кияү булып чыга. Этнографиягә нигезләнгән бу җырлы-биюле тамаша Камал театрының иң популяр спектакльләренең берсе.

16 апрель, 19:00, Зур зал
Г. Камал исем. Татар дәүләт Академия театры
Казан, Татарстан ур., 1

БУ КӨННЕ 100 ЕЛ ЭЛЕК (0+)

Моннан йөз ел элек Казан халкы ничек яшәгән? Гади халык һәм байлар, алпавытлар һәм мещаннар, татарлар һәм руслар? «Казан 100 ел элек: көнкүреш һәм көндәлек тормыш» күргәзмәсенә барып, ул чорда гомер иткән шәһәрлеләрнең тормыш рәвешен күз алдына китерергә, көнкүреш үзенчәлекләренә бәя бирергә мөмкин. Экспозициядә XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы Казан мещаннары һәм дворяннары интерьерларына хас җиһазлар, фарфор, канделябрлар, көзгеләр һ.б. урын алган. Казанлылар ул чорда да заманнан калышмаска тырышкан: өйләренә электр үткәргән, телефон аппаратлары кулланган. Кунак бүлмәләрендә суга торган сәгатьләр, рус йортлары стеналарында – хуҗа һәм гаилә әгъзаларының фотосурәтләре. Татар йортлары һаман да хатын-кызлар һәм ирләр өлешенә бүленгән, йортларын чигүле сөлгеләр бизәгән... Иң кызыклы экспонатлардан – шул чор шәһәр кешеләренең фотосурәтләре.

Көн саен 10:00 сәг. тән 18:00 гә кадәр (җомга – 11:00 дән 20:00 гә кадәр)
Ял көне – дүшәмбе. Татар халкының дәүләтчелеге һәм Татарстан Республикасы тарихы музее (Сөембикә манарасы янында)
Казан Кремле

ХАЛКЫМ ЖЫРЛАРЫ (0+)

Халык җырлары һәм татар профессиональ музыкасына нигез салган композиторларның әсәрләре «Халкым» дип аталган зур концерт программасында тәкъдим ителә. Концертта Татар дәүләт филармониясе солистлары, Илһам Шакиров исемендәге «Татар моңы» халыкара конкурсы лауреатлары Вил Усманов, Асылъяр, Алмас Хөсәенов, Зәринә Хәсәншина, Салават Шәфыйков, Миләүшә Миңнушина, Булат Закиров һәм Татарстан Республикасы Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле катнаша.

27 апрель, 18:30 сәг.
Г. Тукай исем. Татар дәүләт филармониясе
Казан, Павлюхин ур., 73

ДРОПЕР, ДИПФЕЙК ҺӘМ АЛАРГА НИЧЕК КАРШЫ ТОРЫРГА

ҺӘМ КАБАТ – АЛДАУЧЫЛАР ТУРЫНДА

Евгения Чеснокова

Олы яшьтәге ханымның кесә телефонына шалтыраталар. Сәер шалтыратудан соң, ул өеннән чыгып китә һәм ул көнне әйләнеп кайтмый. Алдагы көннәрдә дә. Берьялгызы калган инвалид ире полициягә мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр була. Пенсионер ханымны эзли башлыйлар, күпмедер вакыттан соң, банкларның берсендә, банкомат янында табып алалар. Ул телефонын колагына терәп, акча салыргамы, алыргамы җыена... Телефонның теге ягыннан яңгыраган тавыш аңа тирә-юньдәге беркем белән дә аралашмаска боера. Кат-кат кабатлый. Ул ике көн дәвамында кунакханәдә яши, чөнки аңа якыннары белән аралашмаска кушалар.

МИЛЛИАРДЛАРГА ТӨШКӘН ЮГАЛТУ

Ахыр чиктә, бу конкрет пенсионер хатынны алдаучылардан йолып калалар. Әмма мондый очраклар бик сирәк. Телефоннан алдауга корылган җинаятьләрнең нибары 7–8 проценты гына ачыла. Бу хакта ММЧ өчен «Татмедиа» агентлыгы оештырган махсус семинарда ТР буенча ЭЭМның Җинаять эшләре һәм эзләү идарәсенең мошенниклыкны ачыклау юнәлешендә эшли торган аеруча мөһим эшләр бүлеге оперуполномоченные Радис Йосыпов сөйләде.

2024 елда, аның сүзләренә караганда, татарстанлылар алдаучыларга үз кесәләреннән 5 млрд 659 млн сум чыгарып биргән. Бер ел элек республикада яшәүчеләр, шундый ук ятьмәгә эләгеп, 4 млрд 410 млн сумны югалткан. Ә инде агымдагы елның гыйнвар-февраленә килсәк, халык мошенникларга башка еллардагыга караганда 190 миллион сумга

Фото: pxhere.com

күбрәк акча юллаган. Бу турыда даими аңлатып торылуга карамастан.

ТР прокуратурасының Тикшерү, сорау алу һәм оператив-эзләү эшчәнлеге күзәтчелеге идарәсе башлыгы урынбасары Руслан Шакиров сүзләренә караганда, хәзерге көндә кеше үз исеменә 25 тән күбрәк сим-карта терки алмый. Әле болай да күп, диясезме? Чынлап та, аз түгел. Әмма элегрәк бер кеше йөзләгән карта терки ала иде.

Чит ил кешеләре, сүз уңаеннан, хәзер бары тик 10 симкага хокуклы. Сим-боксларны закон тарафыннан тыярга дигән фикер дә бар, ди оператив хезмәт вәкилләре. Бу җайланмаларда күп сим-карта тупланган, һәм алар телефоннан шалтырату маршрутларын исәптә тота ала. Чит ил номерларының җирле телефон линияләренә тоташуын да. Бер фатирда урнашкан һәм автоном рәвештә эшли торган мондый «тартмачыклар» аша, кеше ярдәменә мөрәҗәгать итмичә генә, йөзләгән ялган шалтырату оештырып була.

Әмма дәүләт нинди генә чаралар кулланмасын, мошенниклар барыбер аларга каршы контрчаралар табып кына тора. Әйтик, гражданнар «Дәүләт хезмәтләре» аша кредитларга үзтыю куярга мөмкин. Әмма алдаучылар икенче ысул таба: гражданнарга шалтыратып, үзтыю дөрес куелмаган, ул гамәлгә кермәгән, дияләр. Шуннан соң, кешегә фишинг (ялган) сылтама җибәрәләр, аның буенча гражданнар «Дәүләт хезмәтләре» рәвешендә эшләнгән чит сайтка эләгә. Шунда үзенең мәгълүматын кертә, логин белән паролен җыя, автомат рәвештә алдаучылар кулында корбанга әверелә.

Мондыйга дучар булмас өчен, **төп кагыйдәне онытмагыз: «Дәүләт хезмәтләре» вәкилләре гражданнарга беркайчан да телефоннан шалтыратмый!**

СЫЛТАМАЛАР АША БЕРКАЯ ДА КЕРМӘГЕЗ!

Шулай беркөнне кич белән, соң гына ерак танышым шалтыратты. Соравы идеме, әллә каттый раславымы:

– Синең бит Настя исемле туганнан-туган сеңлең булганы юк...

– Булганы юк! – дим мин, килешеп. – Хәзер дә юк!

– Димәк, синең телефоныңны «җимергәннәр»! – ди ул. – Синең исемнән ватсапта язалар: әлеге сылтама буенча кереп, ниндидер сайтта Настя туганың өчен сорыйсың, янәсе.

Нәтиҗәдә, ярты төнем парольләрне алыштырып, ялган хәбәрләрне юкка чыгаруларын үтенеп, беркемгә дә тавыш бирмәгез, диеп туган-тумача, таныш-белешләрне кисәтеп узды.

Соңрак, мин әйтергә өлгермәгән берничә кеше язды: без Настя өчен бик теләп тавыш бирдек, диделәр... Нәрсә эшләп була мондый хәлдә? Икенче юлы болай беркатлы булмагыз, зинһар, дияргә генә кала, билгеле.

Минем аккаунт дучар булган алдау ысулы берәүгә дә җитди зыян китермәгәндер, дип ышанасы килә. Чөнки сылтама аша кереп кемнеңдер апасы, сеңлесе, оныгы һ.б. өчен тавыш биргәндә үзегез турында әллә никадәр мәгълүмат кертәсез. Аларны үз кулыгыз белән үк алдаучылар карамагына тапшырасыз, дигән сүз. Ә алар бу мәгълүмат белән нәрсә эшләячәк – анысын инде бер Ходай гына белә...

Мессенджерлардагы сылтамалар гына түгел, ә электрон почтагызга килгәннәре дә куркыныч булырга бик мөмкин. Аларга вируслы файллар беркетә алалар, шуңа күрә **билгесез кешеләрдән килгән хатлардагы сылтама белән кушымталарны ачмавыгыз хәерле. Сәер корреспонденциядә билгеләнгән телефоннарга да шалтыртатмаска киңәш итәбез,** аларда ни булмас. Хәтта сезгә нинди дә булса рәсми сайтка керергә өндәмә килсә дә (мисал өчен, онлайн-кибетләр), башта игътибар белән укыгыз – адресы һәм исеме дөрес язылганмы? **Бер генә дөрес булмаган хәреф тә сезне фишинг ресурска керергә чакыралар, дигән сүз.**

«ҖИТӘКЧЕЛӘРГӘ» ЫШАНМЫЙБЫЗ!

ТР Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү министрлыгының мәгълүмат иминлеген координацияләү бүлеге башлыгы Илдар Вәлиев китергән статистика буенча, 45 проценттан артыграк очракта кешеләр мошенниклар кулына шалтыратулар һәм смс-хәбәрләр аша барып эләгә. Шалтырату дигәннән, алар беркатлырак пенсионерларны гына түгел, ә яшьрәкләрнең дә күзен буа ала. Әйтик, видеоэлемтә аша сезгә җитәкчегез шалтырата. Әйе, сез аның йөзен күрәсез, тавышын ишетәсез. Әмма аның соравы, яки үтенече сезгә бик сәер тоела... Шулаеншулай, тик сез бит моның чыннан да ул икәнен үз күзегез белән күреп торасыз!..

Дипфейк технологияләре – ясалма фәһем ярдәмендә ялган аватарлар ясау дигән сүз ул. Бу төр «аватарлар» кемнеңдер сурәте белән тавышын тулаем чагылдыра ала, шактый югары дәрәҗәдә эшләнелә. Әмма, ди, ТР Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү министрлыгы хезмәткәрләре, аларны да «ватып», ачыклап була. Детальләргә игътибарлы булыгыз – ясалма җитәкчегезнең күзләре йомылмаячак яисә сәер йомылачак, чәчләре, тешләре томанлырак күренергә мөмкин... **Озын сүзнең кыскасы, әгәр җитәкчегезне күрәсез вә ишетәсез, телефон номеры да тәгаен анык икән, барыбер дә истә тотыгыз: бу алдау була ала. Моны истән чыгармагыз, хәтта иң абруйлы санаган, ихтирам иткән кешеләрегезгә дә, төгәллек кертмичә, тикшереп карамыйча, картагызның мәгълүматларын әйтмәгез!**

ЫШАНМА, КУРЫКМА, ЧИКЛӘМӘ

Мошенникларның аерым бер «яраткан категориясе» – балалар. **Әгәр без элек балаларны таныш булмаган кешегә ишек ачасы булма, дип кисәтсәк, хәзер аларга интернеттагы адәмнәргә ышанырга ярамый, дип өзлексез тукып торырга кирәк.** Шулай ук куркытуларга игътибар итмәскә өйрәтергә, виртуаль әңгәмәдәшләр кушкан әмергә колак салмаска, аларны тыңламаска. Баланың гаджетына чикләү куеп, сәер банк операцияләрен шунда ук күреп була торган иттереп, онлайн банк хәбәрләрен үзегезнең телефонга куша алсагыз, бик әйбәт.

Аннан кала, үсмерләр белән яшьләр әле тагын үзләре үк алдаучылар белән бәйләнештә булырга мөмкин. Дропер булып, карта мәгълүматларын чит кешеләргә биргәннәр икән, күңелсезлекләрне көт тә тор! Нәкъ менә шундый карталар халыкны алдау өчен кулланыла башлый. Яшүсмерләр дропер схемалар аша кергән суммалардан процент эшләргә мөмкин. Дроперлык белән яшьләр генә түгел, ә өлкән буыннар да шөгыльләнә. Шәхси банк кабинетына керү мөмкинлеген алу бүген 50 мең сумга төшә, диләр. **Җиңел генә «акча эшләп алу» күпләр өчен кызыктыргыч. Әмма шуны да онытмаска кирәк: бу – хокук бозу санала, аның өчен штрафтан башлап җинаять эшен ачуга кадәр җәза кулланыла.**

ТЕЛЕФОН НОМЕРЫН БАР ҖИРДӘ ДӘ АЛЫШТЫРАБЫЗ!

Алдау корбанына әверелмәс өчен, тагын истә тотарга кирәкле берничә нәрсәгә тукталыйк.

Әгәр дә сезгә хокук саклау органнарыннан (янәсе!) шалтыраталар һәм банк картагыз белән ниндидер сәер операцияләр хакында искәртәләр, аннары сезне «банк хезмәткәре» белән сөйләшү линиясенә күчерәләр икән, белеп торыгыз: ЭЭМның телефон линияләре белән банкларныкы үзара тоташмаган, алар элемтәне бер-берсенә берничек тә күчерми!

Онытмагыз: әгәр сим-картагызны кулланмый башлыйсыз икән, бу хакта банкларга да, «Дәүләт хезмәтләре» сайтына да хәбәр салыгыз. Чөнки карта шәхси кабинетларга «бәйләнешле» булып кала бирә. Мошенниклар андый сим-карта мәгълүматларын сата һәм сатып ала, аларга кредит белән займ теркәргә мөмкин. Телефон номерыгызны алыштыру белән үк, аны кайларга «бәйләдегез», ул «койрыклар» юкка чыгарга тиеш.

АКЧАНЫ ҮЗЕБЕЗ КАЙТАРМЫЙБЫЗ!

Әгәр сезгә **«ялгыш кына» зур сумма күчергәннәр дә аны кире кайтаруыгызны сорыйлар икән, һич кенә дә күчерә күрмәгез!** Акча күчерергә тотынсагыз, мошенниклар кулына эләгергә мөмкинсез. Шуңа иң беренче банкка мөрәҗәгать итәргә кирәк: ялгыш акча күчерү булды, зинһар, бу операцияне кире кайтарыгыз, диегез. Аны үзләре башкаруы хәерле.

QR-КОДЛАР АША ҮТМӘҮ ДӘ ХӘЕРЛЕ

Телефоннан QR-кодлар аша ниндидер эшләр эшләү дә һәрвакытта да куркынычсыз булмаска мөмкин. Мисал өчен, **реклама плакатларына мошенниклар чын QR-код белән бергә ялганын беркетә ала.**

Алдау махинацияләре турында безнең журнал да, башка чыганаклар да инде күп мәртәбәләр язды, сөйләде, хәбәр итте. Әмма, күргәнебезчә, алдау корбаны булган гражданнар саны аңа карап кимеми, ә арта гына бара.

Тагын бер кат барлык киңәшләрне дә укып чыгып, игътибарлы булуыгызны, аек акыл белән эш итүегезне үтенәбез!

«ТАТАРСТАН» ИСЕГЕЗГӘ ТӨШЕРӘ:

- **«Дәүләт хезмәтләре» вәкилләре гражданнарга беркайчан да телефоннан шалтыратмый!**
- Билгесез кешеләрдән килгән хатлардагы сылтама белән кушымталарны ачмавыгыз хәерле.
- **Сәер корреспонденциядә билгеләнгән телефоннарга шалтыратмаска киңәш итәбез.** Бер генә дөрес булмаган хәреф тә сезне фишинг ресурска керергә чакыралар, дигән сүз.
- **Әгәр җитәкчегезне күрәсез вә ишетәсез, телефон номеры да тәгаен аныкы икән, барыбер дә истә тотыгыз: бу алдау була ала.** Картагыз мәгълүматларын һәм кодны бирәүгә дә әйтмәгез.
- **Балаларны интернеттагы адәмнәргә ышанырга ярамый, дип тәрбияләргә кирәк.**
- Дроперлык яшьләр өчен җиңел генә «акча эшләп алу» ягыннан кызыктыргыч. Әмма шуны да онытмаска кирәк: **бу – хокук бозу, аның өчен штрафтан башлап җинаять эшен ачуга кадәр җәза кулланыла.**
- Телефон номерыгызны алыштыру белән үк, **аны кайларга «бәйләдегез», ул «койрыклар» юкка чыгарга тиеш.**
- Әгәр сезгә **«ялгыш кына» зур сумма күчергәннәр дә аны кире кайтаруыгызны сорыйлар икән, һич кенә дә күчерә күрмәгез!** Моны банк башкарсын.
- **Реклама плакатларына мошенниклар чын QR-код белән бергә ялганын беркетә ала.** Телефоныгыз аша аларга керү хәтәр була ала.

«Казанның агач йортлары» проектын «Татарстан» журналы «Татар ядкәрләре» Шәхси оешмасы белән берлектә эшли. Бу саннан сезне татар иленең мәркәзе булган Казаныбызда сакланып калган, тарихлары милли мәдәниятебезнең асыл шәхесләре белән бәйле агач йортлар белән таныштыра башлыйбыз. Бу йортларның кайберләре – милли-мәдәни мирас объектлары, ә кайберләре – ни кызганыч! – әлеге исемлектә теркәлмәгән.

КРЕСТОВНИКОВЛАР ЙОРТЫ: КАЗАННЫҢ ЙӨРӘГЕ КАЙДА ТИБӘ?

Луиза Янсуар, Фәнзилә Җәүһәрова

Без Тукайлы халык булуыбызны гел кабатларга яратабыз. Ә Казанның йөрәге кайда тибә икәнен сорасалар, нәрсә дип җавап бирә алабыз? Бәлки, Тукай исемен йөрткән, аның музее урнашкан һәм татарга бәйле тарихи хәтерне саклаган шушы урамнардадыр? Татар зиратына да, гадәттә, бу урамны кистереп юл сабабыз без.

Маршрутыбызның беренче йорты – Тукай урамы, 126. Атаклы Крестовниковлар йорты.

Фәнзилә Хәкимовна Җәүһәрова белән йортның нәкъ каршысында очрашабыз. Без бу йортның төрле чакларын беләбез: зәңгәрсу буяулы чаклары да булды аның, хәзер менә – сары.

Совет чорында Крестовниковлар йортында балалар бакчасы урнаша. Хәзерге көндә ул Камал театрының рәсмиләштерелгән базасы булып санала. Монда яшь артистлар белән режиссерлар, техник хезмәткәрләр дә яши. Театр карамагында булган йортта төзекләндерү эшләрен дә алар башкарган, әле дә булдыра алган кадәр карап-сипләп торалар.

ИГЪТИБАР!
XIX гасыр ахырының торак архитектура һәйкәле исәпләнгән Крестовниковлар йорты ТРның мәдәни мирас объекты биналары исемлегендә.

Фото: Александр Ефремов



САБЫН КАЙНАТУ ЗАВОДЫ ХУҖАЛАРЫНЫҢ БЕР ВӘКИЛЕ – ИНГЛИЗ КРИС КРЕСТОВНИКОВ, СССР ТАРКАЛГАННАН СОҢ, КАЗАНГА КИЛӘ. УЛ КФУДА ИКЪТИСАД БУЕНЧА ЧЫГЫШ ЯСЫЙ, САБЫН ЗАВОДЫНДА БУЛА, БАБАЛАРЫНЫҢ ЙОРТЫН ЗИЯРӘТ КЫЛА.

ТАРИХКА ЭКСКУРС

– Казан шәһәрендә XIX, XX гасырларда төзелгән агач йортлар бик аз сакланган. Сакланганнары да тузган торакны бетерү кебек масштаблы программа нигезендә сүтелеп, алар урынын шактый төссез, унификацияләнгән торак комплекслар, панель йортлар биләп бетереп килә, – дип сөйли Фәнзилә Хәкимовна. – Ә менә сабын заводыннан (хәзерге «Нэфис Косметикс») ерак түгел, Екатерининская урамындагы (хәзерге Тукай урамы) урнашкан менә бу ике катлы йорт бүген иң яхшы сакланган һәм үзенчәлекле нәкышләнгән агач йортларның берсе.

Бу әллә кайдан үзенә җәлеп итә торган йортны XX гасыр башында танылган Мәскәү фабрикантлары – дан-шөһрәтләре Казанда гына түгел, Парижда, Филадельфиядә, Чикагода да таралган сабын җитештерүчеләр – бертуган Крестовниковлар төзетә. Йорт төзү инициативасы абыйларыннан аермалы буларак Казанда даими яшәгән Иосиф Константиновичка карый.

Йортның кайчан төзелүен төгәл белмибез, шулай да тарихчылар 1905-1914 еллар арасыгы белән билгели. Аның рус төзелеш традицияләренә хас кояш, кошлар, үсемлекләр уеп ясалган тәрәзә йөзлекләре беркетелгән фа-

сады әллә каян аерылып, үзенә тартып тора. Биредә без йортларны рус балта осталарына хас ысул – агачны челтәрләп, уеп-кисеп бизәүнең күркәм үрнәкләре белән таныша алабыз, – дип дәвам итә Фәнзилә Хәкимовна. – Йортка керүнең төп капкасы – төньяктан, ә көньягында ашханә аша чыга торган веранда (ул хәзер юкка чыккан) булган.

Күргәнебезчә, йорт ике катлы. Аның кирпечтән эшләнгән беренче каты хуҗалык эшләре корылмасы буларак проектланган, ә өске кат хуҗаларга торак буларак таза, нык бүрәнәләрдән төзелгән. Әлбәттә, еллар йортны бераз үзгәрткән. Биредә өстәмә тәрәзәләр, ишекләр уелган, чуеннан коелган затлы коймалар сүтелгән, алар урынына менә бу кирпеч корылмалар күтәрелгән. Шуңа күрә хәзерге бу йортны чын мәгънәсендәге тарихи архитектура һәйкәле буларак күзаллавы авыр, ләкин аның Казанда санаулы гына калган тарихи агач йортларның берсе булуына һәм беркадәр каралып, сакланып торуына куана алабыз.

КЕМНӘР УЛ – КРЕСТОВНИКОВЛАР?

Инкыйлабка кадәр Казанга килүчеләр туташ-ханымнарга алып кайта торган иң зур, кадерле бүләк – Крестовниковлар гаилә ширкәтендә җитештерелгән мәрмәр сабын саналган. Аның рәсми исеме дә нәкъ шундый – «Мраморное мыло». Бу хакта «Казань. Времён связующая нить» дип аталган китапта: «XX йөз башы Казанында шәһәрнең төп сәнәгать потенциалын Алафузовлар белән Крестовниковлар ширкәтләре тәэмин иткән» дип язылган. Мәсәлән, Беренче бөтендөнья сугышы башланганчыга кадәр Крестовниковларның шәм белән сабын заводы елына 8 миллион сумнан артык товар җитештерә.

Крестовниковлар династиясенә нигез салучы булып 1 нче гильдия сәүдәгәре Козьма Васильевич исәпләнә. Мәскәүгә ул Переяславль-Залесский каласыннан күчеп килә. Аның уллары – Александр белән игезәкләр Ксенофонт һәм Константин 1826 елда 1 нче Мәскәү гильдиясенә күчә. 1831 елда «Бертуган А.,К. һәм К. Крестовниковлар» сәүдә йортына нигез салына һәм 1832 елда аларга шәһәрнең Мактаулы гражданнары статусы бирелә. Тагын бер кызыклы факт: Крестовниковлар Россиянең егермедән артык шәһәрендә сәүдә конторалары тота.

1812 ЕЛГЫ ВАТАН СУГЫШЫ ЧОРЫНДА КРЕСТОВНИКОВЛАР РОССИЯ АРМИЯСЕ ФАЙДАСЫНА 50 МЕҢ СУМ АКЧА КҮЧЕРӘ.



АКАДЕМИК

ЖИЛОЙ КОМПЛЕКС

Уңайлыкның иң югары дәрәҗәсе



Казанның тарихи үзәгендә

9 йорт

277 машина урыны

3,15 түшәмнең минималь биеклеге

3-7 кат

Террасалы **6** фатир

Премиум-класслы торак комплексы

+7 (843) 590-83-83
Сату бүлеге: Казан ш., Әмәт магистрале, 18, 1 к
Эш сәгатьләре: дшм. – җом.: 9:00 – 18:00

akademikdom.ru сайтында фатир сайлагыз

РЕКЛАМА. Застройщик: ООО «Специализированный застройщик «АСД-2»». ИНН1686027870. Представленная информация носит исключительно ознакомительный характер, ни при каких обстоятельствах не является публичной офертой, определяемой положениями статьи 437 ГК РФ. Построенные объекты могут отличаться от представленных 3Э-визуализаций, изображений. Все представленные материалы, изображения являются ориентировочными, в них могут быть внесены любые изменения и дополнения. Срок завершения строительства IV кв. 2027 г. Проектная декларация №16-002062 от 25.12.2024 на сайте наш.дом.рф.